ФӘРИТ ЯХИН

# *ГАСЫРДАН–ГАСЫРГА: ЯҢА ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫНА*

«Сүз» нәшрияты
Казан

2014

УДК 821.0
ББК 83 (2 Рос=Тат)
Я 90

**Яхин Ф.З.**
Гасырдан — гасырга: Яңа заман әдәбиятына.— Казан: «Сүз» нәшрияты, 2014.— 215 б. (10 а.т.)

Я 90

Татар әдәбиятының үсеш тенденцияләренә багышланган дистәләрчә хезмәтләрдән аермалы буларак, бу китапта әдипләрнең иҗатлары яңача аңлатыла һәм бәяләнә, хаталы карашлар кире кагыла, заманча эстетика һәм әдәбият гыйлеме фикерләмәләре тәкъдим ителә, авторның иҗтимагый тормышка һәм сәнгатькә бәйле уйланулары да әдәби тәнкыйть кысаларында бирелә.

**© Яхин Ф.З.**

**ISBN 978-5-98356-233-2**

# ТАТАР ТЕЛЕ — АРИСТОКРАТЛАР ТЕЛЕ

## I

Ни өчен аксөяк-аристократлар теле? Хикмәте шунда — Казан шәһәрендә татар әдәби теле хәтта иң авыр, тел сәясәтендә катлаулы елларда да шушы аксөякләрдә камил дәрәҗәдә кулланылышта һәм яшәештә булды. Моның хыялый истәлек түгел, бәлки хактан да шулай икәнлеген ачык аңлау-аңлату өчен йөзләрчә вакыйгаларны искә алып сөйләп китәргә мөмкин. Әмма берсенә генә тукталып узам.

Бервакыт шулай, университетта укыган студент елларым иде, күптән танышып, хисләребезнең уртак булуында шикләребез калмаган хәлдә, сайлаган ярымның әти-әнисе белән танышу өчен үзләренә бардым. Аларның иске тарихи заманнардан ук сугарылып киленгән милли бәрәкәт туфрагы тәрбиясендә яшәүче чын татар кешеләреннән икәнлекләрен әлегә белми идем. Хәер, ул танышу шарты белән булган очрашудан соң да нәсел-нәсәпләреннән хәбәрдарлыгым берничә ел дәвамында артмады. Алар: «Без — шулар, тарих ниргәләрендә милләтебезнең мәгърур йортын төзегән шанлы бабаларыбызның балаларыбыз»,— дип бер генә булса да мактанып сүз кузгатмадылар. Болары тормыш барышында белешкәнемдә, китаплардан очраган исемнәр белән бәйле сорауларыма җаваплар тапканымда гына мәгълүм булдылар.

Өйләренә кереп, исәнләшеп, инде танышу һәм аралашу ишекләре миңа киң ачылгач, гаилә атасы Тарикъ Шәех улы әйтә куйды:

— Без өйдә урам телендә сөйләшми идек!

Тәрбиясезлегемне сиздерүдән йөземә оят кызыллыгы йөгерми калмады. Ул узган гасырның сиксәненче еллары башында Казанда «урам теле», «урам тәрбиясе» дигән гыйбарәләргә киң вә тирән мәгънәләр салынып, аларга бәйле кисәтүләрне,— матбугатта булмасын, халык телендә кабатланмасын, университет профессурасы телендә әйтелмәсен,—

яшьләргә еш искәртә иделәр. Бу сүзләр кешенең холыкта һәм әдәптә үзен иркен хис итүен тарлауга этәрәдер сыман да иде. Мин ул «урам теле» дигәннәрендә әлбәттә «русчаны тоюым чамалыдыр» дигән фикергә килдем. Заманасы шундый иде аның: һәммә җирдә, урында, хәтта дөньяда бары тик рус теле генә тел, русча сөйләшү генә сөйләшү, русча белем генә белем һәм тагын да әллә ни-күпме русча-русчалыклар өстен куела иделәр. Бәлки ялгышамдыр? Аннары, кайдадыр еракtагы сала бәрәңгесен ашап үскән, икмәккә туймас булган колхозлы татар авылы баласы, инде егет кеше, Казан аксөякләрен күргәнбелгәнмени? «Урам теле»ндә сөйләшүемне дәвам итеп, сүзләр бәйләнешендәге «падеж» вә «окончание»ләргә аерата зур игътибар салып, сорауларга мөмкин кадәр аң белән җавап бирәм. Тырышлыгым әлбәттә кызларын да, үземне дә оятлы итмәү теләге белән сугарылган. Әмма тагын да шул ук сүз кабатлана, гади, гадәти, шелтәсез:

— Без өйдә «урам теле»ндә сөйләшми идек!

Бу аристократик кисәтү инде аңыма барып җитми калмады, йөрәк бөтенләй дә башка яктан, тамырыннан киселеп куйгандай булды. Күрше як бүлмәдә тыныч кына, әмма ягымлы һәм рәхәт итеп Татар радиосы сөйли. Һәм мин:

— Гафу итегез!— дип үтендем.— Аңламый торам...

Бу йортта шушы сүзләр минем тарафтан беренче тапкыр әйтелгән татарча сүзләр булдылар һәм алар Ходайның хикмәти тәэсире илә хуҗалар тарафыннан кабул ителделәр. Күңелем суынганчыга кадәр баштарак телсез калгандай үземне тойдым, аннары сәер уңайсызлыклар онытылды. Ул йортта моннан соң һәрдаим татарча гына сөйләшергә тиешлегемне төгәл белеп алдым. Дөнья йөзе дә башкача күзаллана башлады. «Урам теле», «урам тәрбиясе» дигән гыйбарәләрнең дә «рус теле», «рус тәрбиясе» дигән мәгънәләргә ия икәнлеген белеп һәм аңлап яшәү күземне генә түгел, күңелемне дә ачып, анда якты утларын меңтөрле тасвирлы төсләрдә кабызып җибәрде. Минем танышлык-танышулар киңәя торды һәм һәр татар аксөякләре гаиләләрендә шул ук бер хәл иде. Әмма, гыйбрәт өчен булгандыр, «урам тәрбиясе» коткысында калган һәм шуның белән «урам теле»нә балалары аяк баскан семьялар

да юк түгел иде. Тагын да искәртергә тиешмендер, ул ныклап атлаган балаларының көннәрдән-беркөнне аяклары таеп киткәнен күреп һәм ишетеп, вакыйгалардан хәйранлык хәсрәтендә сүзсез калган хәлләрне дә узарга туры килде. Бу хакта башка әдип һәм журналистларыбызның язмаларын укыганымда, аңлап җиткерми, миңа бу кагылмый дип кенә, күңел белән игътибарга алынмаган. Инде аларның хаклы булуларына, кайнарланып бәян итеп, кисәтеп язып чыгуларына ил халкы, милләт рәхмәтледер?

Әмма тагын да шунысы бар: ул татар аристократиясе-аксөякләре үз балаларын башка милләт вәкиленә кияүгә бирүгә яки өйләндерүгә һичбер каршылык итмичә, ә тәрбиядә татарлыкны, татарчалыкны оныкларына тапшыра ала һәм белә иделәр. Ә моңа мин сокланыргамы, әллә шелтә белән карарга тиешлеме идем? Андый никахлар һәм тәрбия матбугатта да, милли сәясәттә дә ничәмә кат кире кагылды түгелме?

Тормыш юлымда күтеп торган мәсьәлә булып чыкты ул. Аны мин, үземә килеп кагылгач, нәкъ аларча чиштем. Казан милли аксөякләренең гаилә бәхете дигәннәре — ныклы, саф мәхәббәткә корылган тигез тормыш. Бу мәсьәләдә алар үтә сак була беләләр. Монда Аллаһы тәгаләнең тәкъдир кулы уйнавына зур ышаныч белән карыйлар. Сүздә ул мәсьәләгә шушы килеп алуыбыз фикер мантыйгыннан гына түгел, тормыш чынбарлыгының үзенчәлекләрен дә искәртүдән икәнлеге аңлашыладыр?

## II

Рәсәй шартларында ябылып яшәгәндә рус телен белү белән генә канәгать итсәң дә җитә. Ул шулай булды. Хәтта милли телнең дә кирәге бетә. Моны дөрес аңларга тиешбез. Глобаль шартларга интеграция милләтләр өчен бөтенләй башка мөмкинлекләр ача.

Моңа кадәр яшәгән һәм табигый дип исәпләнелгән хәлләрнең үзгәреше хәзер халыкта телләргә булган мөнәсәбәтне кискен рәвештә яңартып җибәрде. Элек гаилә, өй-йорт кысаларында гына булган туган телнең глобаль коммуникатив мөмкинлекләре аерым әһәмияткә ия икәнлеге ачыкла-

ныып, мәдәни үсеш шартларында туган телнең һичшиксез кирәклеге аңыбызга барып ирешге. Милли тел иҗтимагый функция генә түгел, бәлки дәүләти, илнең яшәве шартларының берсе сыйфатын үзенә алып, мәртәбәдә үсеш кичерә башлады. Татарстан дәүләте, аның идарәсе, өскормасы моны ачык аңлап эш итәргә мәҗбүр булды. Бездә ул ихтыяр көченең әйдәве тәэсирендә алып барылган төсне алды. Аны рус теленә каршы сәяси хәрәкәт формасында кабул итүебезнең төп сәбәбе милли җәмәгатьчелегебезнең холкыннан да килә иде. Глобаль процесста туган телнең югалып калу мөмкинлеге дә фараз ителеп, татар җәмгыятен кабат үзенә бикләнергә, йомылырга, хәтта вакуумга кертү юлына да барырга әзер торган милли каһарманнарыбыз сүз һәм гамәлне әлбәттә изге максатларга юнәлтүдән шулай эшли иде. Әгәр дә Рәсәй кабат үз эченә ябылса, дөнья белән бергә кешелекнең мәдәни үсешенә омтылмаса, иске хакыйкатьләр кабатланачак, милли телебез дә өй ишекләребез артына кереп бикләнәчәк, аксөяк-аристократлар, зыялылар теле булып калачак, моны тоталитар яшәеш шартлары рәвешендә кабул итәргә тиешле икәнлегебез көн тәртибенә килеп басачак иде.

Әмма глобаль вазгыять бездән дөнья күләмендә коммуникатив дәрәҗәсе көннән-көнгә арта барган инглиз телен белүнең әһәмиятен алга куйды. Бүгенге татар аксөяк-аристократлары бу яктан борчылусыз яшиләр. Татарчасы, русчасы һәм инглизчәсе электән яхшы куелган бу катлам үз яшәү кыйммәтләренең тарихи үсеш шартларында кабат өстен чыгарылуына сөенми кала алмый. Болар янына алар тагын да гарәпчәне яхшы ук дәрәҗәдә чамалыйлар, иске заманнардан калган гадәт буенча фарсыча мөгамәлә кыла алалар, төрекчәне таныйлар. Телгә һәм телләрне белүгә һәр кешенең, әлбәттә югары мәдәниятле кешенең, ягъни зыялының, ихласы булырга тиеш дигән караш һәм күзаллау каннарына сеңгәнлек сәбәпле, табип-медикмы, инженермы, укытучымы, башка өлкә вәкилеме, кайда гына эшләмәсеннәр, Казан милли аксөякләребез бу тәрбияләрендә мөкатдәс хис белән береккәннәр. Китапханәләрендә француз, испан, немец, инглиз, гарәп, фарсы, төрек, татар, рус китаплары алгы рәтләрне

алып, алар янәшәсендә кытай-япон әсәрләре дә күренә башлау бәхәссез мәдәни затлардан икәнлекләрен танырга мәҗбүр итә. Татар язучыларының әсәрләрен күпләп укыганлыклары, һәр әдипкә карата татар рәсми тәнкыйтенә һәм танылган әдәбиятчыларының фикерләренә бәйсез рәвештә бәяләре булу, җитмәсә электән укылып, халыкта истәлекле ядкәрләр сыйфатында саклanganлыгы сәбәпледер, хәтта «Тәварихы-Болгария» («Болгар тарихлары») кебек, фән вәкилләре тарафыннан Шиһабетдин Мәрҗани заманнарыннан тәнкыйть ителә килгән китапларга да теш азайтуны, сүз белән суктыруны яратмыйлар. Шул «Тәварих» хакында кемдер саксыз фикер кузгатса:

— Онытмагыз, аны иманында камил, аңы-белеме бар кеше язган,— дигәннәрен ничәмә ишеттем.— Безнең чорыбызның белемдә тарлыгын гаеп итүебез — дөресрәктер!

Ш.Мәрҗани, М.Акмулла, Р.Фәхретдин, М.Госманов һәм башка галимнәрнең ул китапка биргән бәяләре йогынтысында формалашкан фикер калыпларым озак вакытлар шул хәбәрдар Казан аксөякләренең сүзләре тәэсирендә тамырдан какшаган икән, монда әлбәттә бары тик аң-белем дәрәҗәсенең бездә канәгатьсез хәлдә булуыннан гына зар итәргә кала. Дәлилгә китерелгән «Ибне-Фадлан сәяхәтләре»ндәге фактларга да беркатлылык белән турыдан-туры ышанырга тиеш түгелмен икән әле. Моны татарларга бераз хас кирелек аркасында дип аңларга ярамый.

## III

Бүгенге көндә рус теле «урам теле» булудан үзе дә арына барып, милли мәртәбәсенә кайта башлады. Әмма ул барыбер дә безгә кирәк, глобальләшү шартларында аның да әһәмияте бермә-бер артты. Рус теленең чит илләрдә мәртәбәсе һич кенә дә ким түгел, төрле мәмләкәт вәкилләре русчаны танырга, белергә, үзләштерергә омтыла. Бу әлбәттә шул ук мәдәни үсеш юлының киңәя баруына бәйле. Рус телен өйрәнүебез, белүебез бүгенге көндә үзебез өчен дә файдага. Моңа Рәсәйдә яшәвебез генә сәбәп түгел. Милли хәрәкәтебез дә рус теленең үзенә каршы түгел, бәлки халыкта аны «урам теле» булып калу

бәласеннән котылдыру юлын эзләү процессы да бара. Бусы да ачык билгеле хакыйкатьләребездән.

Рус теленең туган тел, чит телләр кебек үк, бүгенге XXI гасыр Рәсәй кешесенә кирәклеге, аның да мәдәни, хәтта дини үсешебезгә дә хезмәт итүе һәм иттерелүе, аксөякләребезгә генә түгел, халкыбызга да бары файдага. Рус телен без мәктәпләребездә, югары уку йортларыбызда, көндәлек тормышыбызда өйрәндек һәм өйрәнәчәкбез. Аңа инде мөнәсәбәтебез «урам теле»нә булган мөнәсәбәт түгел, бәлки милли, зыялы, мәдәни телгә карата хөрмәтебез төсен алды.

Татар халкының шушы соңгы унбиш-егерме еллар эчендә генә дә телләргә бәйле үсеше сокландыра. Бу ниндидер бер ялагай, куштан, мактану сүзләре түгел, бәлки чынбарлыкны дөрес аңларга тиешбез дип таләп итүдән туган уйларыбызның фикер формасын ала баруы күренешеннән килә. Башкалар бүтән реалийләрдә яшәргә мөмкиннәр, әмма мин ул хакыйкатьләрне тоймыйм, күрмим һәм аңламыйм. Белемем татар әдәбияты һәм журналистика гыйлеме өлкәләре белән бәйләнештә үсте. Язучы һәм шагыйрь буларак дөньяның барышын туктаусыз күзәтергә, бәяләргә, ачыкларга туры килә. Борынгы язма мирасыбызны ничә дистә еллар даими өйрәнеп, тикшереп, текстларын том-том китаплар рәвешендә дә, фәнни анализ юлында гыйльми трактатлар хәлендә дә халыкка, өлешчә булсын, кайтаруларым да — барысы бергә татар милли тормышын һәм яшәешен дөрес күрәм, тугыры бәялим дигән өметемнең терәге. Ялгышырга да мөмкинмен. Адәм баласы хаталардан хали була алмый шул.

## IV

Телебезне алга таба нәрсә көтә? Ул үсешендә туктап калмасмы? Яшьләр аңа ничек карар? — Менә шушындый йөзләрчә төрле сораулар аңны да, күңелне дә борчып торалар. Аңлашыла, яшьләрнең туган телебезгә һәм башка телләргә мөнәсәбәте тәрбиядән алынган өлешкә дә, глобаль мәдәни үсешкә кушылып, аннан читләшми яшәвебезгә дә бәйле. Бер чит телне генә белгәндә, ул тел үз сөйләшебездә ана телебезне чүпли башлый, әмма ике-өч чит телне үзләштергәндә —

бөтенләй башка төрле процесс башланып, аң һәм телне мөкатдәс итеп кабул итүгә күчәсең һәм аның шушы үсешкиңәеше үз милли телебезнең сафлыгына хөрмәт хисен ныгыта. Әмма иң тәүдә үз милли ана телеңне белеп алу шарт. Бу фикер үз тәҗрибәмнән генә түгел, башка ничәмә акыл иясе кешеләрдән ишетелгән, хәтта әүвәле ишеткәннәремдә гаҗәпкә дә калдырган сүз.

Татар телебезнең драматик кына түгел, трагик халәт алдында калган чаклары да булмады түгел. Заман үзгәреше Рәсәй чикләрен ничек ачарга мәҗбүр итсә, аң-белемдә чикләнгәнлегебезне дә бик тиз ихтыярый төшендерде. Вакытында авыл мәктәбендә укуым да, Казан милли аксөякләребез арасында кабул ителүем дә, башка сәбәпләр дә миңа ярдәм иткәндер дип беләм. Татарчасы яхшы булган кешенең русчасы һәм чит телне белүе аның каравы начаррак дигән кешеләрне аңламыйм. Русчам дәрәҗәсе үземдә канәгатьсезлек тойгысы уяткан чаклар аз булмады, туган телем белән бәйле дә шундый ук хисләр кичермәдем түгел, чит телләрне үзләштерү осталыгым да бик үк алай сөендерде дип әйтү җаема килми. Боларны авыл мәктәбенең тәрбиясе җимешләреннән буларак азмы бәяләдем. Шуның белән хаталы уйларга да дучар идем. Әмма авыл мәктәбенең үз хозурлыклары һәм ямьнәре хатирәләремдә яңарып, булдыксызлыгымны фидакарь укытучыларыма, аларның дәресләренә аудару бәласеннән шул изге тойгылар саклап калдылар. Төрле телләрне белү бәхете кешегә әйтепсөйләп бетереп булмаслык рәхәтлекләр ирештерә!

Бүген мәктәп белеменең заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә булырга тиешлеген күпләр кайгырта. Дәүләт думасы махсус карарлар әзерләде. Дәүләт советы да эштә. Аңа карап кына, каршылыклы карарлар белән генә берни дә хәл итеп булмас, укучылар һаман да искечә калырлар, укытып кына белем артмый диючеләр дә җитәрлек, милли телне кысалар, милләткә үсү мөмкинлекләре бирмиләр дигән кешеләребез дә борчылуда. Уку-укыту методикаларына үзгәрешләр, үзгәртеп корулар һәм заманага кулай формалар мәйданга чыкмый торып, бу тырышлыклар һәммәсе дә иске киемгә яңа ямаулык салудан гына гыйбарәт. Әле XIX гасыр ахырында гына бала-

ларны уку-язуга өйрәтү мәсьәләсе татарда кискен торган, аны Исмәгыйль Гаспринскийның «җәдит методы» чишкән. Моның шулай икәнлеген татар тормышыннан һәм мәктәп-мәдрәсәсеннән хәбәрдарлар бик яхшы беләләр. Бүген телләрне өйрәнүдә дә шундый ук яңа методлар мәйданга чыгарга тиеш. Дөрес, алар бар. Әмма эффектлы методика юк. Бу хәл әлбәттә халыкны борчый. Галимнәребез тырыша. Юлларны барлый, сыный. Талантлары ачылуны без дә көтәбез. Өметләр акланыр кебек.

Хикмәт телдә генә түгел, бәлки һәр кеше дә үзен бәхетле тоя торган җәмгыять төзи алуыбызда. Милли телебезнең яшәве һәм хөрмәтле булуы милләтебезне бәхетле итә, аңа башка милләт вәкилләре дә сокланса, күңелебез тагын да нурланып китә. Татар халкында кардәш һәм күрше-күләнгә хөрмәт белән яшәү рәвеше гадәт-йола, шәригать дәрәҗәсендә йөртелә. Нинди генә очракта да үзара хөрмәт хисен югалтырга ярамый — без моны барчабыз да яхшы беләбез һәм боларны Аллаһы тәгалә каршындагы дөньялык гамәлләребезнең берсе буларак аңлыйбыз.

*24.10.12.*

## КИТАП ТӘРБИЯСЕ

Билгеле булганча, кешелек җәмгыяте төрле төркемнәргә бүленештә үсә. Андагы һәр шәхес иҗтимагый берәмлек санала. Һәркемнең җәмгыятьтә үз урыны бар һәм, моңардан тыш, ул кеше тәрбия җимеше дә булып тора, үзен туктаусыз камилләштерү юнәлешендә эш итә. Шушылар аңа яшәү мәгънәсе һәм көче бирәләр. Бу исә һәркемнең тормышта шәхес икәнлеген раслап тора. Шуңа күрә дә кешеләр һәркайсы, шәхес буларак, үзара шәхсәни мөнәсәбәтләрдә яшиләр. Матур әдәбиятның көче дә шунда, ул, иң беренче чиратта, кешеләрне шәхес

дәрәҗәсенә куеп фикер йөртә, аларны әдәби герой-каһарман мәртәбәсенә күтәрә.

Кешелек тәрбиясендә ике төрле башлангычның барлыгы ачык билгеләнеп тикшерелгән. Аларның беренчесе — «табигый башлангыч», икенчесе — «культура-мәдәни башлангыч» дип аталалар. Аның икенчесен, башка төрле атап, «цивилизация башлангычы» исеме белән дә йөртәләр. Борынгы һәм урта гасырларда «табигый башлангыч»ка бары тик түбән катлам вәкилләре генә ия, алар шуның җимеше дип белсәләр, югары катлам вәкилләре үзләрен «мәдәниятле-культуралы», ягъни цивилизацияле шәхесләр буларак аерып йөрткәннәр. Моны ачык күрсәтүче билге сыйфатында аларның укымышлы, китап культурасына ия булулары, ягъни китап тәрбиясе алганлыклары факты хезмәт иткән. Шулай итеп, кемнәр укымышлы булсалар, алар цивилизацияле, ягъни культуралы, мәдәни саналганнар, кемнәр китап тәрбиясеннән мәхрүм калганнар яки җитәрлек дәрәҗәдә аны алырга өлгермәгәннәр, алар культурасыз, мәдәни түгел адәмнәрдән саналганнар. «Табигый башлангыч», шушы рәвешле, бик түбән дәрәҗә исәпләнелгән, чөнки аңа һәркем ирешә ала дип белдерелгән һәм бу һәрбер төркемнең яки җәмәгатьчелекнең үсеш дәрәҗәсенең шактый түбәнлеген күрсәтүче фактор буларак хезмәт иткән.

Дөрес, кеше, иң беренче чиратта табигать үсеше продукты, ягъни ул табигый үсеш процессын кичереп яши. Шул ук вакытта, берәүләр табигатьнең «эчендә» тәрбияләнә, ә икенчеләр аннан мәхрүм калалар. Табигать кочагында үскән шәхесләрдә «табигый башлангыч» төп рольне үтәү сәбәпле, аларда табигый сәләтләр дә күбрәк һәм көчлерәк булуын сиздерми калмаган. Шуңа күрә дә XVIII йөз мәгърифәтчеләре бу мәсьәләгә игътибар күзе ташлаганнар. Һәркемнең табигать тарафыннан сәләтле һәм талантлы булып тудырылуы аларда зур кызыксыну уяткан. Әмма кешедә табигый сәләтләр булу гына аз, аны «табигать башлангычы» гына камилләштерә һәм алга таба үстерә алмый, дигәннәр. Менә шунда һәркемгә «мәдәни башлангыч» ярдәмгә килә дә, ягъни кеше китап культурасына тартылырга, табигый сәләтен аң-белем ярдәмендә камилләштерергә тиеш булып чыга.

Бүгенге көндә болар берсе дә беркемгә дә сер түгел, кешелек тарафыннан инде ике йөз еллар элек хәл ителгән мәсьәләләрдән исәпләнәләр. Шунлыктан кешелек «табигый башлангыч» белән «мәдәни башлангыч»ны берләштерү, бер кысалар эчендә үстерү юнәлешендә эш итә башлаган. Талантны бары тик аң-белем генә камилләштерә һәм алга таба үстереп җибәрә ала. Әгәр дә аны аң-белемдә чикли башласак, ул кешенең табигый сәләте җанын шашындыра, акылын бутарга керешә. Бу исә кешенең харап ителүе, үз-үзен юкка чыгаруы дигән сүз. Шуның өчен дә һәркем табигый сәләтен үстерү белән мәшгуль булырга мәҗбүр. «Кеше китап укудан туктаса, фикерләүдән дә туктый»,— дигәннәр француз мәгърифәтчеләре. Алар китап укып аң-белем үзләштерүнең һәркем тарафыннан гомер буена алып барылырга тиешлеген раслаганнар һәм кеше табигатенең асылын китапка бәйләп ачык билгели алганнар. Димәк, матди ризык белән бергә, һәркемгә рухи азык та кирәк. Ә аны кешеләр китаптан табалар. Дөрес, табигать тә рухи азыкны бирә, әмма аны бик азлар гына табу, кабул итү көченә ия, андыйларны без «табигый талант ияләре» дибез. Әмма алар да «мәдәни башлангыч»тан читтә булмыйлар, аларның да язмышлары китапка, мәдәнияткә бәйләнгән.

Шулай итеп, ничек кенә акларга һәм акланырга тырышсак та, бүгенге цивилизация кысаларында калганыбызда, китаптан, китап тәрбиясеннән башка яшәү, үзеңнең дөньяда барлыгыңны раслау мөмкин түгел икәнлеген инкарь итә алмабыз. «Икеле»гә укыдык, «бишле»гә яшибез!»— дип мактанучылар да бар. Алар үзләре ия булырга өлгергән матди байлыкларына сокланып, әллә кемләнеп шулай әйтәләр. Әйтик, бик күп миллионнарың бар ди, рәхәтләнеп яшисең, имеш. Ә үзең томана һәм надан. Шушымы тормыш? Яшәү мәгънәң бары тик шунда гынамы инде? Җан бар бит әле, җан тынычлыгы. «Байда юләр күп булыр!»— диләр. Нәрсә хакында икән бу әйтем, уйланып карагыз әле!

Хәер, бу мәсьәләнең чишелешен кешелек үзенең тарихи үсеше таңында ук хәл иткән инде. Ул чорларда халыкларны китаплыларга һәм китапсызларга аерып йөрткәннәр. Язу барлыкка килү белән тарих башлана. Әгәр дә теге яки бу халык-

ның язуы булмаган икән, димәк аның моңа кадәр тарихы да булмаган, ягъни ул яшәмәгән дигән сүз бу. Шуңа күрә дә һәркем әүвәле анадан туа, аннары, язу таный башлагач, аның тормыш юлы башлана, диләр. Димәк, китаптан гайре, китаптан туктаусыз алына торган аң-белемнән, тәрбиядән башка кешенең шәхси тормышы була алмый икән. Бу закончалык шулай кабул ителгәннән генә түгел, ә бәлки безгә бәйсез хакыйкать, чынбарлык. Бу — кешелек җәмгыятенең төп баганаларыннан берсе, аны алып ташласаң, кешелек цивилизациясе җимерелә дә төшә.

Кешенең гомер буе иң ышанычлы юлдашы буларак китап санала. Әмма шунысы да бар, китапка тәмам мөкиббән китеп, бары тик аның гына колы сыйфатында калырга ярамый. Татар әдипләре электән, борынгыдан бу мәсьәләгә зур игътибар биреп килгәннәр, китапка карата шәхестә тәнкыйди караш та булырга тиешлеген таләп иткәннәр. Моның өчен китаптагы хакыйкатьне тормыш дөреслеге һәм замана барышы белән үлчи белергә өйрәткәннәр. Бу бигрәк тә, рухи тәрбиядә генә түгел, рухани тәрбиядә дә зур әһәмияткә ия. Рухани тәрбия дигәнебездә, дини тәрбияне күздә тотабыз. Ислам динендә Коръән һәм шәригать төп нигез баганалары булып торалар. Әмма шунысы бар, Коръәнгә һәм шәригать күрсәтмәләренә сукырларча табыну үзе үк дөрес гамәл түгел. Аллаһыга табынырга кирәк, табыну аңа гына тиешле. Ул үзенең барлыгын һәм белдерергә теләгәнен безгә тормыш хакыйкате аша бирә.

Коръәнне һәм шәригатьне борынгы һәм урта гасырларда ук галимнәр аңлата һәм шәрехли башлаганнар. Әмма аларның ул заманнардагы карашлары, заманага бәйле рәвештә, чикләнгән булган. Бүгенге көндә алар аңлаганча динне аңлату һәм аңларга тырышу хакыйкатьне инкарь итү юнәлешендә булырга тиеш түгел. Коръәнгә һәм шәригатькә таянырга бурычлыбыз, әмма аларга табынырга ярамый! Табынуыбыз бары тик бердәнбер Аллаһы тәгаләгә генә тиешле икәнлеген тагын бер кат кабатларга мәҗбүрбез. Бу мәсьәләдә пәйгамбәрләр дә, борынгы әүлияләр, имамнар һәм галимнәр дә күп тапкырлар кабатлап-кабатлап әйтеп калдырганнар. Димәк, китап ни кадәр генә изге булмасын, аңа табынырга хакыбыз юк икән. Хәер, бу хак-

та Коръән һәм шәригать гыйлемнәрендә дә туктаусыз искәртелә. Китап безгә мәдәнилек бирә, ул бары тик хакыйкатьне табуыбызга капкаларны ача. Менә шуңа күрә дә без китапка карата зур хөрмәтле булырга тиешбез. Хикмәт кешеләрнең хакыйкатькә ирешүендә һәм ирешүгә омтылуында түгелмени?

Төрле китаплар бар, аларның берләре аң-белем бирү өчен хезмәт итә, икенчеләре рухи яки рухани тәрбия өлкәсенә карый, өченчеләре матур әдәбият булып торалар. Әмма алар, кайсы гына төркемдә булсалар да, өч таләпкә җавап бирергә тиешләр: хакыйкатькә хезмәт итәргә, җанны хозурландырырга, акыл сафлыгын тудырырга. Әгәр дә болар юк икән, ул китаплар тарих иләгеннән төшеп калачаклар һәм кешелек җәмгыяте өчен әһәмиятләрен югалтачаклар.

Китапка мәхәббәт тәрбияләү иң беренче чиратта мәктәпнең төп бурычы санала. Балаларының бәхетле үсүен теләгән ата-аналар да тәрбия эшләрендә иң әүвәле китапка мәхәббәт тудырырга тырышалар. Моның өчен башта сабый балага күңелдән әкиятләр, кызыклы шигырьләр сөйләүне гадәт итәргә кирәк. Аннары китап аларга кычкырып укуга күчә барыла. Бала үзе укыр дәрәҗәгә җиткәч, аңа кызыклы булырдай әсәрләрне күрсәтеп бирергә тиешле.

Һәр бәхетле гаиләнең киштәлекләрендә китаплар була. Алар хәтта меңгә җитәргә мөмкиннәр, әмма йөз яки берничә йөз белән генә дә чикләнә алалар. Иң әһәмиятлесе, ул киштәлекләрдә үзегезгә кирәкле китаплар белән бергә, балаларыгыз тәрбиясе өчен хезмәт итәргә тиешлеләре дә саклансын. Искә төшкәндә генә түгел, көн дә шул киштәлектән китап алып укуыгызны гадәт итегез, укырга теләмәсәгез, игән актарып булса да чыгыгыз. Балагызда шул рәвешле китапка карата мәхәббәт уяна башлар. Әгәр дә китап тулы киштәлекләрегез булып та, башкаларга аларны алырга, укырга рөхсәт итмисез икән һәм үзегез дә ачып та карамыйсыз икән, бу бик күңелсез күренеш, томаналыкка илтүче туры юл булыр.

Китап кешегә аң-белем тапшыра, матур әдәбият тормыш тәҗрибәсе бирә, дибез. Һәм ул шулай да. Кеше дөньяда бер генә тапкыр яши, әмма аның һаман да моның белән генә чикләнәсе килми. Ә матур әдәбиятта нинди генә гыйбрәтле язмыш-

лар, нинди генә затлы кешеләр хакында сөйләнелми. Без аларны әсәрләрдән укыйбыз да, үзебез дә сизмәстән, шул геройларның кичерешләре, тормышлары белән яшәгәндәй булабыз. Моны гади бер иллюзия дип карарга ярамый. Бу — сәнгать! Ул тормышны күпкырлы, матур һәм сокландыргыч итүче сәнгать.

Матур әдәбиятны укыганда өстән-өстән генә күз йөгертеп барырга киңәш ителми. Шигырьме ул, романмы — аларның күңелгә үткәне яхшы. Шул вакытта аның тәэсире дә сиземләнелә. Укучы аның тәмен тойганда, «эченә» кереп китә. Шунлыктан балачакта ук әдәби әсәрләрне игътибар белән укый белергә өйрәнергә кирәк. Әгәр дә ул сезнең күңелегезгә тәэсир итү көченә ия түгел, уйландырмый, хис-тойгыларыгызны кузгатмый, каһарманнарының язмышы уртак кичерешләрне тудырмый икән, ул вакытта бу әсәргә карата тискәре тәнкыйди фикерләрегез тууы бик урынлы булыр. Бусы да яхшы күренеш.

Балаларны кече яшьтән китапка мәхәббәт хисе белән үстерергә кирәк, дибез. Моның өчен аларда кечкенәдән, әдәби әсәр укыганда, әдәби әсәрнең каһарманнары язмышы белән кызыксыну тудырырга тырышыйк. Укыган җирдән тукталып калып: «Менә ничек булган, нигә алай икән?»— дигән сораулар биреп, уртак кичерешләрне, уй-тойгыларны барлыкка китерергә тиешле.

Өй эчендә китап укучылар булмаса, балалар да китапка тартылмыйлар. Бигрәк тә эти кешеләр көндәлек матбугат белән кызыксынып барганда яхшы, әгәр дә шунда алар кайбер мәкаләләрне кычкырып укысалар, хәбәрләрне балаларына җиткерсәләр, игътибарлы булуларын таләп итсәләр, алга таба бу сыйфатлар балаларының үзләренә дә күчә башлар.

Балаларыгызның укый торган әсәрләрен кычкырып укуларын сорагыз. Бервакытта да: «Без моны укыдык инде, алга таба алай була, тегеләй була!»— дип аларны бүлдермәгез. Киресенчә, игътибар белән тыңлагыз. Хаталарын төзәтергә дә ашыкмагыз. Бәлки, шигегез төшсә: «Дөрес укыдыңмы икән, кабатла әле»,— диегез.

Кайберәүләр китап укуны, бигрәк тә калын романнарга балаларының «ябышуын» — вакытларын бушка уздыру дип аңлыйлар. Алар мондый чакта балаларының, китап укып, әдәби әсәрдәге каһарманнарның язмышы белән «яшәүләрен» аңлап җиткермиләр, аларның тормышлары, шуның белән бергә рухлары баюын да төшенмиләр.

Кешелек әгәр дә үзенә гомерлек юлдаш итеп әдәби әсәрләрне алган, начар дип исәпләнелгәннәрен тарихлардан төшереп калдырган икән, монда бернинди дә яманлык юк. Без барыбыз да үзебезгә кызыклы тормышны сайларга хаклыбыз. Әгәр дә сез үзегез, мәсәлән, укытучы булырга хыяллангансыз, әмма тормышта ул юлны сайлый алмагансыз икән, бер дә аптырамагыз һәм уфтанмагыз, бәлки укытучылар турында язылган әдәби әсәрләрне укыгыз, каһарманнарының тормышы белән аз булса да «яшәгез», хыялыгыз хакыйкать кебек кабул ителер, үзегезне мөгаллим яки мөгаллимә итеп тоярсыз. Ул күргән авырлыкларны, сөенечләрне уртак кичерерсез. Онытмагыз, әдәби әсәрнең максаты да шунда: ул безгә яшәү тәҗрибәсе белән бергә яңа бер «тормыш» бүләк итә, без аның «эченә» кереп яши башлыйбыз. Менә шуңа күрә дә берәүләр катлаулы эчтәлеккә ия әсәрләрне укырга яраталар, икенчеләренә җиңел рухлылары кирәк. Мәхәббәт тәҗрибәсен дә, яшәү мәгънәсен дә без әдәби әсәрләрдән алабыз, алар рухыбызны чиксез баеталар, яшәешебезне мәгънәле итәләр.

Иң катлаулы әдәби әсәрләрдән шигырьләр исәпләнеләләр. Аларда кузгатылган хис-кичерешләр вакыйгалар сөйләнеше белән куәтләнелми, лирик герой да катлаулы уй-тойгылар эченә «яшерелгән». Дөрес, шигырьләр арасында да «буш» әсәрләр булырга мөмкиннәр, яисә артыгы белән гадиләре һәм берәр вакыйганы сөйләп бирүгә корылганнары. Әмма монда да мәгънә дигән үлчәү берәмлеге хакыйкатьне танырга ярдәм итә. Әдәби әсәр, кайсы гына жанрда язылмасын, иң тәүдә мәгънәле, эчтәлекле, тирән фикерле, дөреслекне ачып бирүче, ялгансыз һәм риясыз булсын, шул чагында аның кыйммәте дә зур саналыр.

Милли әдәбиятлар ярдәмендә милли рух тәрбияләнә. Әгәр дә балагыз милли әдәбиятны аңламый икән, димәк, аның рухы

да милли хислэрдэн ерак, аннан килэчэктэ миллият хадиме чыгар дип көтеп булмый. Милли тәрбиясез калган бала тормышта чикләнгән була. Дөрес, милли хисләр кешегә яшәешендә комачау итә дип белдерүчеләр дә бар. Әмма мондый фикерләмәнең хаксызлыгын тарихлар ничәмә тапкырлар расладылар инде. Нәкъ менә милли хисләрендә тәрбия җитмәгән кешеләрдән шовинистлар, башка милләтләрне сөймәүчеләр һәм манкортлар барлыкка килә. Андыйларның тормышлары да мәгънәсез, рухсыз уза. Балада милләткә мәхәббәт тәрбиясен иң тәүге чиратта ата-аналар бирәләр, бары тик шуннан соң гына бу вазифаны матур әдәбият башкара ала. Шулай итеп, ата-ананың шәхси үрнәге балалар тормышында төп өлгеләрнең берсе булып кала бирә. Моны һич тә онытырга ярамый. Әгәр дә сез балагызны үзегез хакында күбрәк белсен дисәгез, әдәби әсәрләр арасыннан үз күңелегезгә иң ошаганракларын сайлап алып күрсәтә белегез. Алар да аны кызыксынып укып чыгалар икән, димәк, балаларыгыз сезнең хакта кызыксыналар, сезне яраталар һәм, иң кирәге, сезне күбрәк аңлый башларлар.

Әдәби әсәр укыганда күзегездән яшьләр килсә, яисә кычкырып көләргә туры килсә, хисләрегезне яшермәгез. Ул әсәрдә сөйләнелгән хәлләргә охшаш вакыйгалар тормышыгызда әгәр очрый калсалар, аларны җиңелрәк кабул итәрсез, бәяли алырсыз, күз яшьләрегез дә алай ук үзләрен сиздермәсләр, көлүегез дә гайре табигый булып бәреп чыкмас.

Китап кешене затлы итә, аның фикер офыкларын ача, яшәешенә мәгънә өсти. Боларны һичбер вакыт хәтердән чыгарырга ярамый. Ә нинди китапларны укырга, балаларында ни өчен кайсы китапларга мәхәббәт тәрбияләргә кирәклеген ата-аналар үзләре бик яхшы беләләр.

*Декабрь, 2004.*

## ТӨШЛӘР, ФӘН, ШИГЪРИЯТ

XIX йөзнең бөек психологы австрияле Зигмунд Фрейдның төшләр белән бәйле хикмәтле сүзләре бар. Ул үзенең «Психо-

анализ хакында»гы хезмәтендә «халыкның шигъри иҗаты төшләр белән бәйле аңлатылырга мөмкин» дигән фаразын белдереп уза һәм төшләрдәге символика белән мифлардагы-экиятләрдәге образ-сурәтләрнең туры килү мәсьәләсен дә кузгата. Аның укучылары, хезмәтләреннән төшләрне тәгъбир итү, ягъни юрауларын җыеп, «Сонник Фрейда» («Фрейд төшлеге») исеме белән аерым җыентык та бастырып чыгарганнар. Әмма аның аңлатмалары психоанализ юнәлешен тоталар, авыру кешенең эчке дөньясындагы үзгәрешләрне барлау, өйрәнү, бәяләү өчен кулланылалар һәм аларның хис-тойгыларына, аңсызлык халәтенә бәйле холкын аңлатуга корылганнар. Димәк, һәркемгә кирәргә мөмкин «шайтаный төшләр»нең эчтәлегенә төшенергә омтылудан туган юраулар алар.

З.Фрейдның төшләр белән бәйле фикерләре безне заманында шигъри символиканы тикшерү һәм бу эшне фәнни нигездә алып баруга этәрде, әдәбият өлкәсендә дә көтелмәгән ачышларга китерде. Аларны «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» дип аталган хезмәтебездә (бу китап әүвәле 2000 нче елда шул исем белән Казанда Татар дәүләт гуманитар институты нәшриятында, аннары 2003 нче елда «Урта гасырлар татар әдәбияты: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» исемендә шулай ук Казанда «Раннур» нәшриятында дөнья күрде) бәян итеп аңлатып язып чыктык. Болардан тыш, практик әһәмияте киң булган «Төшлек: Төшләрне юрау китабы» исеме белән аерым том рәвешендә 1997 нче елда (шул ук «Раннур» нәшриятында) махсус китабыбыз, басылып чыгып, халыкка барып иреште. Андагы төшләрнең символларын аңлау һәм аңлатулар урта гасырлар татар «Тәгъбирнамә»ләре («Төш юрау китаплары») нигезендә төзелгән иде.

Шагыйрьләр образлар һәм символлар телендә фикер йөртә. Алар, тормыш һәм табигать күренешләрен ачып, көтелмәгән чагыштырулар ясыйлар. Шушы рәвештә хакыйкатьне тасвирлап бирәләр. Әсәрләре чын мәгънәдә күңелдән, җаннарының кодрәте белән дөньяга чыкканнармы-юкмы икәнлеген белергә теләсәк, моның өчен нинди уйларда булуларына һәм укучының хисләрен ни рәвешле кузгата алуларына игътибар

ителә. Шигырьләренең эчтәлеген төшенү мәсьәләсенә килгәндә, тасвирлаган күренешләренең образ һәм символларын ачыклау таләп ителә. Шигырь чыннан да талантлы шагыйрь тарафыннан тудырылган икән, ул әлбәттә рух куәтенең җимеше булып тора. Ә рухның теле — төшләр теле кебек үк. Төшләрдәге образ һәм символларның тәгъбирләре-аңлатмалары белән шигырьдәге образ һәм символларның мәгънәләре үзара тәңгәл киләләр. Борынгы заман әдипләрен укысак та, урта гасырлар дәверенеке дә, соңгы елларныкы да — һәммәсендә дә бер үк тәртип: шигырь символикасы мәгънәләре һәм төшләрнеке бер үк төрдәләр. Бу үзенчәлек кеше рухы-җанының теле бер генә төрле була икән дигән фикерне алга чыгара. Дөрес, талантсыз шагыйрьләр әсәрләрен рухи сәвек, күңел омтылышы белән түгел, бәлки акыл эшчәнлеге сәбәпле мәйданга чыгаралар. Әлбәттә акыл дигәннәре дә әллә ни югары дәрәҗәдә түгеллеген сиздерә. Аларның язмаларының «ясалма» булулары да бик үк ачык тоелмаска мөмкин. Моны төшенеп алу өчен төшләрнең символик эчтәлеге белән бәйле анализ, әдәби күзәтүләр ясау да җитә: «серләре» ачыла да китә.

Әдәбиятның күңел эшчәнлеге генә булмыйча, акыл хезмәте дә икәнлеген онытып җибәрергә ярамый. Саташулы төшләр булган кебек, күңелгә генә таянылганда, әдипләрнең дә фикерләрендә «саташканнары» бар. Күңелгә генә таянудан тыш, акыл иләге аша тасвирларны уздыру ярдәмендә фикер төгәллегенә ирешү язмалар өчен мәҗбүри шарт рәвешен алырга тиешлеген дә онытырга ярамый.

Әдипләр күңел, рух көченә генә таянып иҗат итү дәвереннән узып, акыл эшчәнлегенә дә таянуның зарури икәнлеген бүгенге көндә яхшы аңлап эш итәләр. Әмма, шул ук вакытта, дөнья әдәбиятларында рухи эзләнүләргә зур игътибар бирелә, хәтта «галлюциноген реализм» дигән иҗат юнәлеше дә мәйданга чыкты һәм һәртөрле рухи фантазияләргә корылган яңа төр әдәбиятның укучы күңеленә якынрак икәнлеген әдәби үсеш тенденцияләре ачык раслыйлар. Рухи сәвек юнәлешендә туган әдәби әсәрләргә алдынгы халыкларда зур игътибар бирелә. Күңелгә, аның бигрәк тә образлы-сурәтле

«фикерләвенә» мөмкин кадәр ирек бирә алган әдипләрне дөньяви карашлы укучылары күкләргә күтәреп мактый, аларның әсәрләре барчаларны диярлек сокландыралар. Могҗиза үзе гадәти шартларда яши, тормышны үзгәртүче куәт рәвешендә яшәешкә килеп керә.

Дөньяда әдипләр арасында рухи көчләрен күрсәтү ягыннан «ярыш» бара. Ул киңәя, яңадан-яңа халыкларның әдәбиятларын үз мәйданына ала. Әдәби әсәрләр, алар инде тарихимы, әллә бүгенге көн хакындамы — барысы да диярлек «төш форматын» алган рәвештә иҗат ителә башладылар. Бу фактлар чынлыкта рухның, акыл һәм зиһеннән аерым да, үз мантыйгында, үз дөньясында яши алуын кат-кат раслыйлар.

Шулай итеп, кеше йокыда вакытта күргән төшләр, асылда, акыл, аң, зиһен эшчәнлегенең тукталып торганында, рухның үз хезмәтен дәвам иттерүе хакында сөйли. Борынгы антик дәвердә үк бөек акыл иясе Аристотель бу мәсьәләгә игътибарын юнәлткән һәм кеше йоклаганда, аның җаны, тәненнән чыгып китеп, киләчәккә сәяхәт итә, тәнгә кире кайткач, бар күргәннәрен сөйли, шул сөйләүләре төш күрү була дип аңлаткан. Бу рәвештә мифологик күзаллаулар башка халыкларда да киң таралган. Мөселман өммәтләре төшләрнең аерым фәрештәләре бар дип күзаллаганнар һәм ул фәрештәләр, Аллаһы тәгаләнең тәкъдир китабын укып, кешеләргә яхшылык һәм ярдәм йөзеннән әлбәттә, укыганнарын адәмиләргә төшләрендә килеп сөйләүләрен бәян иткәннәр.

Бүгенге фәндә бу өлкәдә кызыклы эзләнүләр бара, кешенең баш миендә күзаллаулар өчен җавап бирүче үзәкләрдә импульслар хәтта наркоз белән йоклатылган очракларда да, тәннәре өшетелеп, берни сизмәс хәлдә калганда да сүнмәвенә игътибар биргәннәр. Хис-тойгылар тулысынча ябылганда һәм югалганда да кешенең рухы-җаны һаман үз көчендә кала дигән сүз бу. Димәк, төшләр күрү — рухның куәтен, аның ни дәрәҗәдә булуы хакында да сөйли икән. Ә төшләр күреп, аларны юрауны дин дә, фән дә тыймый. Аларның киләчәкне аңлауга хәбәр булуын бәхәс итү әлбәттә урынсыз санала.

Төшләрне дөрес юрау мәсьәләсенә килгәндә, бу эш шактый җаваплы санала һәм аның да берничә шартка буйсынуы таләп

ителәә. Беренчедән, туганнар туганнарының, аналар һәм аталар балаларының, балалары ата-аналарының төшләрен юраудаһичшиксез ялгышачаклар, чөнки алар һәммә нәрсәне үзара яхшыга гына чыгара алалар, начар булуын теләмиләр. Икенчедән, бозык кешеләр изге затларның төшләрен юрый алмыйлар, чөнки алар һичкемгә яхшылык теләмиләр, яманлык ирешүен генә өмет итәләр. Өченчедән, надан һәм дивана адәмнәрдән төшләрне юратырга ярамый. Үз төшеңне үзең юрау да хаталы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин, диләр.

Төшләрне юраучылар рухи яктан чиста, саф, изгелектә хөрмәтле, зиһендә яхшы булырга тиешләр. Бер кешенең төшен икенчесенә сөйләмәскә, ишеткәнен һәм әйткәнен онытырга бурычлылар. Әгәр кемдер үз төшен халык арасында сөйләп, юраучының төшләрне дөрес аңлатуын сынийсы килә икән, бу — төшен сөйләүченең үз эше, әмма болай итү мәликләргә генә төс, чөнки мәликләрнең күргән төшләре үзе өчен генә түгел, ил халкына да бәйле. Халык алдында сөйләнгән төшнең тәгъбире дә халык язмышына тәэсир итми калмаячак. Бу кагыйдәләр исә шагыйрьләрнең әсәрләренең хикмәтен дөрес аңларга кирәклекне дә алга чыгара түгелме?

*2012.*

# УЗГАН ГАСЫР АХЫРЫНДА ШИГЪРИЯТЕБЕЗ

XX нче йөзнең ахыры татар әдәбиятында шигърият моңа кадәр күрелмәгән эчтәлек һәм форма яңалыклары, инде онытылган һәм кызыксыз-әһәмиятсез кебек тоелган Урта гасырлар традицияләренең яңарышы белән үзенең өстенлеген күрсәтте. Рәдиф Гаташка, Роберт Әхмәтҗановка һәм Лена Шагыйрьҗанга, Рифә Рахманга хас булган кайнар канлы шигъриятебез дә, Илдар Юзеевнең, Роберт Миңнуллинның, Ренат Харисның, Флера Гыйззәтуллинаның үзенчәлекле сабыр холыклы шигырьләре дә үлмәс җырлар кебек халык күңелендә зур дулкынлану, мәхәббәт һәм соклану хисләрен яңарттылар. Шигъриятне халык укымый дип ничек кенә гаепләмәсеннәр һәм аны әдәбият мәйданыннан чыгарып ташларга ашкынмасыннар, ул һаман дәрәҗәсен киметмәде. Шагыйрь Зөлфәтнең иҗаты нәкъ шушы туксанынчы елларда яңа формалары һәм тагын да тирәнрәк эчтәлеге белән татар халкын кабат сокландырды. Кайвакытта күңелгә шундый фикер килә: татар шигърияте тарихында гүяки Зөлфәт кебек шагыйрь әлегә дөньяга килмәгән иде! Дөрес, болай дип әйтү хакыйкатькә бераз хилафлык итү дә әле ул, әмма анда хаклыкны бөтенләй юк дип белдерү шулай ук хата булыр иде. Әйе, һәр талантлы шагыйрь — кабатланмас, үзенчә даһи, үзенчә бөек. Зөлфәт шундыйларның берсе.

Ул елларда Зөлфәт үзен иҗаты белән чыннан да бөек шагыйрь итеп танытты, аның исемен Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Х.Туфан, С.Хәким, Г.Авзал, Ш.Галиев, И.Юзеев ирешкән биеклеккә һичбер шикләнүсез куя алабыз. Минем бу фикерем икенче бер бөек шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовка заманында ошамады, шулай да аны: «Әфләтүн миңа — дустым, әмма хакыйкать — өстенрәк!»— дип кенә юатырга тиеш идем. Иҗат эше индивидуальлеккә корыла, шәхескә бәйле. Зөлфәтне

М.Әгъләмов, М.Әгъләмовны Зөлфәт алыштыра алмый һәм шулай ук берсенең бөеклеген икенчесенең даһилыгы күләгә астында калдырмый.

I

XX гасыр ахырында дөнья да башаяк килеп буталып алды. Мәңгелек кебек тоелган үзкыйммәтләрнең күбесе юкка чыкты, аяк астына салып тапталды. Ә менә борынгыдан ук килгән кыйммәтләр кабат үз киштәләренә күтәрелделәр. Бу хакыйкать һәммәбезгә һәртөрле «изм»нарның вакытлы булуын йөзгә бәреп дәлилләде. Сәбәбе нәрсәдәндер, белмим, китаплары чыгып торса да, Р.Вәлиевнең яңа шигырьләре халык игътибарына тәкъдим итәлмичәрәк торды, Л.Зөлкарнәйнең дә шигырьдән китүе сәерсендерде. Ни өчендер М.Шиһапов белән Н.Касыймов бары тик җыр текстлары язу белән генә канәгатьлек таптылар. Р.Юнысов та укучыларын бик сирәк искә ала, шигырьләрен бөтенләй дә бастырмый, диярлек иде. Әллә язудан туктадылар инде дияргә калды.

Татар халкының шигъри тел мөмкинлекләре шактый киң булуы ул елларда тагын бер кат үзен раслады. Сүз гарәп-фарсы алынмаларының телебезгә һич тә ят һәм чит булмавы хакында да бара. Бу яктан мәҗнүн шагыйрь Р.Гаташның шигърияте мактауга лаек. Аның бер-бер артлы томлыклар дәрәҗәсендә басылып чыккан газәл, робагый, кыйтга, мәснәви, мөнәҗәтләре бергә тупланган күркәм мәҗмугалары татар укучысын ихластан үзләренә җәлеп иттеләр.

Р.Гаташ яңа шигъри сулышы белән әдәбият бакчасында яңа бер әдип кебек яңача балкыган талантын күрсәтте. Ул инде хәзер без элек белгән Р.Гатауллин гына түгел. Аның шигърияте кабат яз вакытын кичерә, иҗаты шигъри чәчәк бакчалары кебек күңелләрне җәлеп итә, сокландыра. Гарузда язылган шигырьләр кайчандыр иске заман калдыгы кебек тоела иде. Р.Гаташ үзе дә андый рухта һәм үлчәмдә язылган шигырьләрне Гатауллин чагында инкарь итә иде. Әмма күңелендә газәлләр һәм робагыйлар туа башлагач, фикерен үзгәртергә мәҗбүр булды. Рөстәм Сүлти дә Шәрык шигърияте стихиясенә чумды.

Тарих безнең һәркайсыбызның башыннан гына түгел, йөрәге аша узды һәм уза тора. Заманаһы төрлечә аңлаган кебек тоелсак та, асылда һәммәбез дә бер үк хәлдә идек.

Публицистик шигърият остасы, заман белән син дип сөйләшергә яраткан М.Әгъләмов, Ә.Габиди һәм Нияз Акмалов та элекләрне Кызыл байракны шигъриятләрендә югары чөя торган иделәр. Шагыйрь Зөлфәт тә Ленин темасы белән озак еллар саташты. Әмма Р.Харис кебек урыс алдында ант суларын һәр шигыре саен диярлек эчкән башка шагыйрьләрне дә, М.Гафуридан алып Р.Зәйдуллага кадәр барлаганда, бик күпләп атап китәр идек. Ул шигырьләр ихлас күңелдән язылмаган иделәрме?

II

Һәр заманның үз төсе, үз стихиясе һәм, һичшиксез, үз җыры бар. Халыкның хис-тойгыларын һичнинди карар һәм фәрман белән үзгәртеп тә, теләгән якка борып җибәреп тә булмый. Дөрес, халыкның аңы белән идарә итәргә мөмкин. Әмма хис-тойгыларына бары тик шагыйрьләре, әдипләре генә хуҗа. Шуның өчен дә әдәбиятның иҗтимагый функциясе әйтеп бетергесез дәрәҗәдә зур. Чөнки әдәбият рухи материал белән эш итә. Талантлы шигырьнең йөрәк тибеше халыкның хис-тойгылары белән туры килә.

Шунысы да бар, «агач шигърият» кушаматын алган, төзеклектә, рифмада, ритмда һичбер хилафы күренмәгән, акылга һәм аңга корылган, бары тик мөкатдәс хистән, эчкерсез хис бирәмлегеннән мәхрүм калган шигырьләр халык күңеленә үтеп керә алмыйлар, шагыйреннән, заманыннан алда үләләр. Шигырь гыйлемен белгән һәркем шигырь төзи ала, әмма тудыра гына алмый. Соңгы вакытларда андый шигырьләрне төзүчеләр, сүз иреге шартларыннан беренчеләрдән буларак файдаланып, үз җыентыкларын укучыларга тәкъдим итә тордылар. Шунысы гыйбрәтле, андый китапларга исемнәре халыкка мәгълүм шагыйрьләребез үзләре үк юл бирүче, сүз башы язучы, хәтта редакторлары икәннәр бит.

Эзләнү, камиллеккә омтылу максатында эшләнгәнлектән, андый әсәрләрнең кайберләрен мактап та телгә алырга булыр

иде. Шулай да талантсыз каләмнән төшкән ул «шыгырлар» бары тик сафсата арбасының таралам-таралам дип шыгырдавын гына хәтерләтәләр. Аларны укыганда, акрошигырь осталары Ш.Галиевнең һәм Р.Миңнуллинның, Л.Зөлкарнәйнең мәгънәле иҗатларына кабаттан хөрмәт һәм соклану хисе яңара.

Чын шигырьнең ясалма әсәрләрдән өстенлеге хис һәм тойгыларны күңелгә ирештерә алуында. Салкын кыштан соң килгән назлы яз ничек тирә-юньне чәчәккә һәм ямьгә төрсә, шигырь дә хәтта сүнгән җаннарны кабат балкыту көченә ия. Безнең тәнкыйтьтә шигырьгә карата фәлсәфи шигырь, публицистик шигырь кебек бәяләр бирү очраклары бар. Алар инде фикер әйтү өчен кулланыла торган терминнар рәвешендә дә кулланыла башладылар. Әмма шуны онытырга кирәкми, шигырь юк икән, ул хис һәм тойгыларга корылмаса, аны коры фәлсәфә һәм публицистика гына шигырь ясый алмый.

Фикерне рифмалаштырып, ритм таләпләренә генә кысалап язудан андый әсәрләр шигырьгә әверелми. Р.Фәйзуллин, К.Латыйп, Акъегет, Р.Миңгалим, А.Хәлим үз иҗатлары белән ирекле һәм ак шигырьнең яшәү стихиясен һәм мөмкинлекләрен әдәбиятыбыз мәйданында күптапкырлар дәлилләделәр. Шигъриятебезнең нәкъ шушы өлкәсенә көтелмәгән җирдән тыелгысыз агым кебек математик Җ.Сөләйман килеп керде. Ул — яңа бер сулыш. Р.Бохараев та, Лондонга китеп, монда тапмаган туган тел кадерен анда тапты, хәтта борынгы төрки имлясында — гарәп графикасында, хәзерге татарча яза башлады.

90 еллар ахырының сөенече булып шагыйрь Р.Фәйзуллинның бер-бер артлы күптомлыклары дөнья күрделәр. Аның дүрттомлыгын әдәбият белән даими кызыксынып баручылар югары бәяләделәр. Инде бишенче томы да әзер һәм ул бары портретлардан гына тора икән дигән сүзләр йөри. Сүз әдәби портретлар хакында бара булса кирәк.

Г.Абзалның, Ш.Галиевнең, И.Юзеевнең дә күптомлыкларын күрәсе, укыйсы килү теләге уянды. Әдәбиятның, аерым алганда татар шигъриятенең үсешен нәкъ шушындый факторлар билгели түгелме?

III

Мәдәниятне бездә икенчел, хәтта болай да таралам-таралам дип сөйрәлгән тормыш арбабызның бишенче тәгәрмәче итеп танытырга теләүчеләр, хәтта моңа ианып яшәүчеләр бар. «Матурлык дөньяны коткарыр» дигән хакыйкатькә алар көлеп карыйлар, ә үзләре җаннарын саклар өчен шайтан авызына да керергә әзерләр. Тышкы матурлык түгел, бәлки эчке, күңелнең, җанның матурлыгы дөньяны һәлакәттән һичшиксез коткарачак.

Шигърият ул —әдәбиятның җаны. Ә әдәбият — мәдәниятнең җаны. Ә мәдәният үзе җәмгыятьнең җаны. Һәр адәмнең дә үз җаны бар. Бер җаныбызны асрау өчен утларга гына да, суларга гына кермибезме?

Гасырны тәмамлаучы соңгы дистә елда Заман ахыры килде, тормышыбыз хакыйкатьне аңларга үзе өйрәтә башлады. Һәрвакыт беренчел урынга куелган сәнәгатебез, иктисадыбыз ишелеп төште. Иҗтимагый аңны ничек кенә һәм нинди генә юллар белән үстермәгән, күңелләрдә ныгытмаган иделәр. Әмма хисләребез барыбер өскә чыкты, ташып, орылып-бәрелеп кайнап күтәрелде һәм дөньяны бутап ташлады. Тыныч холыклы З.Мансуров та, Ш.Маннапов та, Р.Низамиев та, Җ.Дәрзәманов та кайнарланып алдылар.

Ул елларда әдәбият мәйданына шагыйрьләрнең күбрәк күтәрелүен, прозаның чагыштырмача кечерәеп калуын әдәбият белән кызыксынучылар белеп, сөйләп, язып торалар. Хисләрнең җәмгыятьтә алгы, беренчел планга чыккан дәверендә бүтәнчә була да алмаган. Укучыны шигырь кызыксындырмый, шигъри әсәрне укымыйлар дип белдерүләр дә хакыйкатькә һич туры килми икән шул. Әллә Роберт Әхмәтҗановны, Н.Әхмәдиевне, Н.Гамбәрне, Г.Садәне, Ә.Маликовны, Г.Рәхимне, Г.Мөхәммәтшинны укымый иделәрме? Әллә Фирая Зиятдинова, Фәйрүзә Исмәгыйлева, Асия Минһаҗева, Энҗе Мөэминова, Бикә Рәхимова, Эльмира Шәрифуллина, Асия Юнысова, Марс Шабаев, Азат Ганиев иҗаты укучылар күңелә ят идеме? Нәрсәне-нәрсәне, әмма шигырьне татар халкы укудан, ятлаудан, тыңлаудан туктаганы булмады. Укучыларның үзләренең дә кулларына каләм алып, шигырь белән матбугат һәм ра-

дио-телевидение аша якыннарын котлаулары да бу хакыйкатьнең мәртәбәсен күз алдына китерергә ярдәм итә. Талантлы язучы һәм шагыйрь Хәйдәрнең әдәбияткә, сәнгатькә, шигъриятебезгә багышланган тапшырулары, шагыйрә Шәмсия Җиһангированың, Гадилә Бадикованың радиочелтәрдәге интервьюлары кайсыбызны битараф калдыра иделәр? Талантлы әсәрләрнең дәрәҗәсен укучыга сиздерү өчен үзеңнең дә таланттан мәхрүм булмавың шарт. Затлы туфракта чүп тә, алтын башак та, чәчәкләр дә үстерергә мөмкин. Яхшы шигырь затлы туфрак кебек ул, шифалы яңгыр сыман, җаннарны сүндерми балкыту көченә ия.

Әмма, таланлы шагыйрьләр дәверендә яшәсәк тә, яхшы шигырьгә, халыкның хисләренә туры килә торган шигырьләргә мохтаҗлык һәрвакыт булды һәм булачак. Татар шигъриятендә талантка мохтаҗлык Кол Гали заманында да, Г.Тукай чорында да бар иде. Бу таләп бүгенге көндә дә канәгатьләндерелде дип әйтеп булмый.

Талантлы шагыйрьләр чорында талантка мохтаҗлык тагын да зур. Бу мохтаҗлык шигъриятебездә даһилар саны күбрәк булган саен артачак. Шагыйрь Фәнис Яруллинга сокланганбыз икән, аның янында бүтәннәрнең исемнәрен тагын да санап, Х.Әюповны, Ә.Гаделне, Р.Зәйдулланы, М.Мирзаны, Г.Моратны, Г.Гыйльмановны, Р.Газизовны, Х.Хисмәтулланы, Ф.Дунайны, Н.Мәдьяровны, М.Вәлиевне, Р.Вәлиеваны, Л.Леронны, Р.Вәлиуллинны, Ф.Әнәкне, Д.Гарифуллинны, И. Иксанованы, Ф.Мөслимованы, Р.Закировны, Р.Шәриповны, М.Разовны, Р.Бәшәрне, М.Газине һәм башкаларны атыйбыз икән, бу әле аларның арасыннан ике-өченә шигъриятебез таҗын киderткәнбез дигән сүз түгел. Чөнки бер талант икенчесен алыштыра алмый. З.Мәҗитов, К.Латыйплар кебек өлкән буын шагыйрьләребез янәшәсендә яшьләребезнең дә булуы, Энҗе Абзалина, Җансуар, Нияз Вәлиев, Галиәхмәт Шаһи, Зөләйха Минһаҗева, Рәис Апушларның барлыгы да сөендерә башлады. Татар шигыре — йөрәктән-йөрәккә күчеп, буыннан-буынга яшәреп яши, яшәргә тиеш, моңа хакы барлыгын мең кат дәлилләгән шигърият ул!

Иҗат эше, бигрәк тә шигърият — бәхәссез, шәхсәни күңел җимеше, һәркайсы шигырь — кабатланмас, һәркайсы чын шагыйрь — талант иясе. XX нче йөз башы шагыйрьләреннән Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиевнең кайсына да берсенә генә аерып даһилык таҗын хәтта бүген дә кидерә алганыбыз юк. Моның кирәге дә күренми. Алар һәркайсы даһи, үзенчәлекле талант, шагыйрь таҗын киеп дөньяга килгән шәхесләр. Бүгенге көн шагыйрьләребездән дә кемнедер берсен генә менә бу — бердәнбер, менә ул гына даһи, дип әйтә алмыйбыз. Әмма һәр шагыйрьгә таләп бер генә: ул кабатланмас, моңа кадәр булмаган һәм булуы мөмкин түгел шәхес сыйфатында мәйданга чыгарга тиеш, татар шигъриятенә генә түгел, дөнья әдәбиятына да яңа бөеклек ишекләрен ачып, хакыйкатьнең асыл мәгънәсен ачып бирергә, җаннарны сыкрату яки күкләргә чөелү дәрәҗәсенә җиткерергә тиеш.

Шигъриятебездә, шик юк, Н.Нәҗминең, К.Булатованың, Г.Зәйнәшеванын, С.Гәрәеванын да булуына мең кат сөенергә тиешбез. Минем күңелгә һәр татар шагыйренең затлы шигърияте якын. Шигырь җыентыклары белән Хәмид Вәлиди, Нәҗибә Сафина, Флера Гатина, Флера Тарханова, Наилә Ахунова, Рәшит Гариф соклану һәм горурлану хисләрен уяттылар. Чүпрәледә яшәп иҗат итүче шагыйрь Сираҗиның «Сонетлар»ының кайнарлыгы хәйран калдырды. Һәр төбәктә, мәдәни административ үзәкләрдә шигъри антологияләр басылу шатландыра. Т.Миңнуллинның сөю-сәгадәт белән мавыгып китүенә, җанын шигырь хөкеменә тапшыруына көнләшми мөмкин түгел. Әгәр дә кемдер татар шигыренә күсәк күтәрергә уйлый икән, аның бөеклеген аңламый икән, ул кешегә Фәнис Яруллинның шигырьләрен укып җанын савыктырырга киңәш итәр идем. Болар барысы да XX гасыр ахырының ачык хакыйкатьләреннән иделәр.

## IV

Без XX нче гасырда да яшәдек. Олы бер дәверне — тетрәнүләр, сугышлар, туктаусыз сүтелү, үзгәртеп корулар, бер яктан икенчесенә капланулар, каршылыклар, милли-азатлык хәрәкәтләре, кан, күз яше, бәддога һәм догалар дәверен

тәмамлап киләбез. Әгәр дә бу юлдан барсак, XXI нче гасырны да зур сөенечләр китерәчәк йөзъеллык дип әйтә алмаячакбыз.

Шушындый да катлаулы һәм каршылыклы дәвердә халыкның бердәнбер куанычы, күңелен җылыткан учак — халыкчан әдәбият һәм шигърият булды. XX нче йөзне фән-техника революциясе дәвере дип атасалар да, асылда ул һаман да тираннар гасыры хәлендә калды. Аны акыл гасыры дип атый алмыйбыз. Тираннарны һәрвакыт әдәбият коткыга салган. Әдәбиятка көчләре җитә алмаслыгын сизеп, алар хәтта аңа хезмәт итәргә дә маташып карадылар. Чын әдәбият — Кешелек ул. Шунлыктан чын әдәбият һәрвакыт һәм һәркайда тиранга күкрәге белән каршы чыга. Кешелек дәвереннең иртәгә-бүген генә килеп җитмәячәген һәркайсыбыз яхшы аңладык бугай инде. Тантанага иртәрәк. Шигъриятнең тантанасы Кешелек дәвере ирешкәч булачак.

Чын әдәбиятны бары тик талантлар гына тудыра ала. Ул һәрвакыт шулай: Тиран белән Талант һәркайда каршылыкта була. Шигърият — талантлар мәйданы, тираннарның котын алган өлкә. Әйе, шагыйрь үзен, хәтта халкын саклап калу өчен тиранга дан җырларга мәҗбүр, әмма ул моның белән шигъриятне саклап калам дип уйласа — тирән ялгыша. Шигърият өстендә яткан андый тузаннар замананың аз гына селкенгән җиленнән тузгый да бетә. Шигърият, көзге кебек, кабат балкып кала. Тираннар һәм аларга хезмәт итүчеләр моны яхшы беләләр, шигърият көзгесен ничек тә ватып, бозып ташларга телиләр, хәтта халык исеменнән шигъриятккә каршы эш җәелдерәләр.

Холкында тиранлык чалымнары булган кешене мин, шәхсән, талантлы шагыйрь дип күз алдыма китерә алмыйм. Кешелеклелекне инкарь иткән кеше кешелекле була алмаган кебек, Җанны инкарь итүченең җаны барлыгына ышану мөмкин түгел.

Татар шигърятенә төрле яклап һөҗүмнәр ясалган XX йөзнең соңгы дүрт-биш елы эчендә әдәбиятыбызда исә нәкъ шигърият үсеш алды. Шулай ук Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең дә бер-бер артлы бары тик шагыйрьләргә генә бирелгәнлеген күрербез: Р.Харис, Р.Миңнуллин, Ә.Баян...

Соңгы елларда, башка жанрлар белән чагыштырганда, шигырь җыентыклары китап буларак күбрәк чыгарылды. Болар шигъриятебезнең үсешен, офыклары киңәйгәнен дәлилли торган факторлардан түгелмени? Шигърият — әдәбиятыбызны әйдәп баручы, камиллек өлкәсе булып кала бирә.

V

XX гасырның соңгы елларында бер-бер артлы өч поэмасы белән («Сөембикә», «Кол Шәриф», «Мөхәммәдъяр») Ә.Рәшит үзенең мәгънәле шагыйрь булуын халыкка тагын бер кат танытты. Г.Исхакый исемендәге мәртәбәле премияне алды. Бу премиянең бары тик талантлы әсәрләргә генә бирелүе шулай ук сөендерә.

Тарихи теманың җаваплыгы зур. Шунлыктан анда һәр мәсьәләгә аерым игътибар белән килергә, тарихи үсеш рамкаларыннан чыкмый иҗат итәргә кирәк. Һәр халыкның да үз тормышы иҗатын, ягъни тарихын, бөек һәм матур итеп күрәсе килә. Шушы омтылыш сәбәбендә күп кенә шагыйрьләр, үз халкын күтәрү өчен әлбәттә, бүтәннәрне мескен итеп күрсәтүгә алыналар. Мондый әсәрләрнең, аларны ничек кенә мактамасыннар, гомерләре кыска була.

Соңгы елларда тарихи темага бәйле язылган поэмалар һәм шигырьләр аз булмады. Арада телгә алырлык уңышлылары да бар. Әмма күпчелеге беркатлырак иде. Тарихи темага драматик поэмаларның да иҗат ителүе сөенеч тудыра. Бу өлкәдә дә уңышлар җитәрлек. Хәер, анысы хакында сөйләшүне башка мәкаләгә калдырабыз.

VI

Шигъриятнең камил үсеше өчен әдәби мирасыбыз белән халыкның яхшы танышлыгы, бу өлкәнең уңышларга ирешкән булуы шарт. Күпләребез хәтерлидер, Г.Тукайның томлыклары 1986 нчы елларда басылып чыкканнан соң, татар шигъриятендә үзенчәлекле бер чистарыну, күтәрелеш күзәтелде. «Идегәй дастаны» белән бәйле дә шундый ук хәл кабатланды. Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ы халыкка кайтарылгач та шундый ук рухи үзгәрешләр булган иде. Инде Кол Шәрифнең

әсәрләре, Мөхәммәдьяр бине Мәхмүднең поэмалары, Котбинең «Хөсрәү вә Ширин»не, Сәйф Сараи әсәрләре, Сайадинең «Дастаны Бабахан»ы да халыкка кайтарылды. Бу өлкәдә элегрәк Татарстан китап нәшрияты зур эш башкарган булса, гасыр ахырына «Мирас» журналы һәм «Раннур», «Мәгариф» нәшриятлары да төп йөкне үз җилкәләренә алдылар, бу изге эштә рәсми нәшриятка кушылдылар. Шигъри мирасыбызны халыкка җиткерү өлкәсендә Н.Юзиев, Х.Госман, Р.Гайнанов күп тырышлык күрсәткән иделәр. М.Госманов, Х.Миңнегулов, Ә.Шәрипов, М.Гайнетдинов, З.Рәмиев, М.Әхмәтҗанов, Н.Хисамов кебек мәртәбәле галимнәребез дә, Р.Даутов та бәяләп бетергесез зур эшләр башкардылар һәм шушы авыр өлкәне даими күтәреп барырга тырыштылар.

Кызганычка каршы әле һаман да әдәби мирасыбызның тулы килеш халыкка кайтарылганы юк. Г.Гыйльманов Татарстан китап нәшриятында «Әдәби мирас» томлыкларын даими чыгарып баруны оештырган иде, бу эш тә тукталып калды. Финанс кыенлыкларын кичерү чорында яшәү үзен сиздерә, икътисадый авырлыклар иң беренче булып рухыбызга һөҗүм итә, аны гарипли. Шул ук вакытта, әдәби мираска бәйле сүз чыкса, акча юк дип кенә әйтү, кырт кисү хата булыр иде. Әдәби мирас китаплары сатылалар, укылалар. Әгәр шулай икән, акча да китерәләр түгелме? Мондый басмаларны, ягъни халыкка кирәкле китапларны чыгымы зур дип кенә бастырмыйча яткыру, кире кагу тинтәкләрчә хаталануга гына корылган сафсата түгел идеме?

Татар халкы XX нче гасырның кимендә яртысыннан күбесен үзенең борынгыдан килгән әдәби мирасыннан мәхрүм калган хәлдә яшәде. XII нче йөз шагыйре Ә.Яссәвинең хикмәтләре, аның дәвамчысы С.Бакырганиның иҗаты 800 ел буена укылып килеп тә, шушы гасырның соңгы елынача халыктан яшерелеп калдырылды. Аерым алганда, Й.Баласагунлының, Суфи Аллаһиярның иҗат мирасының тарихи-эстетик әһәмиятен күпчелек түрәләр аңлап бетерә алмадылар. Борынгы шагыйрьләребезнең иҗатында төрки шигырь формалары да, гаруз да күптөрлелеккә ия булуы белән чагылыш тап-

кан. Мәхмүт Кашгарның «Диваны лөгате төрек» җыентыгы да татар укучысына бик кирәкле чыганак.

Сүз шигъриятебез хакында бара. Аның киләчәктә үсеш юнәлешен күзаллау, билгеләү дә зарур. Шуны онытмыйк, әдәби мирасыбызның тулы хәлендә халыкка кайтарылуы шигъриятебезнең дә үсеш офыкларын киңәйтер, милләтнең дә рухи күтәрелеш мөмкинлекләрен арттырыр иде.

Әдәби мирас һәр заманда һәм дәвердә рухи үсешнең төп компоненты булды, шулай булып калачак та. Шунлыктан аңа игътибарны һич киметмәскә, даим арттырып барырга тиешбез. Ә.Давыдов, Х.Туфан, С.Хәкимнең дә күптомлык иҗат мирасы халыкыбызга бүген дә кирәк. Әдәби мирасыбызны халыкка җиткерүне хөкүмәт ирекле икътисадый өлкә дип игълан итсә — бу дөрес сәясәт булыр дип беләм.

## VII

Шигъриятебез хакында сөйләшкәндә, татар шигыренең горур илчесе Рәшит Әхмәтҗанов искә төшә, шигырьләре һаман да сүрелми, күңелләрдә балкый.

Ул чын мәгънәсендә зур шагыйрь иде. Ясалмалыкны өнәмәгән, һәр фикеренең төгәл образын һәм символын тапкан, шашкын җанлы шагыйрь иде. Р.Әхмәтҗановның рухи мирасын онытырга хакыбыз юк. Аның шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарган «Рухият фонды»на мең рәхмәтлебез. Андый шагыйрьләр әдәбиятыбызга көн дә килеп тормыйлар. Ул — кабатланмас әдип, затлы шагыйрь булды. Шулай ук Фәиз Зөлкарнәйнең әдәби мирасы да халкыбызга тулы килеш ирешергә тиеш. Бу эшләрне кайсыларыбыздыр үз өсләренә алырга, нәшриятлар өчен әзерләп бирергә хаклылар. К.Сибгатуллинның җыентыкларын кабат чыгарасы иде, Ф.Шәфигуллинның... Азлар шул алар, бик азлар. Шуларга да игътибар җитенкерәми, шуларның да мирасларын бастыруга акча табылмасын инде. Татар, дигән булабыз, бөек, дибез. Үз хөкүмәтебез, президентыбыз, илебез бар, имеш.

Базар — дөньяның товардан гына торган өлеше. Гади, әмма чуар. Кеше хакы тиенгә дә саналмый, кем күбрәк сата, шул

тизрәк байлыкка ирешә. Әмма сәүдәгәр, товары белән бергә, үзен дә сата, тик моны үзе белми һәм сизенмичә кала.

Гасыр ахырында безнең җәмгыятебезне сәясәтчеләребез, хөкүмәт башлыклары базар мөнәсәбетә алып керделәр. Яшәешебез дә товарга әйләнде. Хәтта илбашларының да гади һәм гадәти товарга әверелүе һичкем өчен сер түгел. Шушы шартларда да шигърият үзенең сафлыгын саклап калырга тиеш. Һәр хакимгә, хөкемдарга сәҗдә кылып, ялагай, тешсез, мескен хәлгә төшсә, татар шигърияте бәлки күкрәк сугып, мактанып һәм макталып кына яшәр дип кайбер шагыйрьләребезнең сарай сандугачлары әверелә барулары бер дә сер түгел. Әмма шуның белән алар татар шигъриятенең мәртәбәсен генә бетерә барганнарын сизенми дә калдылар.

Шагыйрьнең иҗаты бөек булу өчен җанының да илаһи булуы кирәк. Мәсәлән, Г.Тукайныкы кебек! Һәммә әдәби жанрлар белән чагыштырганда шигырь — иҗатның иң илаһи өлкәсе. Минемчә, хәтта берьюллык шигъри әсәр дә илаһиятның катнашы белән языла. Шигырьне Мөхәммәд пәйгамбәребез шайтан чыбыркысы белән тиңләгән, әмма көферлеккә, имансызлыкка каршы юнәлдерелгән шигырьне шайтан йөрәгенә төбәп атылган ук дип белдергән хәдисе дә барлыгын онытырга ярамый. Җаның илаһияткә бәйле икән, шайтан чыбыркысы булырлык шигырьне тудыра алмаячак ул. Шигырьнең офыгы тар булса, көче дә югала. Шигъри символ, образ һәм метафорагыйбәрә эчтәлектә тарихи-традицион һәм мәгънәле түгел икән, күңелне шаулатмаса, гади ялтыравык кына булып кала. Әдәби чагыштыруларның, әдәби телнең үз мантыйгы бар. Бу мантыйк бозыла икән, фикер дә, нинди генә әһәмиятле һәм вакытлы әйтелгән булмасын, мәгънәсезлеккә китерәчәк. Борынгы заманнардан билгеле бу хакыйкатьләрне беребезнең дә онытырга хакы юк!

*1999.*

# ТАТАР ШИГЪРИЯТЕҺӘМ АНДА К.СИБГАТУЛЛИН ҺӘМ Н.АКМАЛОВ УРЫНЫ

*Аналитик мәкалә*

Татар шигъриятендә XX йөзнең соңгы чиреге һәм XXI гасырның тәүге дистә еллары эчендә аерым бер әдәби процесс яшәде. Бу процессның эчтәлеген һәм үзенчәлекләрен өйрәнү эше бүгенге фәндә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Махсус хезмәтләр язылу моның ачык мисалы әлбәттә. Т.Галиуллин, Ф.Галимуллин, Д.Заһидуллина, Р.Рахман, Р.Рахмани, М.Вәлиев-Барҗылы һәм башка галим һәм тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләрен, бигрәк тә Ф.Хәсәнованың анализларын, фәнни монографиясен бу өлкәдә кызыклы дип таптык.

Ул хезмәтләрне өйрәнүдән һәм татар шигърияте үсешен анализлаудан соң шушы төп нәтиҗәгә килдек: XX йөзнең соңгы чиреге — XXI гасыр башы татар шигъриятендә, аерым алганда, бердәм булып өч агым яшәгән. Без аның беренчесен «шартлы шигъри идеологик агым» дип билгелибез.

Бу агымның асылы сәяси фикерләмәләрне шигъри хис фәлсәфәсе җирлегендә чагылдыруга корылган. Аның төп вәкилләре әлбәттә Р.Харис һәм Р.Фәйзуллин булдылар. Шигъриятькә яңа көчле агым сыйфатында 60 нчы елларда килеп, 70 нче елларда таныла барып, алар шул ук XX йөзнең 80 нче елларында төп шигъри идеологик фәлсәфәнең әйдәп баручыларыннан иделәр. Зур елгаларга инешләр ничек килеп кушылса, шуның кебек аларга иярүче шагыйрьләр дә аз булмадылар. Рус әдибе М.Е.Салтыков-Щедрин үз чорында белдергәнчә: «Участь всех сильных и энергических талантов — вести за собой длинный ряд подражателей»[1],— кебек килеп чыкты ул хәл. Әгәр дә 80 нче елларда татар шигъриятен эпигонство/эпигонлык томаны каплаган икән, асылда аның барлыкка килүе «шартлы шигъри идеологик агым»ның зур

[1]*Салтыков-Щедрин М.Е.* О литературе.— М.: Советский писатель, 1952.— С.189.

уңышларының кояш кебек халык рухы киңлекләренә күтәрелүенә бәйле иде. Шагыйрьләрнең зур күпчелеге гүяки үзләренең йөрәк хисләренә ачылыр өчен юл һәм мөмкинлекне шушы шигъри агымга иярүдән күрделәр. Ул чор өчен яңа буын буларак төсмерләнгән Г.Морат, Р.Зәйдулла, Л.Лерон, Л.Зөлкарнәй, аларга кадәргеләр — Э.Касыйм, Х.Гайнетдин һ.б. шагыйрьләр мәйданга чыкты һәм алар фикердә хистә-фәлсәфәдә шушы агымга кушылган мул сулы елгалар төсен ала бардылар. «Шартлы шигъри идеологик агым», тарихлар көченгән саен үз байрагының төсен дә үзгәртә белде. Әмма алар «без хаклык байрагын күтәрүчеләр, аның төсе бервакытта да үзгәрми» дигән шигарьне телләреннән төшермәделәр. Бу исә шушы шигъри агымның яңа сәяси тормышка әзер булуын ачык күрсәтте, халык күңелендә алар ышаныч һәм яшәү көчен тудыра алдылар. Шагыйрь күңеле тормыш үзгәрешләренә, киләчәкне тоемлауга сизгер булырга тиеш. Бу яктан «шартлы шигъри идеологик агым» вәкилләре халыкка тугыры хезмәттә булдылар. Әмма аларның фикерләре, уй-теләкләре, дөньяны күрү һәм чагылдыру сыйфатлары кемнәргәдер бәлки ошап та бетмәгәндер?

Һәм ул баштан ук шулай булды.

Һәм менә шул ошатып-яратып җиткермәү татар әдәбиятында, тәүгесеннән бераз соңартылып, яңа бер көчле шигъри агымны тудырды. Боларга, беренчеләреннән аермалы буларак, җитди активлык та, мәйдан да җитмәде. Бу хәлдә бары тик тискәре тәнкыйди, хәтта инкарь итүче карашлар гына үсә алыр иделәр. Моны сизүчеләр булмады диярлек.

Шушы икенче әдәби юнәлешне «шартлы шигъри сурәт агымы» дип атарга мөмкин булыр иде. Алар тормышны, табигатьне, кеше күңелен, тарихны, барлыкны-юклыкны шигъри сурәт эчендә, шигъри сурәтләнмеш аша күрделәр. Шуның өчен аларның әсәрләренең төп тукымасын сурәт хасил итте. Ул сурәтнең җирлегендә ни-нәрсә күзалланса, алар аны хакыйкать дип атадылар. Шуңа ихластан ирелделәр һәм аны халыкка төшендереп бирергә ашыктылар. Шуңа да аларның шигырьләрендә романтик рух өстенлек итте. Аларның да чишмә башы шулай ук еректан, әдәбиятыбыз тарихыннан ук

килеп, И.Юзеев һәм Ш.Галиев лирикасында үз көчләрен күрсәтә башлап, асылда бар тулылыгы һәм күркәмлеге белән Зөлфәт һәм М.Әгъләмов иҗатларында ачылды. Бу агымга кушылган шагыйрь һәм шагыйрәләр шактый иделәр. Мәсәлән Г.Садәне бер дә читкә куеп булмый, Р.Гаташка килгәндә, ул хәтта робагыйлары белән дә беренче агымның вәкиле буларак ачылды.

Татар шигъриятенең өченче юнәлешен «шартлы шигъри фикер агымы» дип атарга мәҗбүрбез. Бу төр әдипләр дөньяны фикер бәяләмәсе аша күрә-күрсәтә иделәр. Аларда фикер бирелеше метафорик куәт алып, бәяләүче, ачыклаучы көчкә әверелә барды. Шуның белән затлы бер шигъри агым тудырылып, күңелләрне заманча хис белән баетуга да иреште. Бу агым татар әдәбиятының шулай ук тарихи катламнарыннан ук килеп, асылда XX йөзнең 70 нче елларында үзенең барлыгын белдерде, алга таба да куәтләнә баруын сиздерде. Әмма метафорик фикер аша дөньяны күрә һәм бәяли белү татар акылы өчен катлаулы мәсьәлә булып чыкты, шунлыктан аңа кушылучыларның сирәк күренеш икәнлеген искәрми мөмкин түгел.

Бу өченче агымның башында К.Сибгатуллин торды, аңа Н.Акмал килеп кушылган иде. Никадәр тирән һәм көчле юнәлешне тәшкил итмәсен, әмма ул агым артык җәелеп китә алмады. Шуның белән аның әдәбиятыбыз тарихы өчен кадере дә зур дип әйтә алабыз.

Шулай итеп, татар шигърияте XX йөзнең соңгы чирегендә, XXI гасыр башына шушы өч агымда халкыбызның күңелен саф хисләре белән сугарып, тормышның болын-урман-кырларында чәчәкләрне, мәгърурлыкны, барча ямьнәрне, акланган һәм акланмаган өмет һәм хыялларны күрергә, аңларга, тоярга ярдәм итеп килеп керде. Әлбәттә агымнарның беренчесе мул сулы, уңышлы, иҗтимагый яктан әһәмиятле кебек күренде. Шунлыктан бу агымда баручыларның иҗатлары асылда эпигония белән характерланды. Әмма моны кабатлану дип түгел, бәлки ияру, шул агымның көчен иҗатта файдалана белү осталыгы буларак танырга тиешбез. Бу өч агым, олы елгалар кебек, тормыш мәйданында агып барышларында сәяси-

көнкүреш ландшафтларына бәйле рәвештә әле үзара якынайдылар, әле ерагайдылар. Шунлыктан аларның бер-берсеннән шигъри-әдәби дым алган очраклары да булмады түгел.

Халыкны шушы агымнарга кергән шагыйрьләрнең шәхси мөнәсәбәтләре кызыксындырмый иде. Сәяси даирәләргә әгәр дә «шартлы шигъри идеологик агым» әһәмиятлерәк тоелса, халыкны «шартлы шигъри сурәт агымы» кызыксындырды. Алар арасында иң сөеклеләре әле И.Юзеев, әле Ф.Яруллин, әле Зөлфәт яки М.Әгъләмов булдылар. Әмма беренче агымда беренчелек һәрвакыт Р.Харис һәм Р.Фәйзуллин каләмнәренә бирелде. Аларның шигъри сүзләре өлгергән һәм җитди саналдылар, шулай дип кабул ителделәр. Өченче агымга игътибар җитмәде. Моны К.Сибгатуллин да, Н.Акмалов та бик авыр кичерделәр. Әмма алар да татар әдәбиятының үксез баласы түгел иделәр.

Ничек кенә булмасын, нинди генә формаларга һәм төрләргә кермәсен, «шартлы шигъри идеологик агым» юнәлеше татар шигъриятендә озын юллар үтәргә җыена, шушы ягы белән ул урта гасырлар суфичылык дәвере татар шигъриятен дә хәтерләтергә мөмкин.

«Шартлы шигъри идеологик агым» татар әдәбиятында яшь М.Җәлилнең 1919 нчы елда «Кызыл йолдыз» газетасында басылып чыккан «Бәхет!» шигыреннән үк баш алып киткән иде. Менә аның кайбер строфалары: «Кулыма мин кызыл кылычны алсам,/ Шулай шуннан кызыл фронтка барсам,/ Олуг бер дәрт белән сафка атылсам.../ Үлем кулы килеп басса — егылсам,/ Җаным күккә-гарешкә очса-китсә — / Менә шунда бәхетле мин, бәхет — шул». Байракларның, тарихи фонның төсе үзгәрүгә карамастан, «шартлы шигъри идеологик агым» нәкъ шушы мотивларда үсте, шушы уртаклык-топта чәчәк атты һәм туклыклы канәгатьлек җимешләрен бирде. Сабырсызлык асылда икенче агымга хас күренеш иде.

* * *

XX йөз башы рус символист шагыйре А.Блок, шигырь язу мәсьәләләре хакында фикерләре белән уртаклашып, укучыларына болай дип белдергән: «Всякое стихотворение — покры-

вало, растянутое на остриях нескольких слов. Эти слова ставятся как звезды. Из-за них существует произведение»[1]. Монда шагыйрь шигырь конструкциясе хакында күзәтүләрен дә, иҗат итү алымын да белдереп калдырган. Борынгы грек трагедияләре авторы Эсхил иҗатын анализлап, аңа бәя биргән А.А.Тахо-Годи болай дип яза: «Приковывание Прометея и скала и низвержение его молниями и громы Зевса, то-есть начало и конец трагедии,— вот поворотные моменты в развитии сюжета. Все остальное — лишь фон для показа страшных мук Прометея»[2]. Монда сүз әдәби әсәрдә күпчелек урынны әдәби борылышлар арасындагы фон алып торганлыгы хакында бара. В.Шкловский болай дигән: «М.Горький говорил мне и многим моим товарищам — передаю точно, но не буквально:

— Не торопитесь в описании. Дайте читателю время понять образ, увидеть вещь. На лестнице художественного построения не забедьте о площадках”[3]. Аңлашылганча, монда да сүз поэтик модус хакында бара. Модус ул, атрибуттан, ягъни предметның төп үзенчәлегеннән аермалы буларак, предметның билгеле бер очракларына-халәтенә генә хас үзенчәлек. Димәк жанр күренеше түгел, бәлки шул жанрның теге яки бу әсәрдә, яисә әдип иҗатында файдаланылган мөмкинлегенә бәйле үзенчәлеге. Әгәр дә, мәсәлән, рифма, ритм, строфика, куплет төшенчәләрен без шигырь атрибутлары буларак белсәк, хис, мотив, фон, борылыш, топ һәм башкаларны, алар арасындагы үзара бәйләнеш үзенчәлекләрен, күләм мөнәсәбәтен, эчке бүленешне шигъри модуска бәйле дип карарга тиеш булабыз. Фәлсәфә фәненә караган төшенчәне әдәбият фәненә кертү беренче генә очрак түгел. Фәннәр бер-берсенең казанышларын файдаланырга хаклы.

Әгәр дә А.Блок фикерен кабул итсәк, димәк шигырь автор әйтергә җыенган төп фикерләрдән һәм шулар арасына куелган

---

[1]***Цитата алынды:*** *Хализев В.Е.* Теория литературы: Учебник.— 3-е изд., испр. и доп.— М.: Высш. шк., 2002.— С.301.

[2]*Тахо-Годи А.А.* Прометей Прикованный // Греческая трагедия.— М.: ГИДЛ МПР, 1956.— С.47-48.

[3]*Шкловский В.* Художественная проза: Размышления и разговоры.— М.: Сов.пис., 1961.— С.35.

эчтәлек тукымасыннан гыйбарәт. Боларның чагыштырма үзенчәлекләре әлбәттә шигъри-поэтик модусны барлыкка китерә. Әдәби фон һәм әдәби борылышлар белән шушы ук хәл, алар да поэтик модус төшенчәсенә-эчтәлегенә туры килә. М.Горький да поэтик модус хакында искәрткән булып чыга. Шулай итеп без әдәби әсәргә поэтик модуслар хас икәнлеген танырга тиеш икәнбез. Шунысы кызыклы, поэтик атрибутлардан аермалы буларак, шигъри модуслар һәр очрак өчен үзенчәлекле һәм иҗади осталыкка бәйле күренеш юнәлешен ала.

Татар шигърияте үсешендә поэтик модуслар белән оста эш итү үрнәкләрен асылда «шартлы шигъри фикер агымы» шагыйрьләре күрсәттеләр. Аларның әсәрләренең схемасы моңардан гыйбарәт иде: метафорик фикер белдерү һәм аны эчтәлек тукымасы эчендә раслап бирү. Әлбәттә башта раслап килеп, аннары да фикер белдереп була. Алар аны да файдаландылар. Әмма мондый гади конструкцияләр белән эш итү шигырьләренең көчсезләнүенә, фикерләрдә кабатлану кебек күренешкә китерер иде. Шунлыктан һәр очракта катлаулы поэтик модуслар иҗат итәргә туры килә.

Шигъри модус белән эш итү осталыгын Х.Туфанның «Иртәләр җитте исә» шигыре ачык аңларга ярдәм итә. Шагыйрь бу әсәрендә һәр строфаны аерым эчтәлектә билгели һәм алга таба шул строфаларның урыннарын алыштырып бара. Атрибутлар саклана. Әмма һәр шигъри куплет, югыйсә анда шул ук сүзләр кабатланса да, яңа хис мөнәсәбәте һәм кабатланмас эчтәлек алып килү тойгысын уята. Модус ул аерым хәлгә-халәткә, ягъни конструктив үзгәрешкә предметның керүе аркасында барлыкка килүче үзенчәлек түгелме? Бер очракта иртәләр җитүгә ярыңның аклыга киенүе, икенчесендә иртәләр җитүгә юлларда җилләр исүе алга чыгарыла һ.б. — шулай итеп эчтәлек үзгәреше барлыкка килә, хәтта атрибутлар монолит хәлләрендә калсалар да.

Әмма «шартлы шигъри фикер агымы» шагыйрьләре Х.Туфанның Шәрык әдәбияты даһие Фөзүлидән үк килгән шигъри алымын файдаланмадылар. Моның төп сәбәбен аларның әдәби агымнарда аерылып торуларыннан күрергә бу-

ла. Һәрхәлдә «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре Х.Туфанны башка агым вәкилләре кебек соклану объекты итсәләр дә, аның иҗатына мөкиббән китсәләр дә, әсәрләрендә аны данга төрсәләр дә, үз агымнарында кала бирделәр. Бу факт та аларның чын әдип булуларын ачык раслый ала, билгеле.

XIX йөзнең соңгы чирегендә М.Акмулла шигъри сентенцияне (әхлак өйрәтүне) шигъри фикер бирү белән алыштырып, «шагыйрьләрдән сүз чыгар хикмәт белән» дигән шигарьлозунг астында иҗат итеп, хикмәтне монда суфичы шагыйрьләр яратып кулланган әхлакый һәм танып белү характерындагы әсәр жанры буларак түгел, канатлы метафорик фикер бирү сыйфатында куәтләп язды. Татар әдәбияты бервакытта да фикерсез булмады. Фикер куәте белән иҗат итү, яңа фикерләр бирү ягыннан һәр шигъри агым да көчле иде. Әмма әһәмиятлесе шунда, башка агымнар өчен шигъри фикер бирү турыдан-туры әдәби әсәрнең идеясенә хезмәт итсә, «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләрендә ул шигырьне барлыкка китерүче поэтик модус рәвешен алды, шуның белән схоластик формуладан котылу, фикер киңлегенә юл ачкычы ролен үтәп, метафорик мәгънә нигезенә эвереләдерелде. Әгәр дә символистлар фикер бирүдәге схоластик формулаларны символик һәм мистик-метафорик форма бирәмлекләре белән алыштырсалар, «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре шигъри метафорика белән эш итүне өстен чыгарды. XX йөз башы татар символизмының иң гүзәл үрнәкләреннән берсе икәнлеген төшенеп, символик эчтәлекнең тирәнлеген аерым аңлар өчен Дәрдемәнд иҗатына мөрәҗәгать итү дә җитә.

Ә менә К.Сибгатуллин болай яза:

Авыр димим сине,
җиңел димим,
үлчәп булмый сине, Замана,
Утыз яшькә җиткән егетләрнең
икенче кат чәче агара.

(“Без синеке инде”, 1973.)

Формаль мантыйкка буйсындыра калсак, чәч ике тапкыр агара алмый. Әгәр дә шигъри логика нигезендә карасак, монда метафорик фикер тасвирлануы аңлашыла.

Сүз тормыш авырлыкларыннан чәчнең агаруы хакында бара, билгеле. «Икенче кат чәч агару»ны да яшәеш шартларының бер дә җиңеләймәвен, тагын да кыенлаша баруын белдерә дип алырга була. Лирик герой замананы үлчәп булмавын, ягъни үлчәүгә салу мөмкин түгеллеген дә искә ала. Бу да метафорик фикер әлбәттә. Лирик геройның зарланырга да, сөенергә дә җыенмавы әйтелә.

Шигырь шул ук: «Авыр димим сине,/ җиңел димим,/ үлчәп булмый сине, Замана,»— фикерләмәсе белән башланып китә. Борынгы грек шагыйре Эсхилның да әсәрләрен әдәби борылышлар эчендә әдәби фон бирү ысулында корганлыгын искәртеп узган идек. Әдәби борылышның К.Сибгатуллинда метафорик фикер бирү өчен файдаланылуын күрәбез. Әдәби фон ролен шигырьнең эчке тукымасында тасвирланган эчтәлек били.

К.Сибгатуллин шигъриятенең хикмәте шунда — ул фикерләр галереясе белән шигъри фон барлыкка китерү остасы булып тора. Шул фикерләр сурәтне дә, идея-идеология катламын да алыштыруга юнәлдерелгән. Аның лирик герое кылыч айкап көрәшкә дә ташланмый, үз хаклыгын да раслап сөйләми, халыкның нинди бәлаләр астында калуын фикер төрткеләре ярдәмендә бирә, аның иҗатында сурәтне метафорик фикер һәм фикерләмәләр агышы алыштыра: «Бишекләрдән үзебез төшеп җиктек/ туарылып калган атларны».

Тормыш авырлыгы сурәтен дә шундый ук метафорик фикер аша бирә ул: «...Камыт агачлары шартлап сынды,/ атлар пеште юлда... ачудан».

Әсәрдән аңлашылганча, лирик герой — сугыш еллары баласы, алар буынына әүвәле әтиләре калдырып киткән эшләрне башкарырга, аннары гына үзләренекен күтәрергә туры килә. Шигырьдә К.Сибгатуллин моны бер нәсел чылбырының «ике буыны» турында фикер әйтеп узганында да искәртә:

Мәңгелеккә үтеп бара торган
кешелекнең шушы буыны
алып тора
халык тарихында —
бер чылбырда ике урынны.

Шигъри фон, шулай итеп, үзе дә тыгызланган фикерләр тезмәсеннән тора. Әмма алар аерым-аерым түгел, бәлки шигъри фикер мантыйгының аерым синтагмалары рольләрен башкаралар һәм һичшиксез башка бер, зур һәм төп фикергә күңелнең омтылышын тудыралар. Әсәрдә ике вакыйга фикерләр тезмәсе рәвешендә ачыла. Беренчесе — аталарның дошман угына каршы килүе, икенчесе — бишектән төшеп, балаларның аларны алыштыруы, ягъни кешелек тарихының чылбырындагы ике буыны бу.

Лирик герой заманага мөрәҗәгать итеп болай ди: «Без синеке инде,/ син — безнеке,/ Тоеп тора сине җилкәләр...»

Монда да автор шигъри метафорик фикерне бирә. Укучы күңелендә сорау туа: «Әгәр дә лирик герой замана авырлыгын тоя икән, ни өчен соң ул вакытта аны «үлчәп булмый сине» дип белдерә?» Моның хикмәте бары бер төрле генә аңлатыла ала: әдәби-композицион борылышны барлыкка китерүче шигъри юлларга эчтәлекне бирүче әдәби фон метафорик каршылыкка куела, ягъни лирик миннең уйланулары «аларны ук әйтәсем килмәгән дә иде» дигән тойгы тудыра. Бу исә шигъри фикер йомгагын тагын да тәэсирлерәк дәрәҗәгә җиткерү өчен хезмәт итә. Утыз яшькә җиткән егетләрнең,— әгәр дә фон эчтәлегендә генә фикер калдырылса,— бу фикер әтиләре өчен дә балаларының чәчләре агарган дигән булып аңлашылыр иде, ә хәзер ул, беренче эчтәлеген җуеп, яңа мәгънә тирәнлеген ала һәм тормыш хакыйкате дәрәҗәсендә кабул ителә.

Шул ук әдәби агымдагы Н.Акмалов, шигъри метафорик фикер коллизияләре белән эш итүче булуына карамастан, әдәби фонны лирик сурәт төсмерендә бирергә омтылышы белән К.Сибгатуллиннан берникадәр аерылып та тора кебек. Бу факт аларның үз иҗатлары белән бер-берсеннән аерымлануларын да күрсәтә.

К.Сибгатуллинның катгыйлыгы, фикердә корылыгы Н.Акмаловның лирик тоемны читкә какмавы — болар поэтик модус закончалыкларын барлауда кызыклы күзәтүләргә этәрә. «Шартлы шигъри фикер агымы»ндагы әдипләрне лирикага бирелү ритмик сөйләм юлына кертеп җибәрә. Бу яктан Н.Акмалов шигърияте шулай ук шактый кызыклы була алды.

*(Н.Акмаловның «Философлар» шигыре, язылу вакыты 1980 нче елларга карый:)*

Иң борынгы бөек философлар
Яшәү асылын ачар урынга,
Калын-калын трактатлар язган
Дәүләт төзелеше турында.

Н.Акмалов шигъри метафорик фикерне К.Сибгатуллин кебек үк алга чыгара һәм алга таба текста аны раслаучы эчтәлек фонын бирә. Дәүләтләрнең тарих барышында үз вакытлары белән җимерелә баруларын искәртеп, фәлсәфәләрнең бүтән төс ала баруларына да, фән үсешенә дә аерым игътибар күзе салып үтә. Н.Акмалов эчтәлек борылышларын шигъри метафорик тезмәгә әверелдергән сыман, әдәби фон эчендә үстереп тә бара. Һәм шунда: «Галимнәрдән ләкин сер кача,— дип белдерә дә,— Бөтен илгә урта белем керттек,/ Акыл ягы калды уртача»,— дигән раслау сүзләре белән фикерен ассызыклый. Әмма бу метафорик фикере дә бары тик шигъри эчтәлекне нығытучы фон ролен үти. Һәр фикер сигтагмасы аерым берәмлеккә әверелеп китсә, әлбәттә шигырь таркалыр иде. Н.Акмалов әсәрләрендә дә, К.Сибгатуллин иҗатына хас булганча, темага ике тапкыр йомгак ясалгандай тойгы калдырыла, ягъни шигырь инде тәмамланып, аңа соңгы куплет өстәп кенә куелгандай аңлашылып кала. Әмма моның шул ук әдәби-поэтик ысул икәнлеге шигырьнең соңгы куплетында эчтәлекне хасил итүче әдәби фонны шагыйрьнең тулысы белән шигъри метафорик кысаларга кертүеннән күренә. Мондый шигъри фикерләү алымы әсәрнең эчтәлеген тагын да тирәнәйтә. Шигырьләре кыска булсын, озын итеп төзелсен, барыбер дә шушы алым «шартлы шигъри фикер агымы»ндагы

шагыйрьнең иҗатында өстенлек ала. Мисал өчен, Н.Акмаловның «Философлар» шигыренең ахырында ул болай бирелгән:

Айны, күкне, йолдызларны сөеп,
Яшәү асылын ачар урында,
Философлар һаман нидер яза
Дәүләт төзелеше турында...

Шушы рәвешле шигырьдәге калку итеп чыгарылган фикер фәнгә әдәбиятны-сәнгатьне каршы куя, әмма бу хакта бөтенләй бер сүз дә әйтелмидер кебек тойгы да калдырыла. Яшәеш белән дәүләт системасы да метафорик фикер планында үзара каршы куелалар.

К.Сибгатуллин һәм Н.Акмаловның шигырь барлыкка китерүче модуслары менә шушы рәвештә: әүвәле метафорик фикер китерелә, аннары ул эчтәлек эчендә «әдәби фон» кысаларында башка фикер синтагмаларына бәйле ачыла, фикергә йомгак ясала, ахырда кабат өстәмә куплет китерелеп (ә ул асылда шигырьнең беренче куплетын кабатлый), яңача нәтиҗә чыгарыла, ягъни идеяне формалаштыруда төп рольне үтәүче шигъри метафорик фикер итеп бирелә. Укучы, Н.Акмаловның «Философлар» шигырен укыганнан соң, кешелек өчен дәүләт төзелеше мәсьәләсе түгел, сөенеп яши белү зур әһәмияткә ия икән дигән фикергә килә. Әмма әсәрнең идеясен шигырьне барлыкка китерүче модусны ачыклауда гына таба алабыз.

Эчтәлек тукымасында фон буларак мондый фикер китерелә: «Фән агачы үскән./ Ә кешенең/ Тамырлары җиргә бәйләнгән». Бу юллар биш куплетлы шигырьнең өченче куплетыннан. Аңа кадәрге строфаларда борынгы фәлсәфәләрнең хәзер башка төстә аңлашыла барулары, дәүләтләрнең җимерелүләре сөйләнелә, аннары килә торган тезмәләрдә белем белән аң үзара каршы куела. Шулай итеп Н.Акмалов фәннең дәүләт хезмәтендә икәнлеген, ә кешеләрнең җиргә берегеп яшәүләрен раслый бара. Ә бу фикерләр суммасы әсәрнең идеясен аңлауга китерә, аның нигезен тәшкил итә бара, эчтәлек тирәнлеге фикерләр кушылмасында кала. Бу шигырь кешенең бәхете сөенеп яшәүдә дигән идеяне бирүгә корылган

югыйсә. Әмма фикерләрнең күплеге эчтәлек киңлегенә китерми.

Әгәр дә шушы әсәрне формаль логикага буйсындырсак, борынгы философларның дәүләт төзелеше турында гына язмаган булуларын, бәлки чынбарлыкны танып белүгә һәм аңлатуга, хакыйкатьне ачыклауга бар зиһеннәрен, акылларын юнәлтүләрен искә төшерсәк, шагыйрьнең хаталануына чынлыкта хәйран итәргә мәҗбүр булыр идек. Әмма «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләренә андый нигезләмәләргә таянып эш итү ул шигырьне үтерүгә тиң. Әдәби әсәрләрнең хикмәте шунда ки, аларда хакыйкать — образлы фикер, метафора ярдәмендә ачыкланыла.

В.Шкловский, әдәбиятның үзенчәлекләре хакында фикер йөрткәндә, Л.Н.Толстойның мондый сүзләрен китерә: «Искусство есть деятельность человека, состоящая в том, что человек сознательно известными знаками передает другим испытываемое им чувства, а другие люди заражаются этими чувствами и переживают их»[1]. Һәм мондый нәтиҗәгә килә: «Великий прозаик не только использует свой творческий опыт, но... хочет определить законы искусства для прошлого и настоящего: для всех и навсегда». Бу ике күзәтү дә кызыклы һәм «шартлы шигъри фикер агымы» шагыйрьләренең әсәрләрен аңларга ярдәм итәләр. К.Сибгатуллин да, Н.Акмалов та үз күзәтүләрен әдәби фикер кысаларында укучыга җиткерәләр. Аларның метафорик шигъри фикере аңлаешлы тышкы билге буларак укучыга тәкъдим ителә. Ул тышкы билге эчтәлек белән баетыла, фикерне үзенә ияртә һәм фикри нәтиҗәгә киленә. Әмма фикри нәтиҗә идеянең үзе түгел, була да алмый. Идеяне барлыкка китерү өчен бу тип шагыйрьләр, әдәби фикерләү катламына күтәрелеп, метафорик фикер белән әсәрне йомгаклыйлар. Формаль логика өчен, акыл-аңга сәер тоелган фикри билгеләр күңелгә тәэсир итәрлек эффектлы сурәт төсен алалар. Шигырьнең көче бермә-бер арта, тәэсир куәте үсә. Укучыда хис-тойгылар өермәсе туа. Шагыйрьнең нинди хаклы булуына

---

[1]*Шкловский В.* Күрсәтелгән хезмәт.— Б.14.

хәйран итәбез. Моны без әдәбиятның тантанага килүенә мисал рәвешендә искә алабыз.

Шулай итеп «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре софистика алымнары белән иҗат итү юлында аерым әһәмияткә лаеклы әдәби үсешне татар күңел дөньясында тәэмин иттеләр. Мондый күренеш шигърият өчен ят түгел, аның бөек таләпләренә җавап бирә иде. Бу агымга XXI йөз башында шагыйрь М.Мирза килеп кушылды, әмма аның формаль логика кысаларына шигъри фикерне кертергә омтылышы шигырен канатланудан берникадәр чикләп тота башлады.

Шигырьнең асылы шунда — ул рухка ирек бирә, шигырь канатларында рух үз дәртендә җырлый, үз моңында көйли, үз телендә сөйли. Менә шуны тудыра алучыны бүгенге көндә чын шагыйрь дип әйтәбез. Рух үзе сүзләрне рифмалаштыра, ритмга сала, фәлсәфәсен, строфикасын, башкасын таба, ягъни чын шигырьне яза. Мондый талант дәрәҗәсенә ирешкән кешегә беркем дә тиңләшә алмый. Аңлашылып тора, мәсәлән «икенче кат чәче агара» дигәндә К.Сибгатуллин формаль логиканы, тормыш дөреслеген боза, монда бернинди хакыйкать юк сыман, бу — әдәби уйдырма. Әмма чынлыкта аның эчтәлеге формаль логик эчтәлектән бермә-бер киңрәк һәм тирәнрәк. Әдәби әсәрләрдә тасвир кылынган фикерләр тезмәсе һичшиксез укучыны идеягә этәрә, идеягә якынайта ала. Идея ул әлбәттә әсәрнең җаны. Укучы әдәби әсәрнең эчтәлеге белән танышуның буеннан-буена үз фикерләрендә хәрәкәт тудыра, бу исә хакыйкатьне аңлауга юл ача. Аңлау мөмкинлеген бирү фикер үсеше юлында төп әһәмияткә ия. Бер фикер икенчесен тудыра. Ризалашу яки ризалашмаудан башланган фикерләү аерым-аерым модуслар хасил итәләр, без моны хис үзгәреше белән дә бәйлибез. Әгәр дә Н.Акмалов шигырендә, мәсәлән, «Урманнарда бүре сирәгәйсә,/ Урамнарда этләр күбәя» дип белдергән икән, монда бүренең табигать санитары булуын да, шул ук вакытта сүзнең җәмгыятьне чиста тотучылар хакында баруын да, ә этләрнең әшәке кешеләр икәнлеген дә аңламый мөмкин түгел. Формаль логика һич югы сарыкларның күбәюе белән бәйле фикер алып барыр иде. Әмма әдәби метафорик фикер күчерелмә мәгънәләр белән эш итү аша хакыйкатьне

күрү-күрсәтүгә, бәянләүгә, тасвирлауга ирешә. Шигъри фикер бирү бер нәрсә, аны шигырьгә әверелдерү — икенче. Шушы формадагы әдәби борылышларны әдәби фон аша дәлилләү, белдерү, аңлату һәм сурәтләү вакытында ул бөтенләй башка төрле эчтәлек алырга мөмкин. Бу очраклылыкның шигырь тукымасында гаҗәеп зур әһәмияте бар. Менә шушы очраклылык шигырь тудыручы модус булып тора да инде. Әгәр дә Фөзүлидән алып Х.Туфанга кадәр әдәби үсешкә бәйле вакыт аралыгында шигырь тудыручы модус төшенчәсе ачыкланылып, теоретик яктан билгеләнеп җиткән булса, «шартлы шигъри фикер агымы» бүгенге көндә бездә берникадәр сәерсенү тойгысын уятмас та иде.

* * *

«Шартлы шигъри идеология агымы» һәм «шартлы шигъри сурәт агымы» вәкилләре дә фикер бирү ысулларыннан йөз чөермәделәр. Киресенчә аңарда фәлсәфәлек күреп, иҗат офыкларын киңәйтү мөмкинлекләренә юл ачу юнәлешендә файдаланып эш иттеләр. Әмма бу факт аларның үз агымнарыннан читләшүләре дигән сүз түгел иде. Алар, тоткан юлларында калып, үз карашлары мөмкинлек биргән кадәрле фикер сөйләүне шулай ук еш файдаландылар. Шигъри фикер күп әйтелде һәм әйтелә торды. «Шартлы шигъри идеологик агым» аны үз кысаларыннан чыкмыйча сөйләде, «шартлы шигъри сурәт агымы» шигъри фикерне сурәт хисе мөмкинлек биргәнчә байрак итәргә омтылды. Әмма аларга карап берсенең дә асыл үзгәреше күзәтелмәде. Бу факт исә шигъри агымнарның мөстәкыйльлеген тагын да бер кат раслады.

Фикер әйтүнең, билгеле бер фикер тирәсендә шигырьне оештыруның үз дәвере-чоры бар, татар әдәбиятында ул XX йөзнең буеннан-буена диярлек яшәде. Аның шулай булуында хикмәт тә бар иде. Укучылар тарафыннан фикер җиңел табыла һәм үзләштерелә торган эчтәлек төсен алды. Хәтта теориядә дә әдәби әсәрнең идеясе эчтәлектә күтәрелгән төп фикер белән тәңгәл куелды. Шушы рәвешле идеяне фикер алыштырды. Төп фикер билгеләнелсә, әдәби әсәр анализланган дип саналды. Әмма «шартлы идеологик агым» өчен фикер һаман да сәяси

һәм әдәби идеологияләргә буйсындырылды һәм шуның өчен дә алардагы төп фикерләр иҗтимагый күренешне бәяләп, алга омтылыш, халык өчен тырышу юнәлешләрендә корылдылар. Алар өчен халык һәм җәмгыять, җәмгыять һәм ил, ил һәм хөкүмәт, хөкүмәт һәм сәясәт, сәясәт һәм идеология, халык һәм дәүләт төшенчәләре бердәй тигез яссылыкта күз алдына китерелделәр. Бу рәвешле монолит фикерли белү аларны уңышларга китерде һәм дәүләт идеологлары бу төр шагыйрьләргә һәрвакыт югары бәя бирделәр. Шул рәвешле «шартлы шигъри идеологик агым» вәкилләре «сарай җырчылары» хезмәтен башкардылар. Әмма бу хәл «шартлы шигъри сурәт агымы» шагыйрьләрен канәгатьләндерә алмый иде.

Аларда да фикер чыгару, фикергә таяну, сурәтне фикергә китереп ялгау, яисә фикерне сурәткә җәелдерү-таркату шигъри модусның төрләрен барлыкка китерде. Фикерчелек стихиясе һәммә төрле вариантларда һәм вариацияләрдә яшәде. Фикерне сурәткә әверелдерү, яки сурәтне фикергә әйләндерү әлбәттә кеше зиһене башкара ала торган күренеш. Әмма бу вакытта фикер генә түгел, күңелгә хис белән бергә идея дә үтеп керә. Ә аның фикер белән тәңгәл килмәгән очраклары ешрак була бара. Шигъри сурәтнең хикмәте дә шунда, ул күңелләрдә хисләрне кузгата, зиһенне-аңны уйната, хисләр әгәр дә мотив белән ачыкланылган булса, укучы күңелендә моң калдыра. «Шартлы шигъри идеологик агым» вәкилләрен әгәр дә укучы «корылыкта» гаепләсә, «таш белән эш итүче төзүчегә» охшатса, «шартлы шигъри сурәт агымы» вәкилләрендә ул хис ташкынын күрде, аларның шигъриятендә рухның яшәвенә сокланды. Һәммә төрле фикерләр әйтелеп беткән һәм алар, мең дә беренче тапкыр кабатланалар сыман тойгы калдырып, фикерчелек дәвере замана мәйданыннан тарихка үтеп китәргә, әдәбияттан кичәргә тиеш иде. Әмма еллар яңарып килә торалар, җитмәсә үз хикмәтләре белән алар туа баралар.

«Шарлы шигъри фикер агымы» вәкилләреннән К.Сибгатуллин үз юнәлешенең сафлыгын, чисталыгын тәэмин иткән иң куәтле шагыйрь булды әлбәттә. Н.Акмаловның аңа кушылуы бу агымга зур көч бирде. «Шартлы шигъри идеоло-

гик агым» һәм «шартлы шигъри сурәт агымы» шагыйрьләренең дә фикер әйтергә омтылышы һәм моны үз агымнары ярларында калган хәлләрендә оста итеп башкара алулары шулай ук «шартлы шигъри фикер агымы» мәртәбәсе өчен хезмәт итә иде.

«Шартлы шигъри фикер агымы» рәсми идеология белән санлашмады. Ул аны хәтта танымады да, аны тануда хәтта мескенлек, фикри җитешсезлек күрде. Дөньяга караштa тәнкыйдилек, ризасызлык, әмма килешүчәнлек аларның төп маяклары булдылар. К.Сибгатуллинның да, Н.Акмаловның да лирик герое шушындый юнәлешләр эчендә хәрәкәт итте. Хәер, аның заманасы да, кешеләре дә ул чорларда нәкъ шундый иделәр. Соклandырганы да лирик геройларының шушындый була алулары аркасында!

Бу өч агым татар әдәбиятының XX йөзе соңгы чирегендә, ягъни 1975 нче елларыннан (дөресрәге 1965 нче елларыннан соң үз юнәлешләре белән туып) куәтле үсеш кичереп яшәп, татар шигъриятен моңарчы күрелмәгән бөеклегенә күтәрделәр, аны үз потенциаль көче белән, башка халыкларның әдәбиятларына иярмәүче, үз стихиясендә яшәүче итеп күрсәтә алдылар. Г.Тукай чорында башланып китеп, 1914 нче елларга чын мәгънәсендә милли юнәлешкә кереп бетә алган шигъриятебез, аннары килеп, 1920–1950 нче еллар арасында башка әдәбиятларга ияреп алды, аларны мөмкинлеге барча кабатлады-кабатлады, хәтта берничә оригиналь әдипне дә биреп алды әле. Ә менә шигъриятебезнең XX йөзнең соңгы чирегендә үсеше бөтенләй башка әдәби картинаны күз алдына китереп бастырды. Татар шигърияте ашкынган атлар чабышын хәтерләткән сабантуй мәйданына әверелде. Шагыйрьләребез берсеннән-берсе көчле иде. Хәтта телләрдә сирәк яңгыраган әдипнең әсәрләрен генә алып укып карасак та, аның иҗатына хәйран ителми мөмкин түгел иде. «Шартлы шигъри сурәт агымы» вәкиле Н.Гамбәр, мәсәлән, татар укучысы өчен шундыйларның берсе булды. Р.Мингалим исә, хәтта сөйләмле шигъриятне якын күрсә дә, беренчел дәрәҗәгә күтәрелеп куелды. Татар шигъриятенең һәр вәкиле диярлек сокланырлык әдип булуы әдәбиятыбыз өчен зур мәртәбә иде. Бу әлбәттә ха-

лык өчен дә зур куаныч һәм аның байлыклар иясе икәнлеген дәлилләүче фактлар рәтенә кертелә ала.

Инде төп гомумиләштерүләргә килсәк, «шартлы шигъри идеологик агым»ның әлбәттә реалистик пафоска коралланган икәнлеген ассызыклап үтәргә тиешбез. Без, укучылар, аларны реалистлар буларак кабул иттек. Дөрес, «шартлы шигъри сурәт агымы» вәкилләре дә рәсми реализм кысаларында кала килделәр, әмма алар романтик пафос белән коралланган иделәр шул. Бу яктан бәяләгәндә, Роберт Әхмәтҗан чын мәгънәсендә романтиклыкның иң гүзәл үрнәкләрен күрсәтте. «Шартлы шигъри идеологик агым»дагы Р.Гаташны да реалист итеп күз алдына китерүе авыр иде. «Шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре рационализм юлыннан хәрәкәт иттеләр. Әмма бу өч агым гомуми юнәлештә барыбер дә реализм өчен тырышлык куйдылар һәм хаклы рәвештә шулай дип бәяләнеп тә килделәр. Тәнкыйть исә алар язган әсәрләренең эчтәлеген сөйләү юлында эш итте. Шунысы да бар, ул әдипләр берсе дә чын мәгънәсендәге саф реалист түгел иделәр. Әсәрләре гүяки зиһен, акыл һәм күңел саташуыннан гыйбарәт иде. Аларның кайсы шигырен генә алсак та, һичшиксез шушы хәл белән очрашабыз. Әдәби анализ белән эш итә белгән укучы моның шулай икәнлеген күреп, аңлап, белеп торды. Постмодернизм термины безнең фәндә юктан гына килеп чыкмады.

Соңгы вакытларда хәзерге татар әдәбиятын «соңарган-соңартылган модернизм» юнәлешендә хәрәкәт иттерергә теләүчеләр ул төр дөньяны танып белү һәм әдәби чагылдыру методының асылында мистицизм ятканлыгын онытып җибәрделәр булса кирәк. Бәлки акыл, зиһен, күңел саташуларына корылган шигъриятне чыннан да модернистик әдәбият дип билгеләргә кирәктер? Әмма моның белән килешүе хәзергә авыр. Тагын да шунысы бар:«соңартылган-соңарган модернизм» төшенчәсе кызыклы, үзе үк мәдәни ачыш! Бу хакта әдәби тәнкыйтә һәм әдәбият белемендә гадел рәвештә уйлыйсы-уйланасы бар әле.

Алга таба безнең татар шигърияте ничек һәм нинди юллардан үсәр? Бу сорауга, шушы аналитик мәкалә чикләреннән

чыкмыйча гына, бары тик бер төрле җавап бирергә мөмкин, ул — ирекле рух тантанасы юнәлешен алачак!

Шигырь гомумән дә ирекле рух тантанасына корылырга тиеш. Шундый шигърият кенә дөньякүләм масштабка чыга ала. Сиксәненче еллар башында аның орлыклары әдәбият бакчасына чәчелеп, инде ул күптән шаулап үсә дә башлагандыр? Хәер, һәр яңа чор, яңа дәвер шагыйрьләре ирекле рух тантанасында мәйданга чыгып, үз юнәлешләрен табалар. Монда да нәкъ шулай була бара төсле. Көндәлек җырларның эчтәлеген хасил иткән лубок шигърияте барлыкка килгән һәм үсеш алган кебек, классик юнәлешләр дә формалашып җитәрләр. Мәйдан — бар, вакыт бара тора.

*Январь, 2010.*

## РЕНАТ ХАРИСНЫҢ МӘХӘББӘТ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЛИРИК ГЕРОЙ

*Аналитик мәкалә*

XXI гасырга татар шигърияте XX йөздән шактый киң һәм югары үсештә килеп керде, үзенең дәрәҗәсен, алдынгы юнәлешләрен, табышларын дәвамчылыклы күтәрелештә көчәйтә барды. «Шартлы шигъри идеологик юнәлеш»нең байрагы һәрвакыт шагыйрь Ренат Харис кулында кала бирде. Урта буын шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат һәм башкалар ничек кенә ул беренчелек байрагын үз кулларына алырга теләмәсеннәр, аларның шигъриятендә Р.Хариска хас үзенчәлекләр (уртаклыклар шактый булуга карамастан) җитенкерәмәү аркасында бу мөмкин хәл түгел иде. Татар әдәби тәнкыйте дә Р.Харисның ул беренчелеген Равил Фәйзуллин белән бүлешүен ничек кенә теләмәсен, шул хакта шактый сүз кузгатып, берсен икенчесенә каршы куюда төрле фикер һәм бәя бирәмлекләрен сайлап бәянләп карамасын, бу беренчелекне Р.Харис шигърияте беркемгә дә бирмәде. Апты-

рагач, шагыйрьне бернинди төркемгә дә кермәүдә, үзенә бер дәрәҗә һәм үзенчәлек саклавында да дусларча «гаепләделәр». Тормышта Р.Харис үз шигъриятенең дәрәҗәсен һәм мәртәбәсен Р.Фәйзуллинга да, Р.Гаташка да, Зөлфәткә, М.Әгъламовка да, башка әдипләрнекенә дә каршы куймады. Ул даими үз юлында, һәрвакыт иҗатта булды. Сәяси-идеологик хәрәкәтнең эчендә кайнады, шул ук вакытта, үзе шуның эчендә кайнаган шәхес булып та, демократик үзгәрешләргә читтән торып бәя дә бирә белде. Р.Харис, шул рәвешле, шигырьдә һаман шагыйрь булып кала барды. Тормыш үзгәрешләре аның да үзгәрешләре иделәр, шигъри табышлары да укучыларга барып җитә торды. Шунысы гаять тә әһәмиятле, татар шигърияте өчен моның шулай булуы бигрәк тә кирәк иде: Р.Харис, татар булсын, рус булсын, бүтән милләтнеке булсын — һичнинди башка шагыйрьләрне кабатламады. Үз шигъри агымына хезмәт итүенә карамастан, ул һаман да шигырьдә Р.Харис булуыннан туктамады. Моның өчен, югыйсә, әллә нәрсә кирәк тә түгелдер сыман. Талантың бар икән — шул җиткән. Әмма әдәбият фәне, тәнкыйть сыман фикер йөртеп, мондый бәяләү белән генә чикләнеп кала алмый. Ул шушы талантның эчке һәм тышкы үзенчәлекләрен тикшереп-өйрәнеп, асылын ачыкларга, аларны системага салып аңлатырга, закончалыкларын билгеләргә тиешле.

Р.Харисның беренчелеге һәм шигъриятенең үз көчендә калуының төп сәбәбе әлбәттә шагыйрьнең әдәби юлын башта ук таба алуыннан килде. Әүвәле аның шундый булуы аңлашылып та җитмәде. Ул башкаларның иҗат алымнарын кабатлыйдыр сыман иде. Р.Харисны үз әдәби дөньясы, үз шигъри алымнары, үз милли герое, үз идеаллары, үз фикерләве булган чын әдип итеп 1981 нче елда басылып чыккан «Замана эзләре» шигырьләре җыентыгы күрсәтте. Баксак, ул чор әдәби тәнкыйте аның шушы зур уңышын билгеләргә тырышып та карамаган, хәтта, кызганыч, берничек тә бәяләми калдырган. Сүз премияләр, мактап әйтелгән, искәртелгән сүзләр хакында бармый, бәлки шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләрен тану хакында бара.

Хәер, Р.Харисның нинди шагыйрь булуы әле хәзер дә бәхәсләр уяту көченә ия. Мәсьәлә чишелмичә калдырылып киленә. Моны шигъри сәхифәләренең дәвам итүе белән бәйләп тә аңлатып була. Әмма, әдәби хронотоп системасы кысаларында караганда, Р.Харисның шигърияте́ндә, катгый сиземләнүче җирлек булуга бәйсез рәвештә, вакытның чиксезлегенә төбәлгән формалар бар, хәтта, мәсәлән, 80 нче елларда язылып та, аның шигырьләре үткәнгә дә, бүгенгегә дә, киләчәккә дә төбәлгәннәр. Мондый итеп яза белү өчен монументальлек кирәк. Аңа 60–80 нче елларда Е.Евтушенко, Р.Рождественский кебек рус әдипләре дә омтылды һәм зур әдәби уңышка ирештеләр. Әмма аларның шигърияте, монументальлеккә корылса да, шул шигырьләрендәге лирик герой үзе монументальлеккә ия түгел иде. Бу яктан Р.Харис хәтта дөньяда кабатланмас шагыйрь буларак бәяләнергә хаклы.

Алдан ук белдереп куярга тиешбез, безне әдәби тәнкыйть юнәлешендә бәяләп фикерләү кызыксындырмый. Сүзләребез дә әдәби тәнкыйть кысаларында алып барылмый. Максатыбыз әдәби күренешне ачу, ачыклау, аның закончалыкларын билгеләү белән чикләнә. Шунлыктан фикерләребез иҗатны бәяләү түгел, бәлки аның эчтәлеген аңлатуга корылды. Моның өчен Р.Харисның мәхәббәт шигырьләрендәге лирик герое тикшерелде, шушы тема-тематика эчендәге әсәрләренә ясаган анализларыбыз шагыйрьнең әсәрләре үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирде, аерым нәтиҗәләргә китерде.

## I

Р.Харисның мәхәббәт шигырьләрендә лирик герой өч үзенчәлеге белән истә кала: беренчесе — ул зәңгәр күзле, икенчесе — ул күңеле белән салкын, әмма андагы карларның-бозларның эрүен тели, аны кемдер эретергә тиеш, өченчесе — ул һаман-һаман да мәхәббәткә, үзен яратуларына мохтаҗ. Шушы сыйфатлары белән бу лирик герой М.Ю.Лермонтовның «Безнең заман герое» (1839–1840) романының төп герое Григорий Александрович Печоринны да хәтерләтә. Алардагы уртаклык хис дәрәҗәсендә бара. Әмма чорлары гына түгел,

аларның күңел стихияләре дә башка, фикер йөртү үзенчәлекләре дә төрле.

Лирик геройның үз-үзен тоюы Р.Хариста яхшы эшләнелгән, ул хәтта кайчан-нәрсә хис итәчәген дә алдан ук белеп тора. Башкалардан үзенә артыкны да таләп итми, алар мәхәббәт, ярату, соклану бирә алсалар, аңа шул да җитә. Тик ул хисләр ихлас, чын йөрәктән генә булсыннар:

Туры кара күзләремә,
Күзең сүзе тәңгәл микән
Телең әйткән сүзләреңә...

**(«Күзең буйлап».)**

Р.Харисның лирик герое укучыны мәхәббәттәге шушындый өстенлеге белән туктаусыз хәйран итә. Мәхәббәт корбаны кебек күзалланып, ул башкалардан өстен чыга бара. Яратуга ышанырга тели, әмма ышанып та җитә алмый.

Күзләремә туры кара...
Сау бул... Киттем... Күзең буйлап
Ят бер егет үтеп бара...

**(«Күзең буйлап».)**

Яки:

Синең кулда —
Синең балдак,
Минем кулда —
Минем балдак...

Хисләребезне булмый ялгап —
Балдакларны булмый алдап...

**(«*** Яфраксыз урманда...»)**

Шартлы билгеләрнең күңел хисләреннән өстен чыгарылуы белән шигырьләре аерылып торса да, Р.Харис иҗаты җәмгыятьтә кешенең бәхете мәсьәләсендә лирик геройның

туктаусыз борчылуына аерым басым ясый. Лирик герой бу яктан, ягъни җәмгатьчелек каршында тәүфыйклы, дөрес кеше образы буларак күз алдына килеп баса һәм үзенә карата укучыдан шушындый ук мөнәсәбәт таләп итү көченә ия булуын сиздерә. Монументаль сәнгатьтә сурәтләрнең кискен һәм үтә туры карашка ия икәнлеге бәхәс уятмый. Татар рәссамы Илдар Хановның сурәтләре шушындый көчкә ия, Константин Васильев (1942–1976), монументаль портретлар ясап, Казан, ә аннары Рәсәй тамашачысының күңелендә соклану хисләрен тудырды, «Мамай курганы»ндагы «Ватан-Ана» һәм башка дистәгә якын монументаль һәйкәлләр дә шундыйлардан.

* * *

Үпкәләттем, ахры,—
Стенага капландың.

Стена миннән җылырак, ахры, бу минутта...

Күзләрем — боз,
Күңелем — таш,
Йөрәгемдә, ахры,
Кар ява...

Эрисем килде —
Сулуым бозга
Әверелде үпкәмдә.

Кичер, иркәм,
Озак эредем —
Суык сүзем
Йөрәгемнән кояшымны
Сөйрәп чыгып киткәнгә.

Бу шигырь Р.Харисның лирик героен тулы чагылдырган әсәрләреннән берсе. Монда күтәрелгән фикерләр, уйлар, темалар мотив рәвешендә дә, фикер-тема һәм хис буларак та башка шигырьләрендә дә кабатлана, яңадан-яңа төсмерләр, эчтәлек ала. Лирик герой — салкын, әмма ул кайнарлык эзли (мәсәлән, «*** Кара миңа буран булып...» шигыре), «кораллы, теләкле» ир үзен чакырган яратканын яулый алмый кала (мәсәлән, «Ни-

чек?» шигыре), сөю хатирәсе калдырып үткән яз, аны яңасы алыштыра, алда яңа бер мәхәббәтме көтә (мәсәлән, «*** Җитте бу яз...» шигыре), яңгыр «бүрттерү» көченә ия, лирик герой моңа шатлана, чөнки барысы да бүртә-арта, анда гаилә кору теләге уяна (мәсәлән, «Яңгыр көзгесе» шигыре), хушлашу, әмма озатканда кул изәп калмау, чөнки китеп югалуын теләмәүдән, имеш (мәсәлән, «*** Мин киткәндә...» шигыре) — болардан күренгәнчә, бер үк төрле лирик герой, аның тирәсендәге тормыш ваклыклары да охшаш, хисләренең тарлыгы-киңлеге дә бер үк төрле, шул ук мәхәббәт темасы, әмма шигъри мотивларда аермалык аларны төрләндереп җибәрә, һәркайсына үз фәлсәфәсендә, үз мәгънәсендә ачылырга мөмкинлек бирелә.

Монументальлеккә корылган шигырьләрдә һәрвакыт шушындый үзенчәлекләр белән очрашабыз. Алар укучыны ерактан җәлеп итә, күңеле белән якынайган саен, аңардан өстен чыга, югарыга аша баралар. Р.Харисның шигъриятенең көче, тормыш дөреслегенең идеологик нигездә дөрес һәм тулы ачылуы белән бергә, темаларының мотив катламнарына кадәр җентекле эшләнүендә дә.

## II

Китте,
Ялгыз калдым.
Тәмәке
Тынычландыра алу көчен югалтты...—

дип белдерелә автор лирик геройның хисләрен «***Китте...» шигыренең беренче куплетында. Монда сагыну аркасында тынычлыкны югалту хакында сүз бара икәнлеге аңлашылып тора. Алга таба әсәрдә очрашуны теләү хисе тасвир ителә:

Аһ, ничек телим:
Йөгереп керсен иде дә,
Тетрәгән гәүдәсен
Иңнәремә элсен иде дә
Сыктасын,
Сыктасын,
Сыктасын иде.

Үзен яраттыру, сагындыру, шушы яраттыруы һәм сагындыруы белән елатырга теләве лирик геройның әлбәттә үзен-үзе яратуы буларак та укучының күңеленә тәэсир итә. Һәм менә лирик геройның үзенең яратмавы нинди тасвири картинада бирелә:

Тәмәкенең көле төшеп
Аның чәч төбен көйдергәч...

Мондый мәгъурурлык, үзен өстен кую, башкаларның аны яратуыннан тәм табуы һәм рәхәтлек тоюы монументальлек төсмере белән сугарылган лирик геройда менә шушындый рәвештә була да инде. Укучыны ул аптырашта калдыру көченә дә ия. Һәм менә лирик геройның усаллыгы тулысынча диярлек ачыла:

Кинәт туктасын иде.
Ычкындырсын иде
Иңнәремнән кулларын.
Башын иеп катып калсын иде,
Аяклары талсын иде,
Идәнгә аусын иде.

Әлбәттә укучы күз алдына монументаль мәгъруур лирик герой да, аңа җанын бирергә әзер, аңарга әсирләнгән һәм әсәрләнгән гашыйк җан да тулы картина буларак килеп баса. Р.Харис аңлы, тойгылы һәм тоемлы әдәби картиналарны тудыру остасы, бәхәс юк. Бу яктан ул үтә талантлы шагыйрь. Аның шушы сыйфаты хәтта поэтик чараларны кулланмый язганында да сизелә. Лирик геройның усаллыгын әдип бу шигырендә менә ничек тасвир итә:

Аяклары талсын иде,
Идәнгә аусын иде...—

дип яза да, һәм алга таба:

Гәүдәсе аша атлап чыгып китәр идем,
Калсын иде...—

дигән хыялда бирә.

Бу шигъри юллардагы мәгърурлык, мин-минлек, мәртәбә хисе монументаль геройга хас булганча зур осталык белән сурәтләнелгән. Кемгәдер мондый лирик герой кабахәт сыман тоела, кемдер аның чын ирләрчә булуына соклана ала. Бу шигъри картина укучыларның күңелендә төрлечә уела, төрле хисләр һәм фикерләр, мөнәсәбәт уята. Әмма лирик геройның мәгърурлыгы өшендереп алу көченә дә ия. Моны, нинди хисләр кичерүләренә дә карамастан, укучылар бердәй тоялар. Р.Харис шушы кадәр мәгърур монументаль героен да шигъри итә белә. Менә ул:

Аһ,
Син хәзер үк миңа тансык инде...—

дип, аның хисләрен бирә дә, лирик героен сагыну тойгылары тәэсиренә кабат кайтара. Шуның белән мәгърурлык аерым монументальлек сурәтендә калдырыла, шул рәвешле картина шигъри форма рәвешен ала, ә сагыну хисе эчтәлекне барлыкка китерә. Мондый әдәби күренеш бары тик монументальлеккә корылган әсәрләрдә генә була ала. Р.Хариста алар төп тенденцияне, иҗат үзенчәлеген хасил итәләр.

III

Монументаль сәнгатькә тормыш җылылыгы җитмәүчән була. Катгыйлык, мәгърурлык, өстенлек комачаулый, билгеле. Мондый сәнгать төрендә эротик алымнарны файдалану ярдәмендә мәсьәләне чишү юлы табылган. Һәм менә Р.Харис шигъриятендә дә бу шулай. Катгыйлык, мәгърурлык исә хисләрнең сафланып алуын, тойгылардагы кырпак тутыкның коелуын, чымырдаган йөрәк белән тузаннардан кагынып куюны барлыкка китерә. Мондый тойгыларны кичерү кемгәдер авыр да бирелергә мөмкин, хәтта күпләрдә чиркану да тудыра ала. Әмма монументальлек, никадәр өшендереп алса да, үз мескенлегеңне сиздерсә дә, ул, шул ук вакытта, бөеклекнең

бер вәкиле булуыңны тою хисен дә уята. Эротик элемент хисләрне кайнарлап ала. Моның шулай булуын Р.Харисның «Көзге сүрән мәхәббәт» шигырендә дә күрергә мөмкин.

Бу әсәр дүрт кисәккә бүленгән. Беренче кисәге ике куплеттан, өченчесе — өчтән, икенче һәм дүртенчеләре берәр куплеттан торалар. Шигырь верлибр формасына корылган.

Шагыйрь сагыну хисен мондый шигъри сурәт белән бирә:

1. Карасам күккә —
   Моң күрәм: синең моңың.
   (Сагыну тәэсир итә
   Микәнни күккә?..)

   Карасам бакчага,
   Лепелди башлый йөрәк:
   чияләр — синең иреннәр...
   Тизрәк сине күрәсем килә.

Иреннәр хакында искә алу һәм күрәсе килү тойгысын искәртү әлбәттә эротик элемент булып тора. Әмма монда монументальлек тә, эротик элемент кебек үк салмак, артык күпертелмәгән. Шулай да, «Сагыну тәэсир итә микәнни күккә?..» дип лирик геройның уйлануы, үзенең сагыну хисен күкләрнең сыйфаты итә белүе — бусы мәгъруранә монументальлеккә бәйле. Дөрес, шагыйрьләр-язучылар геройларының хисләрен табигать картиналары аша (бигрәк тә модернистик әсәрләрдә) бик оста сурәтлиләр. Хәзерге чор әдәбияты өчен андый формалар яңалык түгел. Әмма Р.Харис шигъриятендә эш башкачарак тора: лирик геройның эчке уйкичерешләренә табигать күренешләре буйсындырыла, ул алардан өстен, аларга хис-тойгыларын, уй-хыялларын ачар өчен ярдәмчеләре, хәтта хезмәт итүчеләре итеп карый, аларны үзенә тиң яки үзеннән өстен куя алмый. Әгәр дә эротик элемент булмаса, бу мәгърурлык йөрәкләрне өшетеп калдырыр иде.

2. Карасам күккә —
   Сагышың синең,
   Карасам бакчага —

Алмагачлар күлмәк сала,
Барам,
барам янына, барам...

Лирик герой табигатьне үзе белән тиң куяр иде, әмма ул аның сөеклесенең хисләре турында сөйләүче икән. Монда һичбер төрле кимсетеп карау юк, түбәнлеккә төшерүне дә эзләү урынсыз.

Эротик элемент лирик геройның хисләрен җанлы итә бара, «алмагачлар күлмәк сала» дигәненнән соң хәтта ашкыну хисен дә тудыра. Лирик герой сагыну тойгыларында гына кала алмый. Алар, бу гашыйклар, бергә булырлар дигән өмет, күзаллау барлыкка китерелә.

3. Карасам —
инде күптән
теге болытлар киткән күктән.
Алар урынына
агы килгән,
туй күлмәге кигән.

Йөрәгем — дерт!
Хисләр — күкерт...
Тәмәке кабызам...
Тәмәке генә.

Төтене болытка менә,
Менә,
Менә...
Җитә алмый.
Ә күктә зәңгәр моң.
Синекеме ул?
Минекеме?

Ике арадагы мөнәсәбәтләре туйга барып җитми. Туй әлбәттә ике гашыйкны аерылмаслык бер итәр сыман. Лирик геройга күкләр дә туй күлмәген кигән буларак күзалланалар. Кыз һәм күкләр сурәттә шулай үзара параллель куелалар. Әгәр дә лирик геройның тәмәке кабызуын, тәмәке тартуын аның уйлануы билгесе дип кабул итсәк, төтене күкләргә барып

җитмәвен (ә ул менә, менә, менә...) — туйларга уе ирешмәве дип аңларга тиеш булабыз. Зәңгәр моң исә хыял, өмет, теләкләрнең буш калуы, әлбәттә.

4. Карасам —
күктән кар ява.
Тирә-юнь тып-тын.
Тыныч,
Сафлык.
Ак карда шыгыр-шыгыр эзем.
Аның белән янәшә
бер эз дә юк.
Салкын дым...

Ялгыз калу шигырьдә шушылай сурәтләнелә. Монда монументальлекнең тантанасы булырга тиешле шигъри юллар юк дәрәҗәсендә. Шагыйрь аларның аз микъдарда булуын кирәк тапкан. Бу аның лирик героен монументаль дәрәҗәдә бөек итеп тасвирлавына һичбер зыян китерми. Мондагы очракта ялгызлык үзе үк, шушы кадәр эротик хисомтылышлардан узып та, сафлык һәм тынычлык тойгыларына туры китерелгән. Кар яуган минутларда монументаль һәйкәлләр дә кечерәеп калган кебек күренәләр. Бу шигырендә дә Р.Харис үз иҗат осталыгына хилафлык китермәгән.

IV

Яшьлек белән картлык очрашуы Р.Харисның мәхәббәт шигъриятенең аерым бер тематикасы да булып тора. Сабырсыз яшьлек янында картлык тыйнак калырга тиеш. Әмма ул яшьлектән мәхәббәт таләп итә. Лирик герой монда да үзенә гашыйк булуларына мохтаҗ.

Гашыйк бул син миңа,
Гашыйк бул син,
Вакытлыча гына булса да,
Күзләремә сеңгән яшьлек төсем
Кояш, яңгырлардан уңса да...

**(«Гашыйк бул син миңа».)**

Лирик герой «йөрәгемдә беркем кагылмаган хисләр бар» дип белдерә, күзләремдә «уңмый торган җете төсләр бар», ди. Аның яшьлегенең төсе киткән, әмма бераз калган да әле, алары чекрәеп торалар. Күпләр электә аны күрмичә, янынннан «җил кебек» үткәннәр, ә менә син аның яныннан болай гына узма. Башкалар үткәндә ул тын торган, ә менә син узганда «талпынып», «җилкенеп» куйган.

Лирик геройга вакытлы мәхәббәт кенә кирәк, «бер язга гына күңелен чәчәккә төрүче» булсын ул. Башкасына дәгъва итми.

Р.Харисның лирик герое даими, сүнмәс мәхәббәтне күтәрә алмый. Моның сәбәбе дә шул ук монументальлек белән бәйле. Башкача булганда, лирик геройның монументаль үзенчәлекләре артка чигенер, югалыр иде. Мәңгелек белән вакытчалык каршылыгы лирик геройның бөеклеге каршында хәтта мәхәббәтнең дә (шагыйрьләр дәгъва кылган һәм мәңге сүнми торган дип аталган мәхәббәтнең дә) бер «кабынып алу» буларак күзаллануы, вакытлы күренешкә әверелдерелүе үзе үк көтелмәгән тойгылар уята.

Гашыйк бул син миңа —
Үкенмәссең...
Вакытлыча гына...
Китәрсең...
Тик бер язга гына күңелемне
Чәчәк тулы бакча итәрсең...

Гашыйк бул син миңа...

**(«Гашыйк бул син миңа».)**

Лирик геройның яшьлектән калган ярасы бар. Әмма ул үзе — төзек «көймә», дулкыннар яра, «ялгыз ярга җитмәс борын татып калыйм бар рәхәтне» дип ашкына, ә ватык көймәләр ярда кала («Дулкын керсен...» шигыре). «Су кермәсен,/ Дулкын керсен/ Минем яшьлек ярасына» дигәнендә әлбәттә яшьлек ярасын яңа хисләрнең төзәтәчәге хакындагы фикер буларак аңларга кирәк. Монда дулкын белән хисләр янәшәлектә (ассо-

циатив параллельлектә) куелалар, су белән хәвеф, сагыш, борчылу үзара мәгънәдәш итеп алыналар.

«***Мин бәхетле итәр идем сине...» шигырендә лирик герой ташлап калдырылганны, ягъни «ярда яткан ялгыз каекны»бәхетле итәргә теләгeн сөйли, чөнки ул «җаный» да «һәр күңелдә зәңгәр җилкән киереп»«йөзәргә лаеклы» икән. Бу «җаный»«ләйсән тулы зәңгәр болыт» та әле. Әмма лирик герой «күңелемдә җылылык җитми» дип уфтанып куя. Монда «күңел җылысы» әлбәттә метафорик мәгънәгә ия, ул игелек иясе була алу хакында да белдерү буларак аңлашыла.

Бу шигырьдәге лирик герой үзен дә бәхетсез бугаймын дип атый, шуңа күрә сине онытыйм, «ә үзеңә калдыр мең түзем», ди. Шушы рәвешле сурәтләр һәм образлы фикерләүләр ярдәмендә монументальлек тудырыла. Дертләп кабынып, янып алырга мәҗбүр лирик герой тиздән суына, аның «көтмәгәндә учагы сүнә», ә аннары ул кабат кабынырга, башка мәхәббәткә әзер.

Р.Харисның мәхәббәт шигырьләрендә бу туктаусыз шулай. Мондый хисләр берсеннән икенчесенә күчеп баралар.

Ян, дисең син,
Ян, дисең син,
Ян, дисең син!
Яктысымы,
Җылысымы сиңа кирәк?
Алар миндә
Һава белән Җир шикелле —
Якты зәңгәр күзләремдә
Җылы йөрәк.

**(«Ян, дисең син...»)**

Лирик герой һәр яктылыкта җылы, һәр җылыда яктылык булу мәҗбүри түгеллеге хакында фәлсәфә кора. Мәгънәле сүзләр, билгеле. Лирик геройның күңеле яктылык белән бергә җылылык күрсәтә алганда гына канәгать итәчәк — бусы инде монументальлекнең идеологиягә хезмәт итүенә ачык бер мисал да булып тора.

Р.Харисның мәхәббәт шигырьләре монументальлеккә корылып, лирик геройны тормыш ваклыкларыннан һәм вакытлы күренешләрдән өстен сыйфатында таныргa мәҗбүр итә. Әмма ул үз «эго»сыннан гына түгел, хәтта заман идеологиясеннән дә азат түгел. Абсолют шигъри ирек аңарда юк һәм моңа ул мохтаҗ да түгел. Идеологик яктан төзек һәм ныклы булуы аркасында лирик геройның әле сүнеп, әле балкып алучы мәхәббәт хисләре дә аклана, чөнки ул, шушы үзгәрешләренә дә карамастан, даимсезлектә даимилек таба. Лирик герой янакөя ярата, әмма иреннәрдән ары узмый — бу фикер барлык шигырьләрендә дә диярлек кабатланып, бу мотив Р.Харис поэзиясендәге идеологик чараларның тагын берсе ролен үти. Өченчесе — лирик геройның хатыны бар. Ә лирик герой һаман да менә аны сөя, башка учакларда янып алса да, үз хатынына даими тугрылыклы. Бусы да шигъри идеология ролен үти, идея һәм фикер бирү чикләреннән югары күтәрелү билгесе.

Шигырьләрдәге бер үк фикерләрнең һәм идеяләрнең кабатланышы, төрле яклап аларның бер ноктага төбәлгәндәй яктыртылышы, бер сурәттән икенчесенә үзгәрешсез күчерелә барылуы фикер сайлыгыннан түгел, бәлки идеология тудырудан килә.

Р.Харис бу яктан да көчле шагыйрьләребезнең берсе булды. Ул үз шигырьләренә шушы идеологик фикерләү юнәлешләрен замананың үзеннән дә әзер килеш алды, аны үзенә дә үз күңелендә, акылында-зиһенендә тудырып бирә алучы әдип сыйфатында җитлекте, шундый буласын беренче адымнарыннан ук күрсәтте. Аның шулай булуы иҗтимагыйсәяси лирикасыннан гына түгел, бәлки мәхәббәт шигырьләреннән дә ачык аңлашылып, күренеп тора иде.

*2011.*

# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘ КҮЗӘТҮ ҺӘМ ШИГЪРИ БӘЯН БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ

## I

1970 нче, тагын да 1980 нче еллар башы татар зыялы яшьләре арасында мәртәбәле бер хозурлык һәм тантаналы романтик хисләр белән укылып, киләчәк тормышның бәхет-сәгадәт юлына илтүче, үз көненең сагышын, кайгысын, тарлыгын һәм кечелеген тойдыручы әсәрләр сыман кабул ителә иделәр Равил Фәйзуллин шигырьләре. Аларны коры декламатив рәвештә түгел, бәлки чын дулкынлану хисенә төренеп укыганда тәмам аңлашылалар һәм тирән уйларга, фикер-тойгы агымнарына салалар. Шул хисләр эчендә Р.Фәйзуллинның лирик герое күңелләргә күчеп яши башлый. Әсәрләренең җиңел кабул ителүе сөендерә: эчтәлекне һәркем үзенчә төшенә, аңлата ала. Бигрәк тә мәгънә-идея чокынып аптыратучылар өчен мәйданлы иделәр алар. Шигырьнең хикмәте күңелгә хуш килүендә генә түгел, аның акылга да сыешлы булуында. Бу мәгъкулият кануны эчендә уй йөртә белү (бәяләү хакында әйтергә дә базмыйбыз) кысаларын санга сукмаганда, әдәбият фәненең үз күләгәсе белән үзенең уйнап утыруыннан гайрегә ирешә алмаячагыбыз колаклардан яшереп кенә сөйләнә торган сүз түгел. Ул инде күптән телләрдә йөри, кабатланып-кабатланып, кат-кат ишетелә. Р.Фәйзуллинның кайсыбер шигырьләре, күңелгә хуш килмәгән очракта, акылга сыешлы һәм ярашлы иделәр. Иң кирәге, шигырьдә ул күп вакытта төрен-мәрәсим, ягъни церемонияләр ясап тормый, итагать итүне белми, сүздә чибәрләнү-бизәнү белән иркәлек күрсәтеп аптыратмый, бәлки әйтә дә куя. Бу әйтеп куюлары турыдан килеп чыгамы, әллә eрактанрак әйләндерелеп йөртелеп аптыратамы (мәсәлән, «Сәйдәш» поэмасы) — болары аның сайлаган жанрының хасиятенә, күңеленең стихиясенә бәйле шулай төзеләләр, килеп чыгалар. Р.Фәйзуллин шигърияте футуристик алымнарны үзләштергән, әмма ул слубка икенче төрле, торгынлык чоры кешесенең теләк-омтылышлары белән тулы рухи эзләнүне, дәртле җанны салган әдип буларак укучы каршында тиз үсте, әдәбиятта ныгыды һәм замандашлары арасында

шагыйрьләр хыялланып та ирешә алмаган төрле дәрәҗәдәге биеклекләргә күтәрелеп, халыкның һәм дәүләтнең кыйммәтсенеп-тарланып-сайланып һәм хөрмәтләп кенә бирә торган шанлы исем-дәрәҗәләрен алды. Болары бер хәл. Ә менә Р.Фәйзуллин шигъриятенең асыл хикмәтләре хакыйкатьтә-чынлыкта нәрсәдә һәмниләрдә соң? Бу серле шигъри йомгакның җеп очы булырга тиештер бит инде — аны табуга һәм тартуга ук һәммәсе ачык хәлдә мәгънәви энҗеләр рәвешендә савыла, аңлашыла башлар иде. Бу җеп очы эчтәлекне дә, форманы да бердәй ачып, сүзләренең серен төшенүгә китерәчәк — бәхәссез!

Әсәрләрне бары тематик яктан тикшерү асылда бер үк нәтиҗәләргә китереп, безнең татар шигърияте тарихи, фәлсәфи, көнкүреш-иҗтимагый, әхлакый, сәяси, экологик темалар белән чәчәк ата дигән мең кат таныш, әйтелгән, расланган, мәктәп баскычларыннан билгеле һәм өйрәнелгән вульгар-социологик нәтиҗәләргә генә китерәчәк, татар әдәбиятының үзенчәлекләре дә, әсәрләренең хикмәтләре дә ачылмый калачак. Әмма ул, без эзләргә тиешле, акылга сыешлы, Р.Фәйзуллин шигъриятен аңлый-аңлата, ача, төшендерә-белдерә-таныта, хәтта «сүтеп куячак» җеп очы нәрсәдә яки, һич югы, нинди соң?

Әдәбиятыбыз фәне бу мәсьәләне кызык кына чиште һәм бу сорауга әлегә яшь һәм урта буын саналган галимнәребезнең хезмәтләре белән эзләнүле җавап бирде. Академик Д.Заһидуллина, япон әдәбиятын яхшы белгәнлекләре сәбәпле булыр: «Р.Фәйзуллин иҗатында классик хокку яки танкадагы кебек аерым бер табигать яки тормыш күренешен күзәтү-тергезү аша сагышлы хисләр бәйләме тудырган үрнәкләр бар»[1],— дип юкка гына расламыйдыр? Әмма галимә, бу юлда алга таба сүзләрен дәвам иткәндә, «ләкин» сүзен куллана һәм, Р.Фәйзуллин шигъриятен бәяләп: «... Классик япон шигърияте өчен мәҗбүри саналырга тиешле хисси төсмерләр (моно-но-

[1]*Заһидуллина Д.* «Шаш, рухым, дуласын җан!»: Р.Фәйзуллинның 1960-1980 еллар иҗаты: фәлсәфи үзенчәлеге һәм поэтикасы // Казан утлары.— 2013.— №8.— Б. 123.

аварэ, саби, ваби, сибуми, каруми) ирекле урнаша, шуңа аларның көчеше-үзгәреше “төзелеп бетмәгән күпер” концепциясеннән читкә китә»[1],— ди. Фикерләренең дәлиленә шагыйрьнең өчьюллык «Көзге яңгыр» шигыре мисалга китерелә, аның иҗекләр структурасы 7-8-8 үлчәменә корылганлыгы ачыклап узыла[2]. Дөрес, мондый шигъри үлчәм силлабик-сеҗе (сәҗигъ) һәм гаруз системаларында юктыр, японныкында бардыр дигән хәерсез күзаллау барлыкка килә.

Әмма бу — башка мәсьәлә. Шигырьгә кайтыйк. Ул моңардан гыйбарәт:

КӨЗГЕ ЯҢГЫР

Торналар китеп бара.

Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

Бу әсәрдә, беренчедән, шигырь таләпләренә туры килүен раслаучы ни төзек ритм, ни тышкы булсын, ни эчке рифмалар юк. Кемдер, бу — шигырь түгел, дияр. Кемдер аны — ак шигырь яки верлибр, дияр. Икесенә дә сүзләрен раслар өчен әсәрдә дәлилләр җитәрлек табылыр. Формадан чыгып фикер йөрткәндә алар икесе дә хаклы булырлар. Әмма бу әсәрдә хис бар. Шагыйрь хисне шулкадәр шигъри итеп сурәтли, ирексездән хәйранга каласың. Барыбыз да бала чактан беләбез: яңгыр болытларның күңеле тулганнан яумый һәм болытларның да күңеле хушлашып китеп барган кошларның канатлары тиеп китүдән тулмый. Әмма мондый бәян — шигырь! Шигъри мантыйкның бөеклеге шунда — ул ышандыра, хис иттертә, серле хакыйкатьне ача. Шигърият галиҗәнабы алдында хөрмәт белән башыбызны иягә мәҗбүрбез. Рух тантанасы шушы түгелме? Без дә, шагыйрьнең үз теленнән алып, Д.Заһидуллина кебек: «Шаш, рухым, дуласын җан!»— дибез.

---

[1] *Заһидуллина Д.* «Шаш, рухым, дуласын җан!».— Б.122–123.
[2] Шунда ук.— Б.123.

Димәк, Р.Фәйзуллинның бу әсәре шигырь булып чыга һәм аның шигърилеген бәян мантыйгы дәлилләп торганлыгы безгә төгәл ачыла.

Шул ук вакытта Акъегетнең (Р.Фәйзуллинның энесе Рөстәм Фәйзуллин, нечкә бәгырьле, затлы шагыйрьләребезнең берсе) шигырьләре искә төшә. Аның иҗатыннан бер генә әсәрен мисалга алыйк:

ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Ә күк шундый зәңгәр,
шундый зәңгәр —
Тамчы булып тама зәңгәрлек!
Шундый иркен дөнья,
шундый җиңел!—
Пәрәвезләр оча,
мамык оча
һаваларда Җирне күтәреп![1]

Һәм безнең рухыбыз: «Гаҗәеп бу, гаҗәеп!»— дип тантана итә. Шигърилеккә ул әсәрдә берәр хилафлык табылырмы? Юк! Тагын да шунысы сокландыра, гаҗәпкә калдыра: бу ике шигырь дә бер үк алымда, бер үк манерада, бер үк аһәңдә, бер үк слубта язылганнар! С.Хәким сүзләре белән әйтсәк (Акъегет китабына сүз башы юлланмасын ул язган): «Акъегет шигырь үзен мең еллар буена сынаган юлны сайлаган»[2]. Сүз әлбәттә кыска төзек шигъри формалар хакында бара.

Тагын да шунысы әһәмиятле, С.Хәким мәкаләсендә Сәгъди, Хафиз, Дәрдемәндләрнең иҗатлары искә алынып, рус әдәбиятының символистлары А.Блок һәм А.Ахматова да шул җепкә куелып, аларның «иҗаты өчен иң характерлы шигырьләр шушылар»[3], ди әдип. Шәрык әдәбиятына әлбәттә электән, чишмә башыннан ук кыска формалар характерлы.

---

[1] *Акъегет.* Ак болытлар шәүләсе: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.— Б.47.

[2] *Хәким С.* Иҗатка рухландырсын // *Акъегет.* Акболыт шәүләсе.— Б.6.

[3] *Хәким С.* Күрсәтелгән хезмәт.— Б.6.

Хәер, ул безнең әдәбиятыбызның борынгы дәверендәге ташъязмаларда, «Ырк битиг»тә дә шулай. Урта гасырлардагы фәрд, бәет, кыйтга, робагый кебек жанрлар берьюллык, икеюллык, түртьюллыклардан гыйбарәт. Жанрларны билгеләгәндә Шәрык әдәбияты асылда формаларга бәйле эш йөртә. Эчтәлек ягыннан үзара охшаш газәл һәм касыйдә (Шәрык әдәбиятларында иң киң таралган жанрлар) икесе дә мәхәббәт хисләрен тасвирлауга корылганнар. Газәлнең Аллаһы тәгаләгә, касыйдәнең Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган булуларын тәҗрибәсез укучы сизми дә. Шәрыкта жанрны формага бәйле билгелиләр. Ә адресат ул — Шәрык өчен форма. Шаһларга язылучы мәдхияне ярлы кешегә атый алмыйлар, аның өчен нәсыйхәт жанры бар.

Хәер, модернизм дәверенә кадәр Европа әдәбиятларында да ул шулай иде. 1849 нчы елдан фрацузта үзен күрсәтә башлаган модернизм сәнгатьчәлекне максат итеп куя һәм әдәбиятның төп берәмлеге, сурәтләгән әйберсе хис дип белдерә. Модернистлар мәдәният өлкәсендә тантана итә башлый, модернизм-җәдитчелек дәвере башланып китә. Хисне тасвирлау ысулларының чиксезлеге, алымнарның төрлелеге шул чорларда ачыклана. С.Хәким искәрткән Сәгъди, Хафизның шигърияте (формаларда кыска булсыннар) — башка агымнан, сурәтләү алымнары белән Дәрдемәнд тә алардан кисен аерылып тора. Ул — А.Блок, А.Ахматова слубы агымында, символизм юлында. Дәрдемәнднең тәгъбирче шагыйрь, ягъни символист шагыйрь икәнлеге хакында Г.Ибраһимов «Татар шагыйрьләре»ендә шактый киң тукталып үтә[1]. Хәер, бусы да башка мәсьәлә.

Акъегетнең дә шигъри формалары Дәрдемәнднекенә тартым. Әмма ул да шулай ук — башка агым вәкиле. Формаларны охшаш итеп, күпләр Р.Фәйзуллин шигъриятенә ияреп карадылар. Әмма Р.Фәйзуллин бирә алган кебек итеп импрессионистик шигъри сөремне, ни кыска шәкелдә булсын, ни озын формаларда булсын, ясап чыгара алмадылар. Акъегетнең

---

[1]*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.— Б.94–110.

даһилыгында алар импрессионистик шигъри сөрем түгел, бәлки импрессионистик шигъри картина, импрессонистик шигъри сурәт характерын алдылар: детальләр — төгәл, ачык, нәзәкәтле, бизәкле һәм төсләр гармониясендә эшләнелгән — чын мәгънәсендә сәнгать әсәре. Һәм безнең Р.Фәйзуллинда да сәнгать ягы көчле, әмма ул ипрессионистик шигъри сөрем анда башкачарак, аңарда әдәбилек шигърияченең асылын тәшкил итә, шигырьләрен чын әдәби әсәр ясый. Хикмәте дә әнә шул импрессионистик шигъри сөремдә, әлбәттә.

## II

Кечкенә мәкаләбезнең шушындый озын «кереш» өлешеннән соң төп темага күчәбез. Формасы уңышлы килеп чыкмаган, диярсез. Хакыйкатьне ачу максатында алга куелган мәсьәләгә якын килү өчен башка юл табалмавыбыз аркасында ул шулай булды. Һәм без, Р.Фәйзуллинның шигъри алымының хикмәте — импрессонистик шигъри сөремдә, дидек. Бу сүзләр тезмәсе «әсәре кызыклы килеп чыккан, фикерләре бай һәм фәлсәфи» дип сөйләргә, ишетергә, уйларга өйрәнгән татар акылы өчен ят һәм сәер яңгырый торгандыр — бәхәсләшмибез, дөньяның бүген-иртәгә генә үзгәрүен дә өмет итмибез. Әмма кулланылган терминны аңлатып китүебез дә хәерле.

«Импрессионистик шигъри сөрем» дигән сүз русчалатып уйлап күнеккән сәнгатьчеләр телендә «импрессонистический мазок» терминыннан чыга. Безнең татар сүзлекләрендә «мазок» сүзе «буялыш, буяу төшерү» дип бирелә[1]. Әмма табигый яңгырамыйлар. Импрессионист рәссамның ясаган картинасын күреп, аннан берни аңламаска, нәрсәнең-нәрсә икәнлеген төшенмәскә, сурәтләрне бары шәйләргә генә дә мөмкин. Бераз читкәрәк китәсең, картинадагы шәүләләр рәсемгә әверелә, ачык күренешләр барлыкка килә. «Мазок»лар, ягъни сөремнәр, шулай итеп, гаҗәеп гүзәл рәвешкә керәләр. Мондый рәсемнең «мазок»ларын «сөрем»нәр димичә, нәрсә дисең? Го-

---

[1] Русско-татарский словарь / Под ред. *Ганиева Ф.А.*— М.: Рус. яз., 1984.— С.255.

мер-гомергә Европа белән тыгыз бәйләнештә яшәгән, шул ук вакытта үзләре дә булып кала алган, XIX йөздә Европа университетларында даими белем алган төрек зыялылары үз телләрендә «мазок»ны «сөрмәк» яки «сөрем» дип беләләр, кулланалар. Безнең татар телендә дә «сөрмә», «сөрмәләү» сүзләре кулланыла. «Мазок» сүзен без шуннан чыгып «сөрем» дип бирдек. Аннары тагын шунысы кызыклы, халкыбызда томанлырак күренешкә — «сөрем», диләр, ул русның «смог» сүзенә туры килә. Бу исә «сөрем» төшенчәсенең эчтәлеген тагын да киңәйтеп җибәрә. Һөнәрченең «мазня»сы белән рәссамның «мазог»ы арасында бөек аерма бар, бездәге «буялмыш», ягъни «буяштырып ташлау» белән «сөрем» арасындагы аерма кебек үк. Аннары, «буялмыш» сүзендә «пычратылган», ягъни «мазня» мәгънәсе дә бар. Ә Р.Фәйзуллин буяулар белән түгел, әдәби шигъри сүз белән иҗат итүче шагыйрь.

Р.Фәйзуллинның «Көзге яңгыр» шигырен кабат искә төшерик. Әсәрнең беренче юлы: «Торналар китеп бара». Бу — тормыш күренеше, аны күзәтү. Шигырьнең аерым куплет буларак бирелгән икенче һәм өченче юллары — «Кош канатлары орынгач, болытларның күңеле тулды» — әдәби бәян бирү өлеше. Ул сагыш, моң белән тулы. Аларны укыганда көзге көндә яңгыр астында очып барган кошлар күз алдына килә. Бу юллардан бер укучының зиһене мәгънәле күренеш таба, икенчеләр аларда фәлсәфә күрә, өченчеләр хис-кичереш тоялар. Импрессионистик ысулның хикмәте дә шунда — һәркем әсәрне үзенчә кабул итәрлек, аңларлык һәм аңлатырлык әсәр тудырыла.

Р.Фәйзуллин кыска шигырьләрен дә, «озын»нарын да «этюд» дип билгели ара-тирә. Рәсем сәнгатенә караган жанр атамаларының әдәби формалар белән уртаклыгы мәсьәләсе кызыклы һәм өйрәнелмәгән күренеш. Әдәбиятта бу күренеш импрессионистлар чорында көч алып китә. Шагыйрьләрнең мондый уртаклыкларны тоюлары һәм иҗатларында «рәссамнарча» эш итүләре әдәбиятның сәнгать төрләренә шактый якынаюы хакында сөйли. Сәнгать төрләренең үсеше һәм аларның дөньяны тасвирлаудан ачыклауга таба борылулары модернист рәссамнар фәлсәфәсе белән генә түгел, Р.Вагнер

кебек бөек композиторлар иҗаты белән дә алга сөрелде. Ул хәтта «Нибелунга балдагы»[1] дип аталган шигъри-драматик трилогия иҗат итә һәм дөньяга әдип буларак та танылa. Тагын шунысы да әһәмиятле, башка сәнгать төрләре белән чагыштырганда, барыбер дә рәсем сәнгате бүгенге көндә дә алдынгы юнәлешләрне мәйданга чыгарып, иҗатчыларны авангардта үзенә ияртеп бара. Р.Фәйзуллинның иҗатта рәссамнарга якын торуын сиздерүе аның да алгы сафларда ашкынып яшәргә омтылышы һәм яшәве хакында сөйли.

Шигырьнең бөеклеген аңлар өчен аның асылына ирешергә кирәк. Фән төшенеп кенә калмый. Ул аңлатырга тиеш. Әдәбият белеме фәне, төгәл фәннәрдән аермалы буларак, аңлатып бирә алуы белән яши. Шушы үзенчәлеге белән ул фәлсәфә фәненә тартым, әмма аңардан аерылып та тора. Әдәбият фәне әдәбиятны өйрәнүе белән «фән» турындагы фән ролен башкара, матур әдәбиятның метод-слуб чараларын өйрәнү ноктасына бәйле рәвештә аңлатмаларын кора. Метод-слуб мәсьәләрен атлап кына узып, игътибардан алып ташлап фикер йөртергә никадәр генә тырышмыйк, асылсыз, нигезсез фикерләмәләр белән генә фәнебезне тутырырбыз. Р.Фәйзуллин шигъриятен аңлар өчен аның иҗат слубын ачу-ачыклау төп мәсьәләләрнең тагын да берсе булып тора.

### III

Үткән XX гасырның икенче чирегеннән алып ахыргы дистә елына кадәр татар әдәбияты социалистик реализм мөлкәтлегендә яшәде. 60 нчы елларда әдәбият мәйданына күтәрелгән Р.Фәйзуллин да шуның бер вәкиле иде. Социалистик реализм безнең татар әдәбиятында футуризм, имажинизм, ипрессонизм, экспрессионизм, романтизм, реализм, натурализм кебек һәм 20–30 елларда яшәгән башка төр иҗат стильләре, мәктәпләре, агымнары вәкилләренең шартлы «кушылуыннан», «суммасыннан», «берләшү» тантанасы белән игълан ителгән метод иде. Дөрес,

[1]*Вагнер Р.* Кольцо Нибелунга: Избранные труды.— М.: ЭКСМО-Пресс, 2001.— С.18–399.

коммунистлар («Ленин социалистлары») партиясенең сыйнфый көрәш принциплары нигезендә иҗат иткән әдипләр чын мәгънәсендә социалистик реализм колачында иделәр. Алар коммунистик идеология хезмәтендә булдылар. 60 нчы елларга социализм принципта төзелеп бетеп, сыйнфый көрәш мәсьәләсе чишелде. Бары әхлак, экология проблемаларын гына хәл итәсе калды, ягъни, илдә һәркем аң иясе икәнлеге, әмма, ни кызганыч, аларның әлегә акыл үсешенә ия түгеллеге ачыкланды. Һәм тәрбия эше башланды...

Акыл — кешелекнең әзәлдән килгән проблемасы иде. Фәлсәфә гыйлеме шушы мәсьәләне чишү белән шөгыльләнүне үз өстенә алган булса да, марксистик-ленинчыл фәлсәфәдә ул аңны өйрәнү һәм тәрбияләү белән чикләнде, моның өчен акыл төшенчәсен аң төшенчәсе белән алыштырды. Әдәбият — фәлсәфә түгел. Аның өлкәсе — хис һәм акыл. Әдәбият фәлсәфә була алмый, әмма фәлсәфәчелек итә, фәлсәфәлек кора, фәлсәфәи нигездә тора ала. Шуның белән ул акыллы тоела да. Акыл бөеклеген әдәбиятта хәтта импрессионистик сөрем дә бирә алмый, чөнки ул сәнгать чарасы булып тора. Аны шуңа да сәнгать чарасыннан әдәби чарага эверелдерергә кирәк. Бу мәсьәлә Европа әдәбиятларында, хәтта импрессионизм «аталары» тарафыннан да (Стефан Маларме, Поль Верлен, Артур Рембо, Жюль Лафорг һ.б. турында сүз бара) тәмам хәл ителмичә, ачыкланылып бетмичә, чишелергә асыл юлы табылмыйча «калдырылган»[1]. Хәзер инде ул хакта язып тормыйлар.

Әсәрләре, әдәби иҗат манерасы белән Р.Фәйзуллин импрессионистик әдәби сөрем бирәмлекләрен шигърияттә тудыру, иҗат итү юлын тапкан һәм шуның белән дөнья әдәбияты үсеше куйган сорауларга җавап биргән. Аның, татар әдәбияты вәкиле булып та, дөньякүләм югары дәрәҗәле әдип икәнлеген бу үзенчәлеге ачык күрсәтеп тора.

---

[1]***Карагыз:****Шиллер Ф.П.* История Западно-европейской литературы Нового времени.— Т.III.— 2-е изд-е.— М.: Изд-во Наркомпросса РСФСР, 1938.— С.4–80.

Суфилар теле белән әйтсәк, илаһи сүз генә «башлангыч акыл» була ала[1]. Ә чын шигырь үзе үк илаһи сүз түгелме? «Башлангыч акыл» («изначальный, или всеобщий, ум» теориясе Ибне-Гарәби (1113–1241) тарафыннан эшләнелгән һәм тугыз гасыр буена кат-кат сыналып килгән санала[2].

Импрессионистик шигъри сөрем дип без хис-тойгы уяту көченә ия булган әдәби бәян һәм күзәтү бирәмлекләрен алабыз. Шунысы әһәмиятле, күзәтү бирәмлеге буларак бирелгән шигъри юлның яки юлларның эчтәлеген һәммәбез дә бертөрле кабул итәбез һәм аңлыйбыз. Ә әдәби бәян мәсьәләсенә килгәндә, эш башкача тора. Әдәби бәян бирәмлеге җиткергән эчтәлекне төрле укучы төрлечә кабул итә, аңлый һәм аңлата ала. Мәсәлән, әлеге дә баягы «Көзге яңгыр» шигырендә боларның икесе дә бар: 1) «Торналар китеп бара» — күзәтү бирәмлеге, һәркем тарафыннан бәхәссез кабул ителә, чөнки хәбәр туры мәгънәсендә бирелгән; 2) «Кош канатлары орынгач, болытларның күңеле тулды» — әдәби бәян бирәмлеге, бу юлларның эчтәлеген һәр кеше үзенчә аңлап кабул итә, төшенгәненчә аңлата, алар нигезендә хәтта фәлсәфә кора ала.

Әдәби бәяннең, күзәтүдән аермалы буларак, тагын да бер үзенчәлеге шунда — ул шигырьгә фәлсәфилек төсе-төсмере бирә. Шуның сәбәпле илаһилык белән очрашу хисе укучы күңелендә туа, ягъни шигърият барлыкка килә. Бу әдәби бәян асылы белән «башлангыч акыл» бирүче, хисне генә түгел, зиһенне дә кузгатучы көчкә ия. Укучыда уйлану теләге туа, аңа фикер йөртүгә этәргеч ясала. Уйлану — кеше зиһененең рәхәтлек кичерүе генә түгел, нәрсәнедер төшенеп, аңлап алу тойгысын белән бергә барырга тиеш. Боларга этәргечне Р.Фәйзуллин шигырьләрендә әдәби бәян бирәмлегенең эчтәлеге бирә. Менә шуңа күрә дә әдәби бәянне «башлангыч акыл» этәргече дип бәяләргә хаклыбыз. Сәгъдинең булсын, Хафизныкы булсын, аларда да «башлангыч акыл» бирү бар, әмма алар әдәби бәян бирәмлеге белән чикләнмичә, әдәби

[1] *Таминдари А.* История персидской литературы.— СПб.: Петербургское Востоковедение, 2007.— С.32.
[2] *Таминдари А.*Күрсәтелгән хезмәт.— Б.32.

вакыйга бәяненә күчәләр. Хәер, шигърият гомумән дә шул әдәби вакыйга бәяне белән яши. Ул Р.Фәйзуллин иҗатында гына башкача.

Шагыйрьнең «Этюд» шигырен

(Су төбендә көмеш тәңкә
камыш аша якты сузган
ай йөзенә.)

Д.Заһидуллина болай аңлаган: «Бу очракта шагыйрь фәлсәфи нәтиҗәне алга куя: һәр асылның — күләгәсе яки дәвамы белән бәйләнеше тормыш кануны кебек белдерелә. Айның чагылышы (көмеш тәңкә) Айга «кулын сузган» дигән сурәт укучы күңелендә төрле ассоциация уятырга мөмкин: баланың — ата-ана назына, кешенең — милли тамырларга, укучының — остазга мохтаҗлыгы ул, йә булмаса иҗатның чынбарлык белән мөнәсәбәтләреме, боларын һәркайсы үзе уйлап бетерә. Ләкин әлеге бәйләнешләрнең барлыгы шәхси хатирәләрне яңарта, узганны сагыну һәм моңсу хисне кузгата»[1],— дип яза ул.

Әлбәттә шулай. Күренеп, аңлашылып тора: әдәби бәян «башлангыч акыл» функциясен башкарган, кеше аның тәэсирендә акыл табучыга, ягъни хакыйкатьне төшенүчегә «әверелә». Әмма бу төшенү һәркемнең үзенә күрә үзенчәлекле килеп чыга. Фикер яки мәгънә автор тарафыннан укучыга җиткерелми, бәлки укучы үз фикерен яки уйлаган мәгънәне әсәргә (бу әсәр шул турыда дип) йөкли. Д.Заһидуллина сүзләренә килсәк, димәк, асылда ул да шушы фикерләмәләре белән Р.Фәйзуллин шигырьләренең әдәби бәян һәм күзәтү элементларыннан торуын раслый. Тагын да шунысы кызыклы, Р.Фәйзуллин шигъриятендәге әдәби бәяннәр «импрессионистик шигъри сөрем» буларак тудырылганнар

«Этюд» шигыренә кире кайтсак, әсәрдә сүз — Айның судан үзенә кире чагылган шәүләсе хакында бара, дисәк, ә нигә шагыйрь «су төбендә көмеш тәңкә» дип яза? Димәк, су төбеннән Ай нурында көмеш акчаның ялтыравы хакында сүз бара монда. Көмеш тәңкә Ай нурында ялтырый, әлбәттә. Су

[1]*Заһидуллина Д.* «Шаш, рухым, дуласын җан!».— Б.123.

төбендә булса да. Әгәр дә «су өстендә көмеш тәңкә» дип язмаган булса иде, ул вакытта сүз чыннан да Айның үз шәүләсе үзенә ялтыравы хакында барганын уйлар идек. Барыбызга да билгеле, чөнки шәүлә су төбеннән ялтырый алмый, суның төбе түгел, өсте күзгә ролен үти. Бу шигырьдәге «су төбендә көмеш тәңкә» шигъри юлы — күзәтү берәмлеге, «камыш аша якты сузган Ай йөзенә» өлеше — әдәби бәян. Күзәтү берәмлегеннән аермалы буларак, әдәби бәян («импрессионистик шигъри сөрем») үзендә хис тудыручы эчтәлекне туплый, әсәрнең мәгънәсен, шул эчтәлеккә төшенү аша, укучы үзенчә таба. Шушы шигырьнең эчтәлеген якты Ай нурлары астында су төбеннән камышлар аша көмеш акчаның ялтырап күренүе хакында буларак төшенеп, аңардан мәгънә чыгара һәм яктылыктан серләр яшерелми, серләр якты нурга үзләре ачыла, үзләре «кул суза» дигән фикер ясый. Бәлки инде, уйларын тагын да куертып җибәреп, кабат башка нәрсәләрне таба. Шулай итеп, Р.Фәйзуллин шигырьдә фикер түгел, әдәби бәян һәм күзәтү берәмлекләре бирә, ә аларның эчтәлегеннән укучы үзе мәгънә һәм фикер чыгара. Шул сәбәпле аңарда акыл нурланышы уяна.

Мәкаләдә аңлатылганнарга бәйле рәвештә мондый нәтиҗәгә киләбез: Р.Фәйзуллин шигырьләре, күзәтү һәм әдәби бәян берәмлекләреннән торулары белән бергә, укучыны фикерләүгә, мәгънә чыгаруга этәрү көченә ия булулары белән аерылып торалар һәм мондый импрессионистик әдәби алым аны дөньякүләм әдәби мәйданга үзенчәлекле алдынгы (авангард) шагыйрь буларак, үрнәк һәм бөек буларак чыгарырга мөмкинлек бирә. Тагын да шунысы бар, кыска шигырьләре кебек үк, аның күләм ягыннан озын шигырьләре дә шундый төр берәмлекләрдән гыйбарәт, хәтта поэмаларында да ул шулай. Аерма бары тик берәмлекләренең санында, күплегендәазлыгында, ягъни, кабатланып яисә сан ягыннан артып баруларында. Ә аларны фәнни нигездә тикшерү тагын да кызыклы поэтик ачышлар вәгъдә итә.

*Май–сентябрь, 2013.*

# РОБЕРТ МИҢНУЛЛИННЫҢ ЛИРИКАСЫ<br>ҺӘМ АНЫҢ «ЭСТЕТИК ДӨНЬЯ СУРӘТЕ»

«Эстетик дөнья сурәте» төшенчәсендә универсумны күздә тотабыз һәм әдипнең дөньяны әдәби күзаллавын, аның «эстетик модель» тудыру җәһәтендә фикерләмәләрен барлауны максат итеп куябыз. Бу юнәлештә татар әдәбият белеме фәнендә хәзергә кадәр фәнни хезмәтләрнең җитәрлек булмавы кайбер мәсьәләләрне аңлатканда авырлык тудырасын да хәтердә тотарга мәҗбүрбез.

Дөрес, әдәби әсәрләрнең үзкыйммәтен билгеләү, дөньяны танып белүдәге ролен ачыклау аларга эстетик анализ бирүдән башка мөмкин түгел. Әмма нинди дә булса универсаль анализ моделен төзүне максат итеп куймавыбыз сәбәпле кайбер мәсьәләләр мәкаләбездә шулай ук ачык калачак.

Әдәби иҗат эшчәнлеген бәяләүнең һәммәбезне дә тәмам канәгатьләндерерлек формуласы әлегәчә фәнгә мәгълүм түгел, шулай да моңа омтылыш галимнәр арасында үсә бара.

Лирика дигәндә, аны тематик яктан балалар һәм өлкәннәр шигърияте кебек шартлы бүленешкә таркатмыйча, бергә, бөтенлектә карауны да бу мәкаләдә шарт итеп алдык.

## I

Р.Миңнуллин шигърияттә гадилек һәм гадәтилектә матурлык тапкан әдип. Аның иҗатында тормыш вакыйгалары да, табигать күренешләре дә, кешенең эчке халәте дә шушы юнәлештә ачылып бирелә. Шагыйрьнең фикерләре һәм күзәтүләре гадилек-гадәтилек йомгагында үстерелә. Һәр шигыре шул рәвешле оеша. Укучы аның даим сабырлыкта булуына, тормышның гадәти күренешләреннән тасвир тудыра алуына соклана.

Р.Миңнуллин күзәтүчән шагыйрь. Әдәби детальләре тирән фәлсәфә белән өретелеп бирелми. Аның каравы хис берәмлегенең көче аларда шактый нык сиземләнә, күңелләрне кузгата, шушы ягы белән XX йөз башы «рус крестьян

шагыйрьләре» аталган әдипләр төркеме иҗатын хәтерләтә (әлбәттә С.Есенинны).

Ачтым яшел җилкапканы,
Бастым яшел келәмгә,

Аштым яшел сагышларга
Утырдым да үләнгә.

Р.Миңнуллинның Нажар Нәҗмигә багышлап язган «Шагыйрьнең киңлекләре» шигыреннән бу юллар. Шигъри строфалар фикер һәм тасвир җәһәтеннән катлаулы түгел, гади һәм гадәти. Алар укучы күңеленә барып җитәрлек итеп оештырылганнар. Лирик геройның «яшел сагышларга ашуы» хакында искәртүе күңелгә үзенә күрә бер моң, уй башлангычы бирә. Күз алдына яшел җилкапкалы, яшел келәм булып үскән чирәм килә. Үләнгә утырып сагышланып алу гадәти хәл кебек. Әмма шагыйрь «яшел сагышлар» хакында сүз алып бара. Яшел сагыш нинди була — бусы әлегә укучыга билгеле түгел, әмма күңелне кузгатырга шул да җитә кала. Яшел үлән төсе белән сагыш-моң төсе бербөтенлек хасил итеп, күңелдә сорау һәм кызыксыну да уяталар. Х.Туфан иҗатыннан татар укучысына яхшы таныш шушы яшел төс монда да шигыйранә яңгырый. Гади һәм гадәти тоелган шигъри юллар тирәнәеп, мәгънә төсмере белән баетыла. Р.Миңнуллин менә шушы рәвешле хис, аның белән бергә моң тудыра алуга ирешкән чын, затлы шагыйрь буларак укучының күңел түрендә урын ала да инде.

Шагыйрь аунаган чирәмлек,
Шагыйрь үскән үләнлек,
Сабый чакны, яшел чакны
Сагыныплар үләрлек.

Әгәр дә шигъри деталь үстерелми калдырылса, кабатланып, мәгънә төсмерләре белән баетылмаса, ул эчтәлеккә, шагыйрьнең хисләр үстерелешен бирүгә хезмәт итми. Р.Миңнуллин андый түгел, ул, киресенчә, аны, шигъри дета-

лен, фикерләренең һәм хисләренең гадилеге һәм гадәтилеге белән бәйле рәвештә кабатлый. Шушы рәвешле лирик геройның кичерешләре укучы күңеленә тагын да якыная, үз була бара. Бу табигыйлек төсмере уята. Укучыга кайчандыр үзенең дә нәкъ шушындый хисләрне кичергәне исенә төшкәндәй тоела. Моны тудыру өчен шагыйрь «сабый чакны» «яшел чак» буларак сагыну тойгысы һәркемгә таныш булырга тиешлекне генә искәртә, югыйсә. «Шагыйрь аунаган чирәмлек» дигәндә исерек кешенең чирәмдә аунап ятуы кебек ямьсез күренеш күз алдына да килми, чөнки Р.Миңнуллин санап китү юлы белән хисне көчәйтеп кенә калмый, бәлки шигъри күзәтүне шактый конкретлаштыра, чирәмлекне «шагыйрь үскән үләнлек» мәгънәсенә күчерә. Н.Нәҗминең балачакта аунап үскән туган туфрагы хакында сүз барганлыгы тагын да төгәлрәк беленә, хис ителә бара. Р.Миңнуллин тышкы табигый күренешкә сокланудан шунда ук лирик геройның эчке, күңел халәтен бирүгә күчә, сабый чакны сагынудан үләргә дә мөмкинлекне искәртә. Бу шигъри «беркатлылык» гадәти дә артыгы белән гади дә. Әмма аның эстетик функциясе дә бар. Нәкъ менә шушындый лирик күчеш һәм «борылышлар» белән Р.Миңнуллин оста эш итә белә. Алар шигъри экспрессия тудыралар. Шушы ук вакытта, экспрессив сагышны көчәйтеп, Р.Миңнуллин строфалардагы фикерләрне катлауландыру ягына китми, киресенчә, мөмкин кадәр аларны гади һәм гадәти итеп калдыра бара. Бер куплетта гүяки очраклы рәвештә генә телгә алынган кебек тоелган һәм гадилек, гадәтилек төсмере белән бирелгән шигъри детальне алга таба, икенче куплетта яңа мәгънә төсмерләре, фикер берәмлекләре белән тулыландыра, үстерә. Шул рәвешле әсәрдә хис бөтенлеге барлыкка килә бара. Мисалга әле генә телгә алынган куплетны искәртү дә җитә. Анда автор сабый чакны «сагыныплар үләрлек» дип, халык җырларыннан мең ишеткән, шигырьләрдә укыган формада гади һәм гадәти итеп белдереп узган рәвештә, гүяки бернинди яңа фикер һәм хис тудырмагандай бәянләп уза. Әмма алга таба «сагынып үлү» төшенчәсе шактый баетыла һәм тирәнәя. Р.Миңнуллин болай дип белдерә:

Үләрсең дә... баш өстендә
Асыл кошлар тирбәлсә,
Сайраулары күңелләргә
Бер дә тынгы бирмәсә.

Әлбәттә кошлар сайраганга карап кына кеше үлми. Шагыйрь бу җәһәттә «прозаик» фикер йөртмәвен, бәлки моңның күңелгә авыр тәэсирен укучы күңеленә ирешерлек итеп җиткерүен генә сиздерә.

«Шагыйрьнең тын нигезенә сандугач оя корган» дип язуы белән Р.Миңнуллин Н.Нәҗминең рухын Сандугачка, Сандугачны Н.Нәҗминең шагыйрьлегенә тиңли, аларны үзара бәйле, рухи тормыш дәвамчылары буларак тасвирлый. Мондый чагыштыруны шигърияткә мәдхия буларак кабул итми мөмкин түгел. Гадәти һәм гади күренгән шигъри тасвир алымы эчтәлектә тагын да байый, тирәнәя бара. Болар берсе дә шагыйранә фикерләмә өчен ят һәм сәер түгелләр. Янәшәлек һәм шул янәшелектә тасвир барлыкка китерү, бу тасвирны тагын да гадиләштерүгә ирешү белән Р.Миңнуллин хисләр экспрессиясен тудыра. Артык гадиләштерү, әгәр дә шигърилектән мәхрүм ителсә, строфаларны такмакка әверелдерә, билгеле. Мондагы чикне әдипнең сак күңеле тоеп, тотып ала белергә тиеш. Эзлекле рәвештә үстерелеп киленгән, күтәрелә һәм киңәя барган хис фикер тирәнлегенә кучми алмый.

Р.Миңнуллин шигырьләрдә шушы барышны көтелмәгән юнәлешкә «борып», гадәтенә күрә тәмам үзгәртеп кую юлы белән дә эш итә. Мисал буларак алынган әсәрендә дә шушы әдәби күренешкә тап булабыз. Әле генә аяк астында яшел чирәм, баш очында сандугач иде, инде шагыйрь мондый тасвир бирә:

Аяк астында — Агыйдел,
Агыйдел киңлекләре.
Киңлекләрдән дә күренә
Шагыйрьнең кемлекләре.

Сүз Н.Нәҗминең һәм гомумән дә шагыйрьләрнең күңел киңлекләре һәм шул күңел киңлекләренә бәйле кемлекләре ха-

кында бара, әлбәттә. Бу шагыйранә фикер укучыга яхшы аңлашылып тора. Агыйдел буйлары да яхшы ук күзалланган кебек була. Тасвир юк дәрәҗәсендә гади, әмма ул гадәти, шунлыктан данлы елга буе укучы күңелендә ачык күзаллана. Елга тугайларындагы яшел хәтфә үлән дә, тал-тирәкләр һәм алардагы сандугачлар да искә алынмый, югыйсә. Әмма алар шигырьнең беренче кисәге тәэсирендә күтәрелгән хисләр ярдәмендә күз алдына килергә мөмкиннәр.

Р.Миңнуллин шигырьләрендә тематик күчешләр тасвир алышынуы белән тәэмин ителә. Бу аның иҗат манерасыннан килә. Ул аларны тулысынча күңел фәлсәфәсенә алыштырмый, бәлки табигать күренешләре белән тәэсирләнү янәшәлегендә алып бара һәм үстерә. Бу яктан Р.Миңнуллин шигъри алымга хилафлык китерми, «форма үзгәрешләре» тудырмый, шуның аркасында бөтенлек һәм камиллек бозылмау тойгысы кала. Бу әлбәттә кызыклы әдәби күренеш. Р.Миңнуллинга хас үзенчәлек.

Н.Нәҗминең күңел киңлекләре Агыйделдәй булуы укучыда җылы соклану хисләрен уята. Гади генә искәртелгән кебек тоелган шигъри чагыштыру хакыйкатьне тирән итеп ачып бирә. Р.Миңнуллинның «эстетик дөньясының сурәте» хисләрне баетуга гына түгел, шушы рәвешле тормыш чынбарлыгын төшендерүгә дә корылган булу белән әдәби әһәмият ала. Ул Н.Нәҗми хакында уйларга бирелә, санап китү рәвешендә генә булса да «Шагыйрьнең кемлекләре... Җанының хөрлекләре...» формасында төп фикер юнәлешләрен билгеләп куя. Күпнокталар әйтелеп бетелмәгән мәгънәне үзлегеңнән тутыруга этәрәләр. Укучыга алардагы «яшермә фикер» аңлашылып тора, шагыйрьнең туган җире табигате белән күңеленең табигате янәшә куелып тасвирлануы аркасында ул шулай.

Р.Миңнуллин гади һәм гадәти тоелган табигать, әйләнәтирә, тормыш-көнкүреш сурәте детальләре белән рухи дөньяга гына хас тоелган үзенчәлекләрне янәшәлектә искәртү ярдәмендә генә дә күпме тирән хис-кичерешләрне тудыра һәм укучыда уята алу сәләтенә ия булган шагыйрь. Моның өчен ул

катлаулы тасвирлауларга да бирелми, бәлки һәркемгә дә таныш тормыш детальләрен генә искәртеп узгандай яза белә.

Фикер-тасвирда гадилек һәм гадәтилек, укучыга бик та танышлардыр сыман тоелган шигъри строфалар укучы күңелендә шактый көчле хис ташкыны тудыруга сәләтлеләр. Бу күренеш Р.Миңнуллинның әдәби осталыгы хакында сөйләүче төп факторлардан берсе булып тора. Аның тирән фикер фәлсәфәләре кормавы шигъри фикеренең сайлыгы дигән сүз түгел, әлбәттә. Киресенчә, Р.Миңнуллин үз укучыларын тирән хис-кичерешләргә этәрү көченә ия. Ул хис-кичерешләр көчле күңел дулкынлануына күчәләр. Андый вакытта авторның хата фикере дә дөрес буларак кабул ителә.

Сандугачлы, моңлы нигез...
Ул ходайдан бирелә.
Кем дә шагыйрь булыр иде
Туып үссә биредә.

Әлбәттә ул нигездә, Агыйдел буенда бер Н.Нәҗми генә туып үсмәгән. Һәммәсенең дә шагыйрь булуы шарт та түгел. Р.Миңнуллинның шигъри хисне шушылай гади итеп йомгаклап куюы да сәер түгел. Шагыйрьгә мәдхияне туган нигезенә бәйле мактау сүзенә әйләндереп калдыру кебек тоелса да, монда сүз шактый киңрәк мәгънәгә ия булырга тиеш дигән гадәти хис тә уянмыйча калмый. Бу шигъри тәмамлау ысулы белән дә Р.Миңнуллин үзенең «эстетик дөнья сурәте»нә тугыры кала. «Кем дә шагыйрь булыр иде туып үссә биредә» дигәндә халыкның шагыйрьлеге хакында фикер әйтелгән кебек тоела. Шигырьнең эчке, идея агымы тәэсирендә укучыда үсеп килгән хис-тойгылар үзләре үк шушындый фикер нәтиҗәсенә китерәләр. Н.Нәҗминең туган нигезенә лирик герой көнләшеп карый дигән тойгы исә һич кенә дә уяна алмый.

## II

Р.Миңнуллин шигъриятенең «эсстетик дөнья сурәте» һәммә җирдә һәм кешедә камиллекне сурәтли, таный, зурлый белү көченә ия, шушы сыйфатлар белән характерлана. Камиллек ул асылы белән гадилек һәм гадәтилеккә барып тоташа,

билгеле. Катлаулы күренешләр, вакыйгалар, шәхесләр хаос эчендә булалар, шунлыктан аларның эчтәлегенә тулысынча төшенеп бетү дә мөмкин түгел. Фикер катлаулылыгы, шигырьгә килеп кергәндә, шулай ук хис-тойгыларның хаосын тудыруга сәләтле. Шигъри сүздә гади һәм гадәти булудан барлыкка килгән камиллек исә нәтиҗәдә бөтенлеккә ия хис-тойгыларны уята. Алар беркатлылар сыман да тоелалар. Сихри көчкә дә ия булалар. Гадилек һәм камиллек сихерләми калмыйлар, шигырьдә алар хис-тойгыларны аерым кысаларда һәм юнәлештә тоту көчен табалар.

Р.Миңнуллин иҗатын әдәби-эстетик анализ юнәлешендә тикшергәндә, берничә мисал арасыннан «Туфан урамы» шигыренә тукталып киткәндә дә, безнең фикерләмәдә нәрсәләр күздә тотылганны ачыграк аңлатырга мөмкин булыр сыман. Әдәби камиллек дигәндә әлбәттә формаль, рифма-ритм үзенчәлекләре генә исәптә калдырылмый, мәсьәлә әсәрнең эчтәлегенә турыдан-туры бәйләнештә чишелергә тиеш. Шигырьләрнең форма ягыннан төрлесе була ала, аңа карап кына алар әдәби камиллекләрен югалтмыйлар.

«Туфан урамы» шигырендә Р.Миңнуллин, ак каен һәм тимер койма образларын кулланып, Х.Туфанның язмышын, шагыйрь буларак бөеклеген, тәкъдир каршылылыкларын хис-тойгыларга күчерә алган. Бу шигырь эчтәлеге һәм әдәби проблематиканың куелышы белән кызыклы, шигъри камиллеккә омтылыш, әдәбиятта кабатланмаган фикер үрнәге саналырга хаклы.

Туфан урамының бер очында
Ап-ак каен — Туфан диярсең.
Ак күңелле, ап-ак чәчле Туфан...
Аклык күмгән якын-тирәсен.

Каенның яшел булмыйча, ак «чәчле» картинасы укучыны гаҗәпләндерә, билгеле. Бу күренеш гадәтилеккә хилаф. Әмма каенның ак кәүсәле булуы шартлы сурәтне кабул итәргә мөмкинлек ача. Сурәтләрнең җитәрлек дәрәҗәдә камиллеген таләп итмәгәндә, телдә ак каен гыйбәрәсенең шактый тотрык-

лы саклануын искәпкә алганда, шигъри сүз белән укучы күңеле килешми калмый.

Хәер, хикмәт анда гына да түгел, бәлки Туфан күңеленең ак булуында, сафлыгында. Әгәр дә Р.Миңнуллин шигырьдә яшел күлмәкле Туфан турында сүз алып барган булса, даһиның күңел аклыгы да, башкасы да шигъри сурәт камиллегендә акланыр иде сыман.

Каен төсле Туфан шигърияте:
Якты хисле, якты фикерле.
Урам башындагы якты каен
Чал Туфанга һәйкәл шикелле.

Шигырьдә Х.Туфанның кемлеге һәм ниндилеге төгәл ачылып бирелгән. Аның хакында Р.Миңнуллинның шушы шигъри юлларыннан төгәлрәк һәм камилрәк фикер әйтеп булмас шикелле. Гади, гадәти һәм камил. Р.Миңнуллин шигъриятенең төп үзенчәлеге, аның «эстетик дөньясының сурәте» менә шушы сыйфатлардан гыйбарәт. Ул укучының күңеленә шулар белән үтеп керә, анда якты хисләр, якты фикерләр уята.

Бу шигырьдә Туфан урамының икенче очында тимер койма булу факты шулай ук символик мәгънә белән искәртелә. Монда төрмә рәшәткәсеннән, тимер богаудан шушы рәшәткәнең коелган булу мөмкинлеге дә белдерелеп, хис-кичерешләргә драматик төсмерләр өстәлә. Р.Миңнуллин фикерләрне һәм тойгыларны шигырьдә үсештә, үзгәрештә бирә, дидек. Димәк, динамик үсештә бирә. Бу шигъри динамизм ашкын хисле, каршылыкларны җимерә баручы көчкә ия түгел. Ул тәртип һәм сабырлык кысаларындагы кичерешләрнең хәрәкәтеннән гыйбарәт. Җәмгыятебездә «торгынлык чоры» дип аталган Л.И.Брежнев дәверендә татар шигъриятендә менә шушындый динамик күренеш пәйда булды һәм чәчәк атты. Р.Миңнуллин шул чорда халыкка хас, аның кемлеген һәм ниндилеген таныткан иң күркәм сыйфатларыннан саналган сабырлыгын шигърияттә саклап калган әдип буларак күзаллана. Һәр әдипнең иҗатта үз формалашу һәм үсеш алу дәвере бар. Шул чорыннан мәдәниятебезгә уңай сыйфатларны алып килә алган икән, бу инде талантның көче хакында да сөйли торган факт.

Р.Миңнуллинның шигырьләренә хас «сабырлык» динамизмы хисләрнең хаотик үзгәрешен инкарь итә. Шушы сәбәпле хисләр, уй-фикер агышы тулы гармония тудыра. Шагыйрь аны шигъри формаларда да оста файдалана, тасвирда да куллана.

Бер каенга багам, бер коймага.
Басып торам ике арада.
Ак каенга карыйм — җан яктыра,
Рәшәткәгә карыйм — карала.

Бу шигъри юллар Р.Миңнуллин шигъриятенә хас «сабырлык» динамизмын тулысынча күзалларга ярдәм итәләр.

Болар чыгып, Р.Миңнуллиның шигъриятенә асылда гадилек һәм гадәтилек, камиллек белән бәйле «сабырлык динамикасы» хас дигән нәтиҗәгә киләбез. Әлбәттә бу бәяләмә шагыйрьнең бары тик «эстетик дөньясы сурәте»нең төп үзенчәлекләрен генә, нигезен генә ачык таныргa ярдәм итә, олы шигъриятнең һәммә үзенчәлекле якларын да колачлап бетерә алмый. Шуңа күрә, фикерләмәләребез объектив булсын дисәк, мәсьәләгә башка яктан да якын килеп карыйк.

III

Һич тә сер түгел, Р.Миңнуллин иҗаты татар укучысы өчен якты хисләр, мәгънәле уйлар һәм итагатьлелек тойгыларын уятуы белән дә аеруча кадерле. Аның шигырьләре кече яшьтән үк зиһенебезне бизәп, акылыбызны сөендереп, күңелебезне биләп, хәтер киңлекләрендә яши башлый. Бу яктан ул Кол Гали, Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Х.Туфан кебек бөекләребез белән янәшәдә әдәби-мәдәни тормыш күгебезне яктыртучы йолдызларыбыздан берсе сыйфатында мөкатдәс һәм мең кат мөкатдәстер. Аның шигырьләренә язылган җырлар халык эчендә тиз таралып өлгерә, балаларга атап иҗат ителгән шигырьләре үзләренең самими һәм беркатлы булулары, шулар белән бергә зирәк тә, бераз гына хәйләле дә (ягъни, төшеп калганнардан түгел инде алар) лирик геройлары балачак хатирәләребезнең онытылмас мизгелләреннән шигъри юлларга сәяхәт иткәннәрдер кебек тойгылар уяталар. Бу ничек һәм ни өчен шулай? Сәбәпләрен, асылын төшенү мөмкинме? Әллә

бу мәсьәләләр фән тарафыннан чишелмичә, ачыла алмыйча, сер булып калырлармы?

Үзенең ярты гасырдан артыкка сузылган иҗат дәверендә Р.Миңнуллинның татар шигъриятендә аерым бер шигъри галәм, шигъри дөнья, шигърият җиһаны тудыра, үстерә һәм ашы яшәтә алуының сәбәпләре ил һәм халык алдында хөрмәтле булуына гына бәйле идеме икән? Берәүләр аның әдәбияттагы бәхетен депутатлык мәшәкатьләреннән калган өлеш кебек аңлатсалар, икенчеләр хикмәтне шагыйрь булып тууында күрделәр. Без өчен ул — шагыйрь, шул ягы белән бөек тә. Шунысын да искәртергә кирәктер, үз күңелебезгә килгәндә, шагыйрьләрнең күктәге йолдызлар кебек бер үк төсле, бары тик эрелектә һәм ваклыкта гына бер-берсеннән аерылып торуларын түгел, бәлки җәй башында болындагы чәчәкләр кебек төрледән-төрле булуыларын сөя, аларның шулай балкуларын тели. Әмма шагыйрьләр үзләрен йолдыз итеп, бары тик йолдыз сыйфатында гына беләләр...

Йолдызларга карап торган кеше нәрсә уйлый? Мин аларда җан бардыр дип тоям, мине күреп, аңлап торалар, мин аларны тоям, күрәм һәм аңлыйм. Йолдызлар белән кешеләр нindидер серле, зиһен аңламаган, әмма күңел тоя алган «телдә» сөйләшәләрдер сыман миңа. Әгәр дә Р.Миңнуллин шигъриятен йолдызлары белән балкыган чиксез галәм, күк йөзе дип белсәк, әсәрләре шул биниһая күкнең якын һәм ерак, күренеп һәм күренеп бетмәгән, ачылган һәм ачылмаган, исемле һәм исемсез йолдызлары икән, укучы күңеле шул йолдызлар белән сөйләшүче, серләрен ачып та ачыклап бетерә алмауда бәхет табучы бәрәкәт иясе түгелме?

## IV

Р.Миңнуллин, иҗат иткәндә, шигырьләрен камил детальләр белән бизәп, сурәтле итеп яза, дидек. Бу аның лирик әсәрләренә дә, балалар өчен язылган шигырьләренә дә бердәй хас. Аларның тәүге юлларыннан ук күңелгә күренешләр ачык һәм камил дәрәҗәдә эчке бер ләззәтле һәм мәгънәле хис белән бергә килеп, сагышлары, шатлыклары бөтереп алалар да, каршылыксыз кабул ителәләр. Формаль мантыйк таләпләре һәм

тормыш асыллары белән ярәшеп бетмәүләрен укучы төшенми, уйламый, хәсрәт итми, чын шигърияттнең дәртле хис агымнарына чума. Сагышы белән сагышландыра, шатлыклары белән сөендерә укучыны бу шигърият.

Һәр бөек шагыйрьнең бөеклеген хәтерләрдә даими дәлилләп торучы, исеме телгә алынуга җиңел генә искә төшүче күңелгә якын әсәрләре була. Г.Тукайны «Туган тел»еннән, «Китмибез»еннән, «Шүрәле»сеннән, «Су анасы»ннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Без хәтта шүрәле сынын күрсәк тә Г.Тукайны искә төшерәбез. Хәтер бакчасында Һ.Такташ үзенең «Алсу»ы, «Нәни разбойниг»ы, «Мокамай»ы белән «җитәкләшеп» йөри. М.Җәлилнең исемен әйтүләренә «Кызыл ромашка»сы, «Җырларым», «Вәхшәт» әсәрләре искә килә. Һәр әдипкә бәйле шулай. Әсәре авторының исеме белән бергә истә кала икән, бу исә язучының халыкта кадерле булуы, танылуы хакында сөйли торган факт. Европада киң таралыш алган «әдипләрнең үлеме» теориясе, димәк, нигезле түгел.

Р.Миңнуллин исеме миңа, мәсәлән, «Килен төшкәндә» җыры белән бергә ишетелә. Көе — бер хәл, аның сүзләрендә бөтен хикмәт. Алар татар укучысына шагыйребезнең шигъриятен кабул итәргә, аңларга һәм күңеленә алыр өчен «капкаларны киң ачарга» сәбәпче булдылар. Моңарчы да танылган, укылган, сөендерергә өлгергән шигъриятнең инде чын асыл төсе белән кабул ителә башлануын шул әсәргә бәйләвебездә әһәмиятле ачыш бар. Р.Миңнуллинның ачык һәм төгәл детальле, гүзәл сурәтле шигъриятенең бинасы нәрсәгә һәм нәрсәләргә корылганлыгын, нигезен ни тәшкил иткәнлеген ул һәм аннан алынган мисаллар төгәл билгеләргә мөмкинлек бирә. Хәер, «Килен төшкәндә» шигыре урынына шагыйрь иҗатыннан башка һәртөрле әсәрен сайланып тормыйча алырга була, аңа карап, кайбер нюансларны исәпкә алмаганда, башкачалык белән очрашмабыз. Р.Миңнуллинның хәтта балалар өчен язылган шигырьләре дә шул ук «калыпта» барлыкка китерелгән, тудырылганнар. Шуның өчен дә бу әсәрен (аннары ул киң катлам укучыларга, халыкка бик тә яхшы билгеле һәм шуның сәбәбендә укучыга, мәкаләбез белән танышырга

туры килсә, безнең белән килешергә яки бәхәс итәргә мөмкинлек тә бирә) шагыйрьнең иҗат манерасын, әдәби слубын, төп үзенчәлекләрен ачыклауда һәм аңлатуыбызда бу юлы үзәккә алдык.

Р.Миңнуллинның ул әсәре неоромантизм агымы биргән иң якты әдәби кыйммәтләрнең берсе! Анда сурәтләнелгән һәр деталь, һәр күренеш, хәтта, әйтергә кирәк, вакыйга — татар кешесенә яхшы таныш. Моның сәбәбе җыр булып китүеннән дә килә, билгеле (композиторы — Рөстәм Яхин)[1].

Ак күбеккә баткан юргалар
Кышкы юлдан ярсып чабалар,
Чак-чак кына аумый калалар
Салулаган чакта чаналар,
Арттан чаба бала-чагалар.

Игътибар итик: текстта искә алынган күренеш-вакыйгаларның һәр детале конкретлык, төгәллек белән бирелгән һәм мәйданга камил шигъри сурәт чыгарылган. Ул шунда ук күз алдына килеп баса. Камиллек, әлбәттә, әдипнең рухының көченә, якты акыллы булуына бәйле. Юргаларның кышкы юлдан чабуы да, чаналарның чак-чак аумый калулары да — бик гүзәл манзаралардан. Чаналар артыннан бала-чагалар да чабалар — бусы инде күпкә арттырылган, билгеле. Балалар туй артыннан бераз кушылып-ияреп-йөгереп алырга мөмкиннәр, әмма кышкы юлдан ярсып чапкан юргалар артыннан чабулары — белмим, ерак бара алмаслар, мөмкин хәл түгел, хәтта марафончылар да моны булдырмаслар.

Татар укучысы аңлый, белә: йола-гадәт шундый — узып баручы туй урамдагы балаларга тәм-том сибеп калдыручан, шуларны җыялар алар. Тик тагын да болары бар: кышкы юлдан юрганы ак күбеккә батырып чаптыру — аны яндырып үтерү дигән сүз. Моны ат җиккән һәркем белә. Әмма мәсьәләнең ул яклары шагыйрь тарафыннан искә алынмыйлар. Моның кирәге дә юк. Андый тормыш факты шигърилекне

---

[1]Җырлыйк әле / Төзүчесе — *Надиров И.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.— Б.250.

харап итәчәк. Шигъри дәрткә, шигырь куәтенең тәэсиренә чумган укучы да ул исәпкә алынмаган якларны күрми, сизми, тоймый. Аңа, киресенчә, юргаларның ак күбеккә батып чабулары, балаларның туй атлары артыннан чәрелдәшеп-шаулашып йөгерүләре (игътибар итик: укучы үз фантазиясе белән яңа детальләр өсти, шигырь тәэсирендә күзаллауга җиңел бирелә), чаналарның салулаганда авып киткәндәй булулары кыйммәтрәк. Хыял офыклары киңәеп китү белән бергә тормыш хакыйкатьләре дә шул шигъри сурәт тәкъдим иткән рәвештә күз алдына килә башлый. Р.Миңнуллинның төгәл һәм сурәтле күренеш-детальләрне әдәби ямьдә бирә белү осталыгы укучының күңелендә хис-тойгыларны тирәнәйтә һәм камилләштерә. Бу исә рух тантанасына китерми калмый. Тормышта-чынбарлыкта килен шушылай төшә, татарда менә шулай яшиләр, туй итәләр икән дигән гомуми бер күзаллау да туып өлгерә һәм хәтердә яши башлый. Яшәешнең барышы, көнкүреш мантыйгы, аның детальләре истән чыгарыла, онытыла, аларның урынын әдәби сурәт, әдәби детальләр, шигъриятнең үзе җанны биләп ала.

Галим-голамә, тәнкыйтьчеләр арасында шундый сүзләр йөрүчән: шигырьнең, асылда, башы һәм ахыры матур эшләнгән була, ә уртасына «чүп» тутырыла, диләр. Мондый карашның тууына төп сәбәп — әсәрләрендә шагыйрьләрнең әүвәле бер-бер фикри хакыйкатьне искәртеп, аннары аны сөйләп биреп, аңлатып, яисә бәяләп алуларына бәйле фикер «үстерүләре», аннары яңадан нәтиҗәле (яки алда, шигырь башламында әйтелгәнне кабатлау юлы белән) фикер йомгагын белдереп шигъри «фокус» төзүләренә корылган формаларга өстенлек бирүләрендә, әлбәттә. Р.Миңнуллин шигърияте дә мондый корылмалардан мәхрүм калмаска тиеш кебек. Әмма детальле, төгәллек белән бирелгән камил шигъри сурәт моңа мөмкинлек калдырамы? Вакыйга-күренешләр киңәйтелергә, үстерелергә, эчке, рухи халәт тасвирына әверелә барырга мәҗбүр аның әсәрләрендә.

Мамык мендәрләргә төренеп
Килен төшә бүген авылга.
Борынгыдан калган гадәт ул —

Халык чыга каршы алырга,
Яшь кәләшне күреп калырга.

Безнең татарда Р.Миңнуллин кебек ипле язган башка бер шагыйрь бармы икән? Юк та, ахрысы. Тавыш-гаугасыз, тыныч холкы аның иҗат манерасында да чагылмый калмаган. Шигырьләрен күркәм, тәүфыйклы итеп китереп чыгарулары шагыйрьнең үз табигатеннән килә торган сыйфат. Ул шигырьдә катлаулы символларга корылган мәгънәләр бирү юлында түгел. Эпитетлар белән тасвир-сурәтләр тудырып, Р.Миңнуллин шигырьдә эпик стильгә өстенлек куя. Аның иҗаты чагыштыруларга бай, анда аллегорик күзаллаулар еш очрый. Әмма образлы-символик мәгънәләр бирү ягыннан карaганда, әгәр дә очраклы рәвештә генә алар аның каләм очына килеп кермәсәләр, бөтенләй диярлек юклар.

Эпик стильдә сурәтләнгән вакыйга-күренешләрне бирүдә мәгънәле күзаллау тудыра алу ягыннан Р.Миңнуллин һәммә татар шагыйрьләре арасында изге тойгылар белән күңелләрне баета алу көченә ия булуда аерылып торды. Аның язганнары тирән дулкынландыра. Мәгънәле күзаллау тормышны яктылык һәм бәхет тою хисләре эчендә күрүгә һәм аңлауга, бәяләүгә этәрә. Р.Миңнуллинның шигырьләрен укыган кешедә (лирикасын булсын, балалар өчен язылган әсәрләрен булсын) тупаслык, усаллык, кирелек һәм ямьсезлек туа алмый. Үзеңне дөньяның матур бакчасында йөргән, хозурына сокланган күбәләк сыман тоясың. Бу халәт күңелең киңлекләрендә нурлы балкыш булып сүнми озак саклана. Моны, бер яклап, шагыйрьнең эпик киңлекләрне шигъри төзек кысаларга кертә белү осталыгы, икенче яктан, мәгънәле неоромантик күзаллау тудыра белүе, өченчедән, шуларны тәэмин итүче сурәтле детальләштерү алымнарын оста файдалануы белән генә аңлатып була.

«Килен төшкәндә» шигыре белән аның җырга салынган вариaнты арасында берникадәр аермалар да бар. Менә шушы,

әле мисалга китерелгән икенче куплеты шигъри басмаларында болай яңгырый[1]:

Мамык юрганнарга төренеп
Төшә икән килен авылга.
Борынгыдан калган гадәттер —
Авыл чыккан каршы алырга,
Яшь кәләшне күреп калырга.

Күренеп тора, шигырь вариантында эпик киңлек бераз тарайтылган, детальле раслау тоны да түбәнәйтелгән. Бу исә «Килен төшкәндә» әсәренең шигырь варианты романтик хисне калку итеп ясап өлгертеп бетермәве хакында сөйли. Җыры тексты — очына, дәрт бирә. Шигырь тексты рационалистик күзаллау ягына тарта, җырда «мамык мендәрләргә төренеп», ә шигырьдә «мамык юрганнарга төренеп» килен төшә, шигырендә шагыйрь киленне каршы алырга авылның чыгуын «борынгыдан калган гадәттер», ди, җыр текстында «гадәт ул» дип, раслау тоны белән белдереп, бу йолага соклану хисен алга чыгара. Җыр тексты шуның кебек кечкенә, әмма мөһим аермалары белән тагын да камилләшеп китә. Алга таба да мондый аермалыклар күзәтелә һәм алар җырга ямь, пластика өстиләр, туй манзаралары белән бергә килеп туган хисләр кебек тоелалар.

| ***Шигырь текстында:*** | ***Җыр текстында:*** |
|---|---|
| Җилкендереп япь-яшь кызларны, | Җилкендереп япь-яшь кызларны, |
| Хәтерләтеп яшьлек узганны, | Килен төшә бүген бер өйгә |
| Килен төшә бүген бер өйгә, | Кайда калды шундый чагым дип, |
| Эһ, кайтмас шул инде тагын дип, | Авыр сулап куя әниләр, |
| Авыр сулап куя әбиләр. | Авыр сулап куя әбиләр. |
| | |
| Күптән инде ачып куйганнар | Күптән инде ачып куйганнар |
| Килен төшкән өйнең капкасын, | Килен төшкән өйнең капкасын, |
| Төшкән килен | Килен төшкән өйнең капкасын |

[1] Татар поэзиясе антологиясе.— II китап.— / Төзүчесе — *Гәрәй Рәхим*.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— Б.325.

Өйнең капкасын
Китәргә дип кире япмасын,
Кайгы җиле килеп какмасын.

Китәргә дип кире япмасын,
Кайгы җиле килеп какмасын.

Татарда килен авылларга мамык юрганнарга, яисә мамык мендәрләргә төренеп төшә икәнлеген халкыбыз үзе дә Р.Миңнуллинны укып, җырын ишетеп, аңа кушылып җырлап, шушындый күркәм йолаларыбыз булганда яхшы икән дип белә башлады. Моны без, әдәбият тормышны камилләтерде, дибез.

Р.Миңнуллин эпик формаларда шигъри күренеш, тасвир бирү остасы. Ул менә шушы җыры-шигырендә генә дә туй көнендә авыл халкының төрле төркемнәре-катламнарының нинәрсәләр хис итүләрен детальле сурәтли, нечкә итеп бәян итә. Шушындый әдәбиләштерү юлы, тормыштан көтелгән вакыйгаларны күңел сурәтендә чынбарлык итеп бирә белү осталыгы белән ул шагыйранә кабатланмас дөнья барлыкка китерә. Аның эпик планда төзелүе эчтәлеккә киңлек бирә. Укучы анда үзен рәхәт, күңелле һәм бәхетле хис итә.

Р.Миңнуллин — эпик формалар белән шигъри сурәтне детальләрдә оста рәвештә әдәби гомумиләштерүләр белән иҗат итү остасы буларак милли шигъриятебезнең үзенчәлекле шагыйре, халкыбызның рухи сафлыгын, гореф-гадәттә тәүфыйк, итагать билгеләрен тәрбияви үстерүче неоромантик рухлы әдипләребезнең яңа заман чоры даһиларыннан, әлбәттә.

Шунысы тагын да кызыклы, аның иҗатын ничек кенә, кайсы юл белән генә тикшермик һәм анализлап бәяләмик, һаман да шул бер үк төрле нәтиҗәләргә килергә мәҗбүрбез. Бу исә хакыйкатьнең тугыры ачыклануы дигән сүз дә. Фәннилек башкача була алмый.

*2008–2013.*

# ДӘРЬЯ ДӘРТЕ

*(Рөстәм Мингалим иҗаты хакында)*

Рөстәм Мингалимнең шигърияте ургып алып китә торган дәрьяны хәтерләтә. Әмма ул болганчык сулы, авыр холыклы караңгы диңгез түгел. Саф, чиста. Һәр шигыре диярлек рухны сафландыру көченә ия.

Аның 2003 нче елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Дәрт чишмәсе: Шигырьләр, поэмалар (Мөхәррире — Р.Х.Корбанов, рәссамы — Ф.З.Зөлкарнәева)» тупланмасы шагыйрьнең күңел тантанасы гына түгел, татар әдәбиятының сөенече дә булган иде.

Тик, укучым, сез Р.Мингалим шигъриятеннән «ә»гә «җә» рифмаларын, «сандык-тартмачык» калыпларын, «шаккаттыризм» шәрәлекләрен эзләмәгез. Инде татар шигъриятендә реализм үлде, хакыйкатькә җеназа укылды, сафсата аламасы милли әдәби байрак итеп күтәрелде дигән заманда ул әле һаман, ничә еллар буена дәрья булып шаулый. Р.Мингалимнең дә шигърияте, хәтта «Юл өстендә тургае» да (1978 нче елда басылып чыккан шигырьләр һәм поэма китабы хакында сүз бара), бүген дә сайрый. Башкача була да алмый, булырга да тиеш түгел.

## I

Белмим, ни өчен Р.Мингалим җыентыгына «Дәрт чүлмәге» дигән исем бирергә уйлагандыр (бәлки заманага ияреергә мәҗбүр иткәннәрдер), әмма ул дә ташып чыккан. Күңел кайнарлыгы шигырь дәрьясына әверелгән. 1972 нче елда ук язылган «Нәкъ унбиш ел үткәч...» дигән шигырен укып, һушсыз калгандай булдым: никадәр тормышны аңлау һәм тою, никадәр шигърият һәм яшәеш мәртәбәсе, ул фикер тыгызлыгы һәм җиңеллеге... Әгәр бүгенге көн татар шигърияте хакында сүз алып барабыз икән, һичшиксез сүз Р.Мингалимнән башланып китәргә тиеш кебек тә хис кала.

Көзге төнгә йөзен куйган иде
Күкчәтауның иркен даласы,—

ди шагыйрь, дала стихиясен күңелләр түрендә җәелдереп.

Шигыренең башындагы шушы шигъри юлларда ук кузгатылган хис-тойгылар алга таба күңел дәрте булып әверелә. Шагыйрь моңсулык агышына күңел кайнарлыгын ияртеп кенә, гадәти тормыш вакыйгаларын, гүяки чәчеп-чәчеп җибәргәндәй итә дә, җиңел адымлы тезмәдә сөйләп бара. Тракторларның кырда утларын уйнатып эшләве дә, лирик геройның «тирлитирли чылбыр ялгавы» да, хаталандырган чибәркәйнең, калдырып, үз якташына иргә чыгуы да, «ятимнәрне җыйган ана кебек» булган даладан китәргә мәҗбүр егетнең уйлары да — һәммәсе-һәммәсе, шигъри мизгелләрдә искәртелеп, инде ничәмә еллар сугарыр яңгырны күрми ката барган яргаулы җаннарыбызны гайрәтле үткер сабан төрәне кебек каезлап һәм әйләндереп ташлыйлар...

Авырлыктан качты бу егет, дип
Әйтүче дә бардыр ул барын...

Бардыр, дөнья шул ул, андыйлары гына табылыр! Әмма киткән кешене дә юлның уңае гына көтми, калган кешеләрнең дә эше җиңел генә булмаячак. Әйе, хикмәт китүдә яки калуда түгел, башкада! Шагыйрь моны сиздереп кенә куя. Ул һаман да шул ук тезмә кысасыннан чыкмый сөйли, әмма сүз агышының яссылыгы инде башка. Бу — Р.Мингалимнең шигъри алымы: ул бер фикер һәм хис катламыннан икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә күчә-күченә һәм кире кайта-кайта, шул рәвешле сулышны, уйны, тоемны һәм аңны алыштыра-алыштыра бара. Әдәбиятның көче дә шунда: син инде чын әсәрне бер укысаң, кабат элекке хәлеңә кайта алмыйсың һәм кайтырга да теләмисең. Син инде башка, бүтән яссылыкта, әүвәлге халәттән еракта.

Ә Р.Мингалим моны бик җиңел тойдыра, бу аның шигъри сүз мәртәбәсенә бәйле. Укып кына карагыз, үзегез дә төшенерсез. Менә ул, шушы ук шигыренең ахырында:

Нәкъ унбиш ел үтте,
Бер уйласам,
Эшлим кебек эшем җимереп.

Бер уйласам, көзгә йөзен куйган
Күкчәтауның төнге даласы... —

дип, бүселергә әзер дәрт диңгезенең дулкыннарын тынычландыргандай итә.

Әйе, игътибар бирми мөмкин түгел: никадәр сыгылмалык, нинди аһәң-яңгыраш, моң! Гади, гадәти! Һәр буявы-төсе урынында, ягымлы һәм ятыш!

Һәм кайчаннан бирле тракторым
Кабыза алмый йөдим, ләбаса.
Дуслар сөрә әнә,
Төн — караңгы,
Шырпы сызып карыйм моторга.
Ни булды соң әле?
Мотор — салкын...
Тәмәкем дә беткән тартырга.

Бу — Рөстәм Мингалим каләме, башка бер генә шагыйрьдә һәм шигырьдә булмаган, яралы һәм сәламәт, тынгысыз һәм сабыр, сагышлы һәм кояшлы язу карасы салынган дәрт чүлмәгеннән буялып чыгучы каләм. Әйе-әйе, дәрт чүлмәге түгел, сагыш һәм кояш чүлмәге дә әле ул! Мең мәртәбә аңлаешлы һәм фикер күзеннән ерак Мингалим. Мондый шагыйрьнең татарда булганы бар идеме?

II

Шигырь хистән-тойгыдан, дәрттән, акылдан буш булмый, юкса ул үлә. Белеп торыгыз, тәнкыйтьче, мәкер айгырына атланып, харабат кылычын пәһлевандай айкаган һәм гыйлем-хакыйкать байрагы тантанасы өчен баһадирларча җан аткан каһарманга тиң ул. Без дә, бу эшкә алынганбыз икән, үзебезне нәкъ шулай тотарга тиешбез. Дөресрәге, Мингалим шигърияттен иңгә-буйга йөреп, аннан бушбугазлык эзләмәкчебез. Әмма, егет, кылычыгыз тиз сынар, дип лаф ормагыз, максат ул Мәскәүне дә алдырган, Парижны да тезләндергән!

Менә ул, менә «Зәңгәр ишек» шигыре. Автор аны «Балачак дусларыма» дип багышлаган. 1973 нче елда ук язылган булса да, ни тәнкыйтьнең, ни адәмнең күзе төшми калган шигырь. Моннан әдәбият фәнендәге һәртөрле «изм»нарның исе аңкып тора. Мода әдәп һәм әдәпсезлек, монда үҗәтлек һәм битарафлык... Бер сүз белән әйткәндә: шәп бит ә?!.

Бер-беренә охшаш чуерташлар сыман —
Уйга килә — ярда безнең шәрә яткан...

Яр буенда яткан «балачак дуслары» — чуерташлар! Шунда ук мәңге сөйләшеп туймый торган, бер-берсенә гүяки төскәбиткә дә охшаш иптәш малайлар хәтердә яңара. Шагыйрь хәтта кояш барлыгын, күкнең аязлыгын да теленә алмый. Ә шигырьдә никадәр нур, җылылык!

Беренче тапкыр бу шигъри юлларны укыганда без, учларыбызга егылып төшкән йөрәгебезне тотып, бүлмәбезне аркылыга-буйга йөреп таптап бетердек. Салкын тиеп авырган чагыбыз иде. Тәмам хәлсезләнгәч кенә акылыбызга киленде, урыныбызга яттык. Мингалимне ачуландык: никадәр мең тапкырлар кабатланган, фикерсез һәм кызыл байраклы шигырь, дидек. Зәңгәр ишек, имеш, максат ишеге! Аңа якынаясың, ул арткарак оча, сакчысы бар, калын, бикле... Ә аңа ирешәсе, аны бәреп ачасы бар!

Һәм Мингалим барыбер үзенекен итә, шулкадәр сүзне әйләндереп куя, узылган һәм киләчәк язмышың бар тулылыгы белән көмеш тәңкәле ак чабак кебек ялтырап күз алдында күренеп ала...

Үзен зәңгәр ишек итсә серле максат,
Дөнья безне кеше иткән, куәт биргән.

Чыннан да шулай түгелме? Бу әсәр нык үскән куәтле һәм бәхетле социализм дәверендә язылган, җиде елдан илдә коммунизм тантана итәчәк дигән елларда!.. Әйе, заманасыннан чыгып бәя бирсәк, бу — фикерсез шигырь, идеалларны юкка чыгаручы сафсата. Әмма бүгенге көннең ничек итеп киләсен ул вакытта кемнәр белгән дә, кемнәр аңлаган?

Р.Миңгалимнең шагыйрь буларак көче-куәте хакыйкать икән шул, сүз уены, хисләр аймагы гына түгел.

Гафу, шагыйрь әфәндем, мең гафу, сезнең шигыregeзне фикерсез дип атарга җөрьәт иткәнем өчен, чөнки тәнкыйть азмы шулай ялгышты һәм ул безнең каләмне дә хаталандырырга җыена. Нишлисең соң, тәнкыйтьнең мәкер алашасы йөгән чәйнәргә, тешләшергә маташа.

Максатына тими узган ташлар кебек
Соңгы көндә егылмасак иде Җиргә.

Гади һәм гадәти сүзләр кебек!

Шигырьнең җененә игътибар итик: ярда яткан чуерташлар сыман малайлар һәм максатына тими узган ташлар! Йомарлам кебек бөтен, мәгънәле фикерне үзенә сыйдырган тулы канлы, тәмамланган картина булып тормыш хакыйкате күз алдына килеп баса. Догасы да драмасы да бар!

III

Р.Мингалимнең бу җыентыгының бөтен хатасы — ялагайлана белмәүдә. Әллә кайчан әллә кемнәр булып бетәр иде дә, ул орденнар, ул премияләр, ул катлы-катлы йорт-фатирлар, машиналар, алтыннар, хатын-кыз гыйшкы, мунчасы һәм пәрәмәчләре белән күмелер иде. Юк шул, Мингалимгә боларны Ходай тәгалә моңа кадәр күпсенгән, аңа туры һәм тугыры тел, иман биргән. Ә югыйсә шигърияте ндә кемлекләрен язып биргән шул ук депутатлар, чиновниклар, «койрыклар», «койрык арты койрыклар» аның үз танышлары, якын белгән кешеләре, хәтта дуслары да түгелме? Алармы Мингалимне укымыйлар, алармы үзләрен танымыйлар? И шагыйрь, нигә шушы кадәр хакыйкать ялчысы булып туарга кирәк булды икән сезгә? Тарихлар шаһит түгелме, шул дөреслекне сөйләгән шагыйрьләрнең язмышлары нәрсә белән беткән? Хәтта үзләрен, мөслиммен, дип, хакыйкатькә тугрылык саклаучыларбыз, дип йөргән мөселманнармы Хакка, Хаклыкка, Хакыйкатькә хезмәт иткән шагыйрьләрне дар агачларына асып үтермәгәннәр? Әллә данлы авропалылармы, кул бармакларыбыз арасыннан каннар

агып тормый дип мактана ала? Кичәге тәртипләр бүгенме үзгәрделәр?..

Үзгәрә, дип күз яздылар,
Үзгәрәдер — чындыр ул...

Шушылай тыныч кына башлап китә Мингалим «Идарә чылбыры» (1989) шигырен һәм мыскыллап әйтеп тә куя: «вәйт озын да чылбыр ул!»

Ә бу чылбыр өскә, башәйләнгеч югарыга таба китә.

Иң түбәннән өскә хәтле —
Арт ялауга корылган...

Аны, алай түгел, дип әйтеп карагыз!

Ярар, идарә чылбыры шундый булсын да, ди, ә безгә, «түбәннәргә ничек түзеп торырга?!.» Укучысы алдына шагыйрь сорауны бар тулылыгы белән, яшермичә китереп куя белә. Йа Ходa, дисең, ярый әле түрәләр шигырь укымыйлар һәм аңламыйлар, юкса татарны бөек бер шагыйрьдән мәхрүм калдырырлар иде дә, хакыйкать урынына ялагай эт кебек шыңшучы куштан читек-кәвеш шигырьләр генә дөньяда калыр, милләтнең хәле харап, эше харап, йөзе харап булыр иде. Шушы кадәр кирәкме инде?

Ничә күрәм күтәрелеп:
ялау да ялау һаман,
җитмәсә —
әле ыштансыз
һәм
Тәһарәтсез
заман?!

Хакыйкатьнең татар шигъриятендә бу рәвешле артын ялтыратып мәйданга йөгереп чыкканы юк иде әлегә. Көлке дә, моңсу да. Һәм шагыйрь менторлыкка бирелергә мәҗбүр. Кая барсын? Бәлки башка берәүнең шигырендә үгет-нәсыйхәтчелек калдыклары сиземләнсә, сару кайнаткыч тойгылар уятыр иде. Әмма Р.Мингалим — кулына сыек чыбыркы тоткан Ментор,

ул шушы исемдәге бөек Одиссейның улы Телемахка акыл сабагын бирәчәк мөгаллим генә түгел, үткен каләмле урыс мөхәррире Н.В.Гогольгә кадәр һәм аннан соң да көленгән, каһәрләнгән, мыскылланган, алай да дәваланусыз калган һәм гарипләгән яшерүче, бөтен Рәсәй эчен беренче яратылыш көненнән үк исләндергән түрә-түрәчекләр белән эш итүче бүгенге көннең Каюм агасы.

Товарищлар!
Бу ни гадәт?
Килешми бу, кирәкми,
рас уйладың үзгәрергә —
ялашуны сирәклик!

Бу — җан авазы. Әдип бул да әдәпкә өйрәтми калдыр — алай барып чыкмый шул ул.

Р.Мингалимнең мондый темага язган башка шигырьләренә тимичәрәк торыйк. Тәнкыйть ишәге һаман да мәкер апрасына үрелмәкче.

## IV

Р.Мингалим, яшереп торасы түгел, замананың интернационалист шагыйре. Әйе шул, нигә кирәк иде инде болай да кыерсытылган, кимсетелгән, каһәрләнгән, сүгелгән, пычранып беткән урысны кимсетергә? Агайның үзенә ошамас бит!..

Донос менә шулай, шундый сүзләр белән башланып китәдер әле ул? Аны кем өстеннән язганда да нәкъ шушы рәвешле сызгалап ташлыйсы, бер дә баш катырып торасы түгелдер әле! Хәер, моның нәкъ шулай булуын, тәнкыйть мәкаләсен язарга алынучы буларак, сүзебезнең башында ук аңладык. Вакытында туктый белмәдек, чөнки дусларыбыз-танышларыбыз да үртәделәр, әдәбият профессоры булып йөрисез, бер тәнкыйть мәкаләсе дә язып маташтырганыгыз юк, имеш, дип мыскылладылар…

Донос сүзенең татарчасы, безнеңчә, әләкләү, әләк-шәләк китерү генә түгел, илтотарларга илтеп тапшыру булырга тиеш, башы-кулына, аягына кабал кидертеп, билгеле. Эһ, егетләр,

туктатмадыгыз вакытында, табылмады арагыздан батырлар, инде шагыйребезне харап итеп ташлыйбыз, Ходам ярлыкасын!

Менә, җәмәгать, Р.Мингалимнең «Татар түбәтәе ник кара төстә, яки Ходай язса...» (2000) дип аталган һәм демократиягә гарык булган капиталистик илләргә хас постмодернистик алым белән язылган шигырен генә алып карагыз. Монда диндарлык та, хөр фикер дә, кайнар хис агымы да, «икеләнү» дә бар. Барысын да тәртип белән барлаганда, энәсе дә, җебе ачылыр. Карагыз әле нәрсә ди бу татарның бөек шагыйре!

Ходай язса, әгәр язса,
бирә бит ул байлыкны:
    татар иле — татарныкы,
    урыс иле дә аныкы?!
Зур урыска — бер генә ил
һәм шунысы кыенрак:
    ил үзәге томанлырак,
    чикләре — артык ерак?!

Хакыйкать ялчысы булгач, шагыйрь дөресен язмыйча кала алмый. Әмма мондый ук батырлыкны күкрәк киереп йөргән әллә ни кадәрле минкемнәр дә кыла алмады, ә Р.Мингалим... Ил эчендә егетлек күрсәтергә өндәгән дистәләп, йөзләп милләттәшебез барлыгына шигебез юк иде. Әмма Р.Мингалим һәммә ышанычыбызны аяк астына салып таптатты, өметләрембезне юк итте, бу калай әтәчләрнең ялтыравыгына хәйран итеп йөрүебезне төшендереп бирде түгелме? «Кайда сез, егетләр?»— дип аваз салырга гына калды. Аларның берсенең дә шушы кадәр батыр йөрәкле булуларын кәгазь өстендәге каләм сугышында да күрсәткәннәре юк иде әлегә. Оят, бик оят! Хәтта үз йөзебезне көзгедән күтәрелеп карарга оят! Һәр дөрес сүздән куркып, хаталарны яшереп, ялагайлык, ялган һәм куштанлык белән койрык болгап яшәүдә нәрсә башкара алдык һәм алачакбыз соң? Сәясәт мәйданында хакыйкатьнең башы түмрәнгә куелган һәм менә вәхшәтнең үткен балтасы айкалыр да — тын алырга да ирек бирмәс! Рәсәйнең иман шәмнәрен кабызып кына маташмакчы томана халкы шуны көтә, догага теле күнегеп җитмәс борын шуны ялварып сорый. Ә безнең Р.Мин-

галим интернацхис мәйданында тантана итә. Ник кенә шунда шовинизм мәйханәсендәтуй иткән сәрхүшләрнең акырышу-бакырышуларына колак салсын!

...Татарның —
иле икәү дә...
җиңел түгел аңар да:
ике илгә ярый торган
көй һәм бию табарга?!

Һәм, мишәр агайлар әйтмешли, суйган да каплаган! Ә сез: «Татарстанда әллә урыска яшәве рәхәтме?»— дисез. Нишлик, аларның китәр җирләре юк инде, бер уйлап карасак: Мәскәүгә кадәр — мукшы һәм татар җирләре, ә аннан ары — немец һәм карелныкы. Шагыйребез дөрес әйтә:

Ходай язса — бәндә күрә
тәкъдирендә ни барын:
Күрик әле, түзик әле,
        Яшик әле, дусларым?!

Инде тагын да «Казанның 1000 еллыгы уңаеннан» язылган «Кылыч йөзе буйлап» (2001) шигырен укып карагыз. Казанны талаган, җимергән, халкын суйган, чукындырган өлкән агабыз урыс халкын шушы кадәр дә кызганырга, аның өчен җан атарга, хәсрәт чигәргә, дөньяның алдынгы әдәбиятларына гына хас постмодернистик алымнар кулланырга кирәк идеме икән?

...Иртән ачсам
Казан радиосын —
ишетәм татар гимны газабын:
авызын Мәскәү учы кыса сыман,
кысылып... тына... көйнең азагы.

И шагыйрь әфәндебез, йөрәгебезгә каты кагыласыз!

Р.Мингалимнең бу китабы интернационализм, интернацхис белән шыгырдатып тутырылган. Дөрес, милләтчелектән башка интернационализм була алмый, интернацхиснең асылы бөтен барлыгы белән милли хисләр тантанасына корылган. Милләт-

че мәртәбәсенә ирешә алмасалар, шагыйрьләребез интернационализмга хилафлык китерер иделәр. Бу яктан Р.Мингалим иҗатын, әдәбиятыбызның затлы үрнәге дип тәкъдим итә алабыз.

Сүзләребездә шик һәм шуклану юк, монысын да укучыларыбыз аңласалар иде. Каләм карасына бераз шаянлык һәм тапкырлык кушып җибәрү сүз тәме өчен алдынгы халыкларның әдәби тәнкыйтендә бик хуплап кулланыла, ә без исә, аларга ияреп, алар кояшында йөзебезне яктыртырга маташучы алама ай кисәге генәбез, бигайбә!

V

Әйтмәгәнебез булсын, сүзебез озынгарак китте, ахрысы. Әмма күпме хакыйкатьләрне аңлатырга өлгерә алмадык, ничәмә шигыренә күзәтү ясалмады, берсе артына икенчесе тагылып саналмады, төркемләнмәде, бүленмәде, киселмәде. Тәнкыйтембезнең мәкерле корчаңгы аты тигез юлда абынудан гайрегә ярамады. Ә шулай да тагын бер талпынып карарга, Р.Мингалимнең шигъри осталыгына кыек күзебез белән төбәштергәләп ук атарга җөрьәт иттик. Әйтәләр бит, һавадагы чыпчыкка угын мәргән тидерер дә тидерер, менә сукыр яки кылый — торнага эләктереп карасын, егет булыр!

Сез Р.Мингалим шигъриятеннән верлибр эзләмәгез. Дөрес, шигырьләре традицион түгел, авангардизм коткысына бирелгәннәр. Әгәр сезгә аллитерацияләр, аллюзияләр (иллюзия түгел), анафора, антетиза, ассонанс, гротеск, ирония, метафора, перифраз, анжанбеман һәм башкалар кирәк булса — алар монда тулып яталар. Хәтта центон һәм элипсисларны да очратсагыз, бер дә аптырап калмагыз, алдыгызда — замананың бөек татар шагыйре китабы. Монысы да куштанлык һәм шаярту сүзе түгел.

Р.Мингалим шигыриятендә барыннан элек табигый һәм сыгылмалы, мәгънә-эчтәлеккә бай фикер агышын кысалаган форманың төзеклеге сокландыра. Шигырьләренең һәркайсында үз җене, үз җаны бардыр сыман. Хәтта җитәрлек дәрәҗәдә ныклы күренгән шигъри юлларында да, верлибрны да чын шигырь итә алган өстәмә эчке бөтенлек бар. Верлибр гына да булыр-

лар иде, әмма алар рифмасыз һәм ритмсыз түгелләр. Тезмәлек мәсьәләсендә Мингалим шигъриятенә тел-теш тидерерлек түгел. Әсәрләренең катлы-катлы шигъри бөтенлеккә корылуы сокландыра, гаҗәеп, бик гаҗәеп...

Кемгә ничектер, әмма бу җыентыкның иң затлы шигырьләреннән берсе дип «Шунда сине күрмим бит һаман...»ны атар идек. Аңа «Каләмдәшем Хәйдәр истәлегенә» дип куелган, ул 2001 нче елда язылган. «Замана шигыре нинди була» ул дигән сорауга, «нәкъ менә үзе, төгәл шушындый була да инде» дип җавап бирер идек без. Бәлки арадан кемнәрдер башкачарак фикердәдер? Мәйдан — егетләрнеке, тәнкыйть атын иярләгәндә Шайтан мәкеренә генә бирелмәгез, вәссәлам!

*2004.*

## ЗӨЛФӘТ ШИГЪРИЯТЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*(Әдәби-эстетик анализ тәҗрибәсеннән)*

Шагыйрь Зөлфәт XX йөзнең соңгы чиреге һәм XXI гасырның тәүге елларында татар әдәбиятының иң алдынгы вәкилләренең берсе булды. Әмма аның шигърияте билгеле бер чор яки дәвернең кысаларында гына калдырып булмый, ул киң фикерле әдип иде. Дөнья ваклыклары, көндәлек мәшәкатьләре белән бергә, аның шигъриятенә сыя алмадылар. Әдипләр, күпчелек очракта, билгеле бер чорның уй-кичерешләрен, хис-тойгыларын чагылдыралар. Зөлфәт андый шагыйрь түгел. Ул үз иҗатында чиксез иде, кешелекнең кичәгесенә дә, бүгенгесенә дә, хәтта киләчәгенә дә бәйле кичерешләр эчендә ялкынланып иҗат итте. Аны шулай ук аерым бер милләт шагыйре дип тә атап булмый, чөнки аның шигърияте аерым халыкның уй-кичерешләрен генә түгел, бәлки гомумкешелеккә хас йөрәк тибешен чагылдыра алу дәрәҗәсенә күтәрелде. Боларның сәбәпләре әлбәттә аның шигъриятенең көченнән, хисне сурәтли белү осталыгыннан,

дөнья әдәбиятын һәм кешелек омтылышларын даими тоеп иҗат итүеннән килде.

Зөлфәт шигърятен әдәби тәнкыйть табигать һәм мәхәббәт белән бәйле рәвештә бәяләп килде. Хакыйкатьне эзләүче шагыйрь буларак ачылуына зур игътибар бирелде. Һәр шагыйрьдәге кебек, Зөлфәтнең дә үз дөреслеге, үз хакыйкате бар иде. Ул аны иманы кебек үк кадерле һәм беренчел итеп кабул итте, аңардан чыгып фикер йөртте, башкаларга бәя бирде. Шәхес бары тик шулай гына яши ала. Аның лирик герое хакыйкатьне туктаусыз эзләргә мәҗбүр булды һәм аны табигый матурлыкта тапты. Шушы хакыйкатьне эзләү һәм табу процессы аның шигъри йөрәген даими ялкынсытып торды, борчыды һәм, нәтиҗәдә, нәкъ менә шушы процесс аны чын шагыйрь ясады. Моның мисалы итеп 1999 нчы елда язылган «Ходай сулышы» шигырен алырга мөмкин.

Инде кайтмас яшьлек
Йә якында,
Йә еракта учак кабыза,
Якын-ерак айкала да ялкын,
Бәгырьләрне өтә... Җан сыза!

Монда шагыйрь хис-тойгыларны учак белән бәйле тасвирлый. Бу учак, әлбәттә, мәхәббәт учагы. Ул нәкъ менә яшьлеккә хас күренеш. Лирик геройның үзендә түгел, бәлки аңа якында яки еракта кабынгалап тора, ягъни дөньялыкта яшьлек дәвам итә, яшьләрнең йөрәкләрендә утларын тергезә бара. Лирик геройның бәгырен инде менә шул якындагы һәм ерактагы ялкыннар өтеп ала һәм шуңардан йөрәге сызлана. Әмма монда аның җаны сызуны көнчелек дип түгел, бәлки яшьлегеннән ерагайган кешенең сагынуы дип кабул итәргә кирәк. Шул ук вакытта моның мәхәббәт ялкыныннан сызлануы да икәнлеген төшенми мөмкин түгел.

Зөлфәт ашкын көчкә ия шагыйрь, ул уйлану рәвешендә фикер бирә дә, бераз укучы күңелен аптырашта калдыра да, шунда ук яшьлекне тасвирлауга күчә, аның нинди икәнлеген ачык күз алдына китерерлек итеп бәянләп бирә:

Шул баш бирмәс еллар —
кайнар яшьлек
Уңны-сулны белмәс булганга —
Кагылганмын былбыл оясына
Һәм басканмын кара еланга...

Монда яшьлекнең кайнарлыгы белән бәйле лирик геройның уйланылмаган гамәле, гүяки саксызлыгы итеп, конкрет детальләр ярдәмендә төгәл тасвирланган. Былбыл оясы да, кара елан да әлегә символик мәгънәгә ия түгелләр. Үзсүзле лирик герой тормыш барышында ясаган хаталарын гына исенә төшерә дип укучыга уйларга кала. Шул ук вакытта, яшьлек кабызган учак белән бергә, ялкыннарның айкалуы һәм җан сызлануы, елларның баш бирмәс, уңны-сулны тоймас хәлгә лирик геройны төшерүләре укучыныкы белән уртак һәм аваздаш яңгыраш таба. Хисләр мозаикасы көч ала. Үткән белән бүгенге тойгылар буталышы барлыкка килә. Әмма бу буталыш шигъри тасвирның мәгънәсен көчәйтү өчен файдаланыла. Яшьлеккә хас шашкын хисләр тәэсирендә калган лирик геройның былбыл оясына кагылуы һәм кара еланга басуы һичшиксез укучы күңелен хәвефле итә, моның нәрсә икәнлеген һәмниләргә китергәнен белү теләген уята.

Шагыйрь кабат яшьлек уты хакында тасвири фикерләүгә күчә, шул рәвешле хис алмашын барлыкка китерә, инде онытылырга тиешле кебек тоелган тема яңадан кабатланып, шушы кабатлануы сәбәпле, хатирәләргә илтүче романтик мотивка әверелә.

Дөрли генә яшьлек, ут шикелле,
Сүнмәс, капмас өчен кабынган —
Кичке шәфәкъләрдә учак кабыз
Кичәге таң офыкларыннан!..

Монда шигъри романтик мотив теманың тотрыклы үсешен тәэмин итүче төп чараларның берсе булып тора. Әмма ул темага өстәмә мәгънә дә бирә һәм аның тасвири бизәлешен арттыра, тәэсир көченә хезмәт итә. Яшьлекнең ут шикелле дөрләп, сүнмәс өчен кабынуы йөрәктә калдырган хисләргә

бәйле. Зөлфәт шул хакта белдерә. Әмма ул яшьлек утын кабатланмас өчен кабынган дигән фикерне дә әйтә. Монда сүз яшьлек хисенең сүнәргә тиеш түгеллеге хакында бара, аңлашылып тора: ул бер тапкыр кабынып, инде сүнмәгән икән, аның кабатланып кабынуы хис бөтенлегенең саклануы өчен шарт түгел.

Шагыйрь яшьлек хисләренең сүнми гомер буе сакланырга тиешлеген символик фикер ярдәмендә конкретлаштырып тасвирлау остасы. Ул монда да, шигъриятенә хас буларак, шушы үзенчәлегенә тугыры кала һәм «Кичке шәфәкъләрдә учак кабыз / Кичәге таң офыкларыннан!..» дип, фикеренә сурәтле мәгънә бирә. Монда сүз яшьлек хисләрен картлыкта да саклау кирәклеге хакында бара. Кичке шәфәкъне көннең ахыры, ягъни гомернең соңы дип күзалласак, кичәге таң офыкларының моңа капма-каршы булуын, тормышның яшьлектән офыклары киң ачылып башланып китүен аңларбыз.

Зөлфәт теманы фәлсәфи эчтәлектә киңәйтә белү остасы. Ул моның өчен мәҗүсилеккә дә, тәңречелеккә дә, Ислам дине тәгълиматлары кысаларында яшәгән суфичылыкка да үтә сак кагыла һәм таяна белә. Шагыйрь кешелек тудырган һәм үстергән бер генә төрле тәгълиматны да кире какмый, аларның кешелек фикере-аңы үсешендә дә, иҗтимагый һәм табигый шартларда да әһәмиятләрен күрә белә. Зөлфәт шул тәгълиматлардан килгән белемнәрен үтә тоемлы шигъри фикер фәлсәфәсенә әверелдерү ягыннан җаваплы эш итә. Совет чорында марксизм-ленинизмга ничек таяна белсә, демократия дәверендә ул аларны кире какты дип әйтә алмыйбыз. Аңарда аң-белемгә, акылга ышаныч хисе көчле. Ул хакыйкатьне — инкарь итүдән түгел, бәлки шул хакыйкатьтә тирәнәюдән һәм шул юлда киңәя белүдән эзли. Аның иң явыз дошманы — фикер тарлыгы, фикерне аерым кысаларга бикләү, аның иң сөйгәне — фикер, хыял һәм фәлсәфә хөрлеге. Әмма бу шартлы фикер бирү калыбында алып барылмый. Ул табигыйлекне сөя. Аның әсәрләрендә шигырь өчен кирәк булган бөтен нәрсә дә (сурәтләр, күренешләр, фикерләр, мәгънәләр һәм башкалар) үзләреннән-үзләре, үз табигатьләре белән үз урыннарында җиңел агым рәвешендә бөтерелеп барлыкка киләләр. Зөлфәт

табигать белән сөйләшкәндә ничек мәҗүси өннәрне тартса, галәм белән ялкынлы тәңречелек тәгълиматы телендә аңлаша белә, күңел дөньясын Ислам дине тәгълиматыннан башка күз алдына китерергә теләми. Аның өчен Аллаһы тәгалә, Ходай иң беренче чиратта күңел дөньясының ачкычы булып тора.

...Ходай сулыш өргәч җан кергән бит
Безгә —
сынга—
үзле балчыкка!
Бәлки тагын сулыш өрер Ходай?
«Җитте...»— димә, йөрәк, ашыкма!

Үзле балчык гыйбарәсендә үзсүзлелек мәгънәсе дә бар. Бу шигырьнең «Ходай сулышы» дип аталуын да искәрсәк, шагыйрьнең фикерләвеннән аңлашылганча, сүз җан турында бара. Зөлфәт кешенең яңадан тууына һичшиксез ышана. Әмма башка сыйфаттагы туу түгел, ягъни будда дине фәлсәфәсенчә, кешенең үлемнән соң яки үсемлек, яисә хайванга әверелүе хакында сүз бармый, бәлки Ислам дине тәгълиматы буенча кеше булып калуы турында. Шунысы әһәмиятле, Зөлфәт дини-фәлсәфи тәгълиматларны ачык аңлап, бер-берсе белән бутамыйча фикерли белә торган әдип. Бу факт аның белем киңлекләре һәм аң дәрәҗәсенең камиллеге хакында ачык сөйли.

Зөлфәт шигырьдә яңа бер тематик күчеш ясау өчен фикер юнәлешләрен үзгәртеп куярга ярата. Әмма мотив һаман да сакланып кала. Шул сәбәпле теманың эзлекле үсеше дә тәэмин ителә. «Ходай сулышы» шигыренең беренче биш куплетында теманың үстерелешен ут, учак сүзләре белән бәйле эчтәлек тәэмин күтәрә. Шушы ук вакытта Зөлфәт шигъри фикерләмәләр һәм сурәтләр эчендә Ходай сулышы, былбыл, кара елан белән бәйле яңа тематик юнәлешләргә корылган фикерләмәләренә дә юл ача, әмма ут һәм учак әлегә төп романтик мотив билгеләре булып кала киләләр.

Ут йөгергән шул сулыштан
Сулык-сулык типкән бу канга —

Димәк,
сөю булып килеп керден
Үзең гомер иткән Ватанга!

Аңлашылганча, монда сүз мәхәббәт тәэсирендә кешенең камилләшүе белән бәйле үзгәреше хакында сүз бара. Әмма ул бу юлы башка тематика кысаларында, үлгәннән соң туу түгел, бәлки яшәгән кешенең яшьлектәге кабатланмас үзгәреше хакында. Зөлфәт кешенең бөтен яшәешенең асылы мәхәббәттән гыйбарәт икәнлеген ачык белдереп яза. Ул аның башкача, башка төрле тәэсирләрдән була алуын шигъриятендә күз алдына китерергә дә теләми.

Билләһи, дим:
гомер дигәнебез,
Еллар белән санап карасаң,
Мең афәтле еллар түгел һич тә —
Мәхәббәтле еллар лабаса!

Шагыйрь бу ачышын тантаналы төстә яңгырата. Антик һәм борынгы әдәбиятлардан ук үстерелеп килгән шушы фикер көчле яңарыш кичерә, шуның аркасында хакыйкатьнең асылын конкретрак төшенү формасы буларак аңлашыла: монда шагыйрь мең афәтле елларга мәхәббәтле елларны каршы куя. Шул сәбәпле мәгънә тирәнлеге дә барлыкка килә.

Зөлфәт һәрвакыт әдәби-фәлсәфи ачышлар шагыйре булды. Аны шигырьнең ритмик буыннарын үзгәртү белән бәйле табышлар да, рифма уйнатулары да кызыксындырмады. Алар аның шигъриятендә очрасалар да, әдипнең иҗади теләге аркасында түгел, бәлки табигый рәвештә, шигырь һәм мәгънә агышы аркасында гына шулай килеп чыккаладылар. Зөлфәтне әсәрләрендәге хис агымының мәгънә белән уратылып һәм өртелеп барылуы күбрәк кызыксындырган. Шигырьдә мондый агышны саклау гаять авыр. Иң беренче чиратта мәгънә үстерелеше әдиптән фикри эзләнүләр таләп итә. Шагыйрь бер әсәре кысаларында төрле фикер юнәлешләренә кереп китәргә мәҗбүр була. Алар эчтәлектә чагылмый калмыйлар. Андый хатадан котылу өчен Зөлфәт фикерне сурәткә әвереллдерә,

теманы саклау максатында шигъри мотивларга аеруча зур игътибар бирә.

Чәчләремне еллар тараганда
Уйларымны еллар тарады —
Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Кара елан миңа сайрады.

Зөлфәт бөдрә чәчле иде. Яшьлегендәге купшы бөдрәләре, ул олыгайгач, тәмам тигезләнеп беттеләр диярлек. Әгәр дә шушы фактка игътибар итсәк, чәч бөдрәләренең кайнар холык һәм хис билгесе икәнлеген кыяфәтнамә гыйлеме ярдәмендә күзалласак, чәч тарауның монда шул бөдрәләренең тигезләнүе буларак бирелгәнлеген аңлавы авыр түгел. Шушы тәгъбирдән чыгып, лирик геройның еллар узган саен холкы утыруы хакында сүз алып барганлыгын төшенүе авыр түгел. Шагыйрь хәтта уйларның да еллар узган саен тигезләнүе, ягъни хисләрдән арына баруы хакында әйтә. Боларга капма-каршы куеп, йөрәген былбыл чагу, кара еланның сайравын тыңлавы хакында искәртә. Бу фәлсәфәсе хисен һәм холкын аңлатучы сәбәпләр сыйфатында бирелә. Яшьлегендә былбыл оясына кагылган, кара еланга баскан иде ул. Шигырьдә шушы тема лейтмотив булып кабатланып килә, әмма яңа эчтәлек ала бара: былбыл — йөрәген чага, кара елан — аңа сайрый. Монда былбылның агуы хакында, еланның моң бирүе турында сүз бара дияргә мөмкин. Боларның асыл мәгънәсен аңлавы авыр түгел: сүз шагыйрьнең үз шигъриятенә бәясенә бәйле. Зөлфәт үз иҗаты хакында уйлана һәм аның эчтәлеген дә, үзенчәлекләрен дә ачарга, аңлатып бирергә омтыла. Сәбәпне яшьлегенә, шашкын мәхәббәт хисләренә китереп бәйли.

Зөлфәт конкрет формалар һәм сурәтле күзаллау ярдәмендә фикерли, дидек. Шигырьләрендә мәгънәне образларда тасвир итә. Аның бу осталыгы әсәрләрен хисле һәм киң яңгырашлы итә. Шигырьләре хисне гомуми планга алып язудан башланып, конкрет вакыйганы тасвирлауга күчә, ахырда яңадан гомуми план алына. Шушы рәвештә әдәби конструкцияләрен коруы шигырьләренә укучы күңеленә ирешү өчен юл ача. Алар тормышчан һәм аңлаешлы эчтәлектә булып чыгалар. Шагыйрь

мондый формаларның беркатлылыкка, артык гадилеккә китерүен аңлап, теманы мотив һәм лейтмотивлар белән шактый катлауландыра алды, шуның белән шигырьләрендә хис һәм мәгънә көчен арттырды. «Ходай сулышы» шигырендә дә ул шулай эшли.

...Ник тоташтан
гашыйк булам һаман?
Алгысытыр еллар күп мәллә?
Ходайның бер Кашка Тәкәсеме?
Яшәр җирем — Изге Күк мәллә?

Монда, «Ходайның Кашка Тәкәсе» дигәндә, автор «Аллаһының Сөеклесе» дигән төшенчәне файдалана. Исмәгыйль пәйгамбәргә нисбәтле вакыйгалар күз алдына килә. Шагыйрь тоташтан гашыйк булуның сәбәбен эзли һәм аны яшәү белән дә, Аллаһының сөекле бәндәсе булуга да бәйли, мәхәббәт аркасында кешенең урыны Изге Күк булачагын да белдерә. Гыйшык өчен җавап бирәчәге дә аны куркыта, мәхәббәт аркасындагы гөнаһлары савапка әверелүгә дә өметләнә.

...Туймас-төкәнмәс бу
гыйшкым өчен,
Ни диярмен анда — азакта?
Яратудан кылган гөнаһларым
Саналмасмы икән савапка?

Монда сүз җилбәзәклек турында бармый, билгеле. Шагыйрь шагыйранә мәхәббәт хакында фикерләрен җиткерә. Аның шулай икәнлеген алдагы шигъри куплетта тагын да конкретлаштырып әйтеп бирә:

Уйнаклап кан,
әйбәт җөмләләрне
Яшьтән шигырь итеп
мин шаштым —
Болар миңа савап саналмас шул...

Болар —
минем бетмәс гөнаһым!

«Шигырь — шайтан чыбыркысы!» дигән гыйбарә бар. Аны Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисенә нисбәт итәләр. Хикмәт шунда, Мәккә тормышына бәйле чорда, Пәйгамбәрдән кәферләр шигырьләр-такмаклар әйтеп көлеп мыскыллаганнар. Шигырьнең күңелгә җиңел үтү үзенчәлеге бар. Пәйгамбәребез шул шигырьләрдән бик тә мыскылланган һәм, җавап буларак, игътибарга алынган хәдисен әйтә торган булган. Монда шигырьнең бәгырьне телгәләве хакында сүз бара. Әмма гасырлар эчендә бу хәдиснең эчтәлеге вакыйгасына бәйсез аңлатыла башлап, шигырьне шайтаннан килә дигән фикер таралыш алган. Суфи шагыйрьләр шунлыктан шигырьгә мөмкин кадәр дини мәгънә салып, аның хискә корылу үзенчәлегеннән баш тартырга тырышканнар, шунлыктан әсәрләре коры дидактик эчтәлектән гыйбарәт булган формаларга кергән. Бары тик XIX йөздә Г.Кандалый һәм М.Акмулла татар әдәбиятында шигърияtne хис стихиясенә кайтару эшен башлап җибәрәләр. Зөлфәтнең исә, бетмәс гөнаһ дип әйтүе — схоластик дини карашлар тәэсиреннән икәнлеге укучыга аңлашылып тора. Әмма, әйткәнебезчә, Зөлфәт һәртөрле тәгълиматлар һәм карашлар белән җаваплылык һәм хөрмәт хисе тоеп эш итә. Китерелгән мисал моны тагын да ачык дәлилләп тора.

Зөлфәт хисләрне ничек кабартса, шулай тынычландыра да белә. Аның гөнаһ һәм савап хакында шигъри уйланулары «Ходай сулышы»нда да шушы рольне башкара. Укучы ул каршылыклар эчендә тетрәнү ала, бу аңа рухи чистарыну бирә. Шагыйрь моны аңлап эш итә һәм, тынычлану стихиясенә бирелеп, шигъри мотивны кабатлап яңгыратып ала. Хис камиллеген тудыруда мондый уңай композицион юлларны файдалана белүдә Зөлфәт кебек уңышлы иҗат иткән шагыйрьләрне күпләп санап булыр иде. Г.Тукайның «Пар ат»ы моңа отышлы мисал икәнлеген искәртеп үтү дә җитәр.

Зөлфәт тынычлануның ни-нәрсә икәнлеген килешү һәм язмышын ничек бар шулай кабул итү турындагы шигъри юлларында тасвирлап бирә:

Китмәс өчен килде, ахры, яшьлек...
Тетрәп,
        дөнья онытылганда
Кагылам гел былбыл оясына,
Һәм...
        басам гел кара еланга!

Ахырына таба шигырь яңадан тантана көчен ала. Мотив буларак сайлап алынган былбыл һәм кара елан вакыйгасы, ешрак кабатланып, лейтмотивка әверелдерелеп, әсәрдә төп фикер доминантасын барлыкка китерә.

Рәхмәт, дөнья,
Язмышның син миңа
Тоташ шигырьлесен сайладың,—

Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Һәм өздереп елан сайрады!..

Упкын төпләрендә гөлләр үскән
Кыяларны белеп сайладым...
Мин
        былбылдан сезне чактырырмын,
Тыңлатырмын елан сайравын.

Зөлфәт нечкә күңелле лирик шагыйрь буларак дан алды. Аның әсәрләре вакыт чиксезлеге тоемында, кешелекнең яшәеш фәлсәфәсе кысаларында язылган. Әдипне һәрдаим кеше табигате, аның уй-кичерешләре, хисләренең бөтенлеге кызыксындырды. Шигырьләре күңел мәгънәсе тирәнлегендә туып, халкыбызның теләк-омтылышларын гомумкешелек мәртәбәсендә яңгыраттылар.

*26.01.09.*

## УРАЛ ТУЛПАРЫ

*(Шагыйрь Р.Ягъфәров иҗаты үзенчәлекләре)*

Рәшит Ягъфәров галим булып яшәде. Фольклорист иде. Милли хәрәкәт җитәкчеләреннән берсе булып күтәрелде, халкыбызның хөрмәтен яулады. Ә аның шагыйрь икәнлеген бөтенләй дә белмәгәнбез. Ул, чынлыкта, шагыйрьлеген артык күрсәтмичә, танытмыйча, шул бөеклеге дәрте белән саф хисләргә бай, затлы күңел моңында сызып кына сагышланып яшәүчеләрдән дә түгел иде сыман. Аның күкрәк аранында мәңгелеккә таба томырылырга тиеш булган тулпар тышауда торган. Көннәрнең берендә ул алтын тояклы, киң канатлы шигъриятенең тулпары үзен тоткынлыкта тоткан диварларны ватып-җимереп, бәреп чыгар да үзенең күркәмлеге белән безне сокландырыр дип көтәргә дә түгел иде. Әмма замананың шартлы билгеләре алып ташландылар. Кичәге идеология шигърияте чигенде. Халыкка чын әдәбият кирәк иде. Яңа, кешелек хисләрен түкми-чәчми сөйләп бирүче әдәбиятны мәйданга чыгарган шагыйрьләребездән, үткәннән килеп, әмма яңа заманныкы буларак тавышын ишеттергән әдипләребез арасында Р.Ягъфәров та бар иде. Ул вакытлардан бирегә таба еллар узган, ераклаша барган саен, моның шулай икәнлеге тагын да ачыклана төште. Тарихыбызга без дә хөрмәт белән карарга өйрәндек. XX гасырның 90 нчы еллары иманыбызны төзәтте. Ул чор татарның шанлы әдәби мирасын кабаттан кайтып тикшергән, асылда Г.Исхакыйны гаделлек байрагы итеп күтәргән чаклары иде. Күп әдипләр үз иҗат мирасларын тарих үлчәвенең хөкеменә тапшырдылар. Яңа чор идеал эзләде, шигърияттән илаһи сүз көтте. Әмма яңалар туарга өлгермәгән, без аны кабул да итәргә өйрәнмәгән идек. Бу юлы да онытылган, игътибарсыз калдырылган иҗатлар ярдәмгә килде. Менә шул чорда иске, күнегелгән исемнәр яңа төсләрдә, яңа форсатта яңгырадылар.

Р.Ягъфәровның «Тулпарларым» (1969), «Рәхмәт, җырым...» (1971), «Карт диңгезче җыры» (1967), «Агымсулар моңсулата» (1968), «Кайтыр юлда ап-ак томан» (1969), «Шоңкар моңы» (1971), «Гафу сорыйсы бар...» (1971), «Тол буенда» (1969),

«Хыянәт» (1976), «Илле яшем» (1981), «Акбүз ат» (1968), «Сагынылды» (1969), «Бүген тагын...» (1969), «Кайттым бит...» (1971), «Балалар паркында» (1981), «Тынгысыз төн» (1970) дип аталган шигырьләре яратылып укыла башладылар. Аның «Сабантуй мизгелләре» (1975) шигырьләр циклы үзенә бер әдәби табышка корылган, бәйрәмнең күңелле уеннарына багышланган күренешләр белән бәйле хис-кичерешләрне тасвирлау белән характерлы. Дөрес, Р.Ягъфәровның сәяси шигырьләре дә шактый. Уйландыралар. Фикергә этәрәләр.

Шигырьнең хикмәте тышкы һәм эчке кичерешләрнең гармониясен әдәби мантыйкта мәгънәле итеп бирә белүдән гыйбарәт. Гади һәм гадәти итеп язу осталыгы ул – беркатлы тезмәләр белән әсәрне тутыру түгел, бәлки гади һәм гадәти тоелган, кешенең, һәр шәхеснең дөньясында-табигатендә бар хисләр-тойгыларны күңел төпләренәчә төшеп айкалдырырлык, чайкалдырырлык, шуның белән рухи сафлыкның, мәгънә энҗеләренең һәр йөрәктә ачылып китүләрен тәэмин итеп яза белүдән гыйбарәт. Бездә сүз куерталар, мәгънә авырайталар, фикер бирү артыннан куалар. Ә югыйсә чын шигырь өчен әллә нәрсә кирәк тә түгел сыман. Хисләрне тасвир итеп бирү дә җитә. Әмма моны чын шагыйрь генә башкара ала.

Р.Ягъфәровның шигырьләре арасыннануналтысын сайлап алып күрсәтүебез икән, аларның менә шушы дәрәҗәдә гүзәл язылган булуларын таныту өчен мисалга китерүебез ул. Алар классик дәрәҗәдә туганнар. Рәшитне чын мәгънәсендә шагыйрь Рәшит Ягъфәров иткәннәр. Язылган елларына карасак, алар 1967 елдан 1981 еллар арасында туганнар (1967 дә – 1; 1968 дә – 2; 1969 да – 5; 1970 тә – 1; 1971 дә – 4; 1976 да – 1; 1981 дә – 2). Аз да, күп тә түгел. Китапта басылып чыгу елларына караганда — чын мәгънәсендә әдәби мирас. Тыелган мирастан да түгел, бары тик күз уңыннан читтә калган, әмма, вакытлар узган саен күңел-рух ихтыяҗыбызны канәгатьләндерүдә кирәкләре арта барган шигъри мирастан алар. Шул әсәрләреннән күренгәнчә, Р.Ягъфәровның иҗаты 1969 нчы елга чын асылы белән оешып җитә, 1971 нче елга кадәр үз көчен саклый. Ә аннары сүрелә бара. Аның 1970-71 нче еллары, шигырьләреннән күренгәнчә, «Солдат дәфтәре»

чорына туры килә. Р.Ягъфәров әгәр дә 1967-69 нчы елларда тапкан һәм ирешкән шигърилеген югалтмый саклап, алга таба көчле ялкынлы учак итүгә ирешсә, халкыбыз аның шигърияте җылысында күңелен савыктырып яшәгән булыр иде. Әмма моның өчен аңа тормыш та, Тәңренең бирмеше дә җай куймаганнар (ул үзе бу хакта болай дип белдерә: «Тәңрем миңа үзгәреп торучан холык биргән»[1]).

Р.Ягъфәров озак еллар буена киң җәмәгатьчелек алдында шагыйрь буларак беленми торды, дидек. Бу хәл бәлки дуслары, туганнары өчен сер дә булмагандыр? Бәлки аңа наширлар, әдәби редакторлар юл бирмәгәннәрдер?

Р.Ягъфәровның 1969 нчы елда ук язылган «Тулпарларым» шигыре иң камил әсәрләреннән берсе. Күңеле тулы уйларын ул ыргылырга торган тулпарлар итеп тасвирлый. Шушы уйлары аны йокысыннан уята. Лирик герой алар артыннан йөгерә-чаба.

Бу шигырьнең серле хикмәте бар. Шигъри тойгы-хиснең үзгәреше бер фикердән икенчесенә эверелеш рәвешендә бирелгән. Мондый шигырьләр дөнья әдәбиятында да сирәк очрый. Аны хис-тойгы, хыял-өмет могҗизасы буларак аңларга кирәк.

Башны салып йокымсырап китсәм,
Шул тулпарлар кешнәп уята,—

ди шагыйрь. Лирик герой сикереп тора. Әмма тулпар-уйлары юлларда дага чыңы калдырып үтеп киткәннәр. Шагыйрь рухы алар артыннан калмый гомер буе шулай йөгерә, бары җилдавыллар — аның юлдашы.

Р.Ягъфәров, уйларны ыргылучы атлар итеп сурәтләп, яңалык та ачмыйдыр кебек. Уйлар шундый инде алар, хыяллар кебек үк ашкыналар. Әмма шагыйрь:

---

[1] *Ягъфәров Р.* Язмышым — шигырьләремдә [Сүз башы мәкаләсе] // *Ягъфәров Р.Ф.* Тулпарлар моңы: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— Б.3.

Егылып калсам, очкан тулпар итеп
Ясасыннар минем гүр ташын,—

дип белдерә дә бөтенләй башка тойгылар, мәңгелек белән тоташкан горур һәм мәгърур хисләрнең сафлыгына хисләрне күчерә.

Ир егеткәй белән ат башына
Тәңрем белгән ниләр бирәсен.
Тулпарларга — канат,
Миңа исә
Тулпар җанын биргән, күрәсең.

Бу шигырь чыннан да могҗиза, ул хис, тойгы, сурәт, фикер могҗизаларының бербөтен булып әверелүеннән туа. Әсәр шагыйрьнең 2006 нчы елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан Казанда бастырылып чыгарылган 143 битле «Тулпар моңы» исемле шигырьләр җыентыгыннан. Китап шушы камил, могҗизалы шигырь белән ачылгач, андагы һәммә әсәрләрдән дә шушындый ук бөеклекне көтәсең. Аның янәшәсендә «Рәхмәт, җырым...» шигыре килә.

Аның үзәгендә «идеалларга таба китеп баручы» лирик герой сурәтләнелә. «Йөзен кисеп ачы җил исә». Менә шунда шагыйрь халык җырларын искәртә, лирик геройның «Кара урман»ны җырлавын сурәттә биреп ала. Шундый җырлар упкыннарга төшәр мәлдә өскә күтәрүен белдерә. Асылда җыр канатлары, дөньяның моң-зарын кыйный-кыйный, кеше рухын күккә ашыралар икән. Шагыйрь моның шулай булуын чынлап ышанып, ихластан яза һәм укучының да гомеренең авыр минутларында җырда күңелен юатуларын исенә төшерерлек итеп тасвирлый. 1967 нче елда ук иҗатында туган «Карт диңгезче җыры» (аңа автор «Укытучыларыма» адресын да куйган) шигырендә көймәсен, йөзгәнендә аумасын дисә, дулкыннарга каршы йөздерергә киңәш иткән карт диңгезче вә диңгездә көймәсен дулкыннарга каршы алып баручы яшь кеше сурәтләнелә. Бу шигырь әдәбилек ягыннан да талантлы эшләнелгән. Шагыйрь аны 21 яшендә язган.

Р.Ягъфәров шигырьне сурәтле вакыйга, күренешләр үзгәреше чалымы тасвирлары белән иҗат итә. Мирасында үзгәрешсез, хәрәкәтсез калган күренеш шигърияте бөтенләй юк. Сурәтле тасвирларының хәрәкәт егәре дә көчле, тәэсирле. Алар олы, гаҗәеп әһәмиятле вакыйгаларның шигъри мизгелләреннән гыйбарәт, тормышның чиста-саф булып күңелдә уелып кала барган хакыйкатьләре, әлбәттә. Болар шагыйрь Р.Ягъфәров иҗатының асыл үзенчәлекләре, аның әдәби мирасын кыйммәтле дә, әһәмиятле дә иткән төп сыйфатлары да.

*Февраль, 2013.*

# Ә.ЕНИКИ ИҖАТЫНДА ӘДӘБИ ГЕРОЙ КОНЦЕПЦИЯСЕ:
## *ТӨП ЭЛЕМЕНТЛАРЫ*

Прозада әдәби геройларның сурәтләп бирелеше аерым әһәмияткә ия булуын, аларны өйрәнү һәм бәяләү үзе үк әсәргә ясала торган төп анализ юлларыннан берсе икәнлеген барыбыз да яхшы беләбез. Укучылар инде мәктәптә үк, югары сыйныфларда, әдәби геройларга характеристика бирү юлларын үзләштерәләр, шуның ярдәмендә тормышта үзләрен һәм кешеләрне танырга, башкаларга карата мөнәсәбәтләрен булдырырга өйрәнәләр. Ә.Еники әсәрләренә килгәндә, алардагы әдәби геройлар татар әдәби тәнкыйте һәм әдәбият фәне тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән, бәяләнгән, аның геройларны күп очракта чагыштырма планда тасвирлавы да кат-кат бәяләнгән икәнлеген искәртергә тиешбез. Димәк, бу яктан без өстәмә нинди дә булса яңа фикер яки мәгълүмат бирә алмыйбыз. Әдәби герой концепциясенең төп элементларына килгәндә, язучы иҗатын анализлауда конкретлыкка омтылыш соралып тора. Без моның шулай булуын, чәчелмичә, бер әсәр мисалында да күрергә мөмкинбез.

Фикерләмәләребезнең үзәгенә Ә.Еникинең «Йөрәк сере» повестен алып, алардагы геройларның бирелеш концепциясен ачыкларга керешкәнче, игътибарны моңа кадәр билгеле булган фәнни күрсәтмәләргә юнәлтик.

Ә.Еники иҗатын һәм тормышын өйрәнүчеләр арасында төп галимнәрдән саналган Ә.Р.Мотыйгуллина бу повестьның ике геройны каршы кую ысулы белән язылганлыгын болай аңлатып бирә: «Аның берчесе — Нәҗип белән бәйле... Аның кырыс холкын шул еллар мохитеннән аерып карап булмый.— дип яза ул, икенчесе, әлбәттә аңа капма-каршы куелырга тиеш-

ле герой инде: — ... Очраклы рәвештә генә танышкан... Бәхетгәрәй бөтенләй башка. Ул — хис кешесе»[1].

Әсәрнең эчтәлеген искә төшергәндә, ул катлаулы түгел: Казаннан Идрис исемле тарихчы («Кандидатлык диссертациямә аз булса да хәзерләнермен дип (мин үзем тарихчы, күптән тарих укытам), ярты чемодан әдәбият төяп килгән идем, шуларга тотынып та караганым юк» дип уфтана Идрис әсәрнең IV бүлегендә) Сочидагы «Дулкын» санаториена килә. Ул монда бер ел элек кенә булган. Шул вакытта ук Зөһрә исемле чибәр ханым белән танышып, аның йөрәгендәге серне хикәя итеп сөйләвен тыңлаган да, менә хәзер аларны, хәтерендә яңартып, укучыга бәян итә. Вакыйгаларга ярлы, баналь гына мәхәббәт тарихчасы килеп чыга. Зөһрә аны, ни хикмәт, тау сыртындагы имән төбендә, диңгез панорамасы һәм кояш баешы күренеп торган урыннан өч кич буена, алар арасында хәтта берничә көннәр очрашмыйча торып, ашыкмыйча гына сөйләп чыга. Аның хикәясенең беренче зур өлеше Нәҗипкә багышлана, ахырда, бик кыска гына итеп, Бәхетгәрәйгә мәхәббәте бәян ителә. Ул шул ук М.Акъегетнең «Хисаметдин менла»сындагы, М.Фәйзинең «Галиябану»ындагы һәм башка йөзләрчә әдәби әсәрләрдәге «мәхәббәт өчлеге» вакыйгаларын хәтерләтә, алардан әллә ни аерылып та тормый. Мәсәлән, Канифәнең, бай һәм булдыклы Сибгатулланы санламыйча, Хисаметдингә «ябышып чыгуы», яки Галиябануның шундый ук бай егет Исмәгыйльгә бармыйча, авылның урта хәллесе (ярлысы түгел) Хәлилгә «ияреп чыгарга» теләве — болар татар укучысы өчен бик тә таныш, мәхәббәт дигән могҗизаның серен төшенеп бетү мөмкин түгеллеген кат-кат дәлилләгән иделәр инде.

Укучы Ә.Еники кебек талант иясенең дә шушы банальләшкән мәсьәлә белән мавыгуына бераз аптырашта калырга тиеш, билгеле. Әмма әсәрне укыганда да, укып чыккач та андый хис уянмый. Хикмәт нәрсәдә соң? Әлбәттә Ә.Еникинең, әдип була-

[1]*Мотыйгуллина Ә.Р.* Психологик проза остасы // Еники Ә. Сайланма әсәрләр.— “Мәктәп китапханәсе” сериясе, Т. II.— Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002.— Б.18–19.

рак, вакыйгаларны тасвир итү осталыгында. Ул әдәби әсәрләрендә һәрвакыт «сер эченә сер» яшерде. Шуның аркасында бик гади тоелган вакыйгалары тирән эчтәлек алдылар. Иң кызыклысы тагын да шунда, аның шушы «сер эченә сер» бикләп язулары күңел белән җиңел хис ителә, әмма акыл белән аларны төшенер өчен зыялылык, интеллектуальлелек кенә аз, интуициядән башка мөмкин түгел. Шунлыктан, мәсәлән «Йөрәк сере» повестена анализ ясаганда, тәнкыйть тә, фән дә бик җиңел генә хата юлга кереп китеп, дистәләрчә кат әйтелгән һәм кабатланылган фикерләргә килеп төртелми калмыйлар. Хәер, монда сүз Ә.Еники турында гына бармый, бәлки әдәбиятны аңлау һәм аңлату-анализлауга да барып тоташа.

XX йөзнең 60-70 нче еллар татар әдәбияты «конфликтсызлык теориясе» нигезенә корылып иҗат итеЛДЕ. Ә.Еникинең күпчелек әсәрләре шул чорга карый, «Йөрәк сере» повесте, мәсәлән, шул теориянең иң лаеклы үрнәкләреннән берсе булып тора. Монда Нәҗип һәм Бәхетгәрәй арасындагы тышкы каршылык, конфликт юк, алар бер-берсе белән таныш та түгелләр, бер-берсенең барлыгын да белмиләр. Алар арасында шартлы каршылык булса да, ул бары тик Зөһрәнең аларны үзара каршы куеп, булдыклы, акыллы, тәрбияле, зыялы, зур һәм данлыклы заводның баш инженеры Нәҗипне ярата алмавыннан, сугышка барганында Чиләбедә вакытлыча тукталган, типтәр белән башкорт каныннан туган офицер Бәхетгәрәйгә үзенең хисләрен багышлавыннан гына килеп туа, шул сәбәпле ул хисләре иҗтимагый төс тә алмый. Монда кызның йөрәген яулар өчен төрле авырлыклар аша узарга җыенган геройлар юк. Хәтта Зөһрәнең үзендә дә без андый сыйфатны күрмибез. Вакыйгаларда геройларның кискен каршы куелуы гына әдәби әсәрнең сюжетны мавыктыргыч итә дип белдерергә теләүчеләргә «Йөрәк сере» повесте эшнең киресен сөйләгәне аңлашыла башлый. Хәтта сюжетның нигезен геройларның үзара конфликты төзи дигән теоретик карашны да юкка чыгарырга тиеш булабыз. Шул ук вакытта сорау да тумыйча калмый: бәлки әсәрнең вакыйгалары, шулар белән бергә сюжеты да асылда Нәҗипкә дә, Бәхетгәрәйгә дә бәйле түгелдер? Алар турында сөйләп чыгу авторга бары тик укучының игътибарын башка

якка алып китү өчен генә кулланылган булса — бусы инде Ә.Еникинең әдәби осталыгының дәрәҗәсе югарылыгын тагын бер кат раслый торган фактка әверелә түгелме? Бу әдипнең «сер эченә сер» яшерү осталыгын күрсәтмиме?

Без әдәби иҗатның күңел белән башкарылуын, шул чагында гына чыннан да талантлы әсәрләр туарга мөмкинлеген тәкрарлап сөйләргә яратабыз. Моның асылда ничек булуын язучылар үзләре дә аңлап җиткерә алмыйлар. Алар язылучы әсәрләрен мөмкин кадәр «акыллы» итәргә тырышалар. Фән дә, тәнкыйть тә, ул әсәрләрне анализлауга, аңлатуга алынып, аларны тагын да акыллырак һәм мәгънәлерәк итеп чыгара.

Ә.Еникинең «Йөрәк сере» повесте, инде искәрткәнебезчә, санаториега килгән Идриснең былтыргы танышы Зөһрәне сагыну халәтен тасвирлаудан башланып китә. Автор Кырым табигатенең матурлыгын, героеның хисләренең нечкәлеген соклану планында да, фәлсәфәле кичерешләр юнәлешендә дә ача барып, укучы күзләрен санаторие бинасының өченче катындагы, кырыйдан дүртенче балконына төбәлергә мәҗбүр итә. Повестьның хатирәләр эчендә йөзгән герое Идрис бу вакытта тын бакчадагы яшел эскәмиядә утыра. Ул бүген генә, көннең икенче яртысында килеп төшкән, урнашкан, душ та коенып чыккан. Кичке ашка кадәр вакыты бар. Ял итеп утыра. Аның бу юлы Зөһрәне күрергә теләп килгәнлеге аңлашыла.

Әсәр Идрис теленнән сөйләнелеп алып барыла. Ул: «Зөһрә — минем бик яшерен йөрәк серем иде»,— дип белдерә. Бу сер аның бары тик йөрәгендә генә саклана ала, башкача түгел. Укучыга да бу кызыклы булып тоела. Дөрес, озын гына бер вакыйга бәян ителеп, ахырдан аның морале чыгарылып куелучан. «Хәйләкәр» укучы әсәрнең шул өлешен табып укый да, әсәрнең эчтәлегенә төшенеп ала, инде җентекләп укып та торасы юк, кызыгы бетә. Әмма Ә.Еники әсәрләрендә андый мораль бирелеш өлеше юк, булганда да, ул башка, әсәрнең тышкы вакыйгалар катламыннан гына килеп чыга, төп фикер булып әверелә, әмма идеясе хезмәтен үтәми. Моны аңлау өчен, мәсәлән «Әйтелмәгән васыять»кә бәйләнешле алып, бер сорау бирү белән төп фикер һәм идеянең икесе бер нәрсә түгеллеген төшендерергә була: «Ни өчен Ак әби үз васыятен, әгәр дә балалары

тыңларга вакыт тапмаганнар икән, кулдан язып калдырмаган соң?» Аннары, аңа васыятен калдыру нигә кирәк булды соң әле? Бу, әлбәттә, «сер эчендә сер», әдәби тәнкыйтькә дә, фәнгә дә, башкаларга кәгазьләр тутырып фәлсәфә корырга, тәрбия, заман, яшәеш мәсьәләләрендә ачыктан-ачык сөйләшү ачарга мөмкинлекләр бирә.

«Йөрәк сере» повестенда да шулай килеп чыгар иде, әмма автор Нәҗип белән Бәхетгәрәйне бигрәкләр дә ачык итеп, контраст сурәтләрдә тасвирлап, гүяки бөтен әйтергә теләгәнен дә күрсәтеп биргән. Дөрес, монда әдәби тасвирлар детальләштерү ягыннан да аерылып торалар. Нәҗипкә бары коры буяулар гына туры килә. Аның җитдилеге, алдан исәпләп куюлары, нәкъ кирәкчә, китапча үз-үзен тотышлары — болар барысы да турыдан-туры әйтеп сөйләнелә. Бәхетгәрәйгә килгәндә, Зөһрәнең аны яратуын төшенер өчен бер генә купшы деталь да ярдәм итми, аның башкортча җәенке бите, кара чәчләре, елтыр күзләре, хәйләле елмаюлары — берсе дә аны Нәҗиптән өстен чыгармыйлар. Ә кызның шушы кешене үзенең йөрәгенә якын алуы укучыны тәмам аптырашта калдыра. Дөрес, без Бәхетгәрәйне әллә нинди куе сүзләр белән матурларга, күкләргә чөеп мактарга, ул хис кешесе бит, ул әнә сугышка китте, анда да илнең зур ышанычлы кешесе булган, Зөһрәгә сәламне военком аша гына тапшыра алган, бу факт үзе генә дә күп нәрсәләр хакында сөйли диярәк бәхәс кора алабыз. Гадәттәгечә, Нәҗипнең сугыштан бронь белән калуын да хупламыйбыз. Мондый бәхәс корылганда, Бәхетгәрәй, әдәби герой буларак, күз алдында зурая барачак һәм тиздән күңелләребез аның үзе һәм эше белән сокланугa тулачак.

Зөһрәнең Бәхетгәрәйне йөрәк сере итеп сайлавы, югыйсә, ни әти-әнисенә, ни үзенә бәхет китерми. Әйтергә мөмкин: ахырдан алар бергә булдылар түгелме соң? Әнә аны Зөһрә ничек ярата, һәр көнне аңа шалтыратып тора, сагынуын әйтә! Тагын ни кирәк инде, диярбез! Әлбәттә, башка берни дә кирәк түгел. Авторның безгә әйтергә теләгән төп фикере аңлашылып тора, әсәрнең идеясе дә шушы дип, Ә.Еникинең үзенә кадәр яшәп иҗат иткән язучылардан берни белән дә аерылмавын, бары тик матур итеп җөмләләр төзү осталыгына хәйранлыкта

үзебезне бәхетле тоячакбыз. Әмма без барыбыз да бу әдәби феноменның осталык үзенчәлекләре бик күп төрле икәнлеген белеп торабыз, аның һәр әсәре, бриллиант кашлы йөзек сыман, идея нурланышын йөрәкләрдә калдырып, кайтара-кайтара уйлата, кайтарып-кайтарып укыттыра. Бары тик бик ялкау җаннар гына, аның иҗатыннан ләззәт алып та, алардагы геройларның язмышы хакында уйланулардан баш тарталар, «сер эчендә сер» барлыгын төшенеп, икенче яки өченче кат укып чыгарга да теләк тапмаячаклар. Әйе, Ә.Еники — рәхәт итеп язучы, аны кабат укуы, беренче укуыңа караганда, ләззәтне күбрәк һәм артыграк бирә. Бу хакта ничә кешедән ишеткәнебез һәм үзембезнең дә ничәмә тәҗрибә кылып караганыбыз бар.

Ә.Еникинең әдәби героеның концепциясе, әсәрләренең эчтәлеге сыман, шиксез ачык аңлашылып торалар кебек. Әсәрдә кем макталса һәм өстен чыгарылса, аның шул герое яхшы, кем кире кагылса, хәтта бик яхшы сыйфатлар иясе булуына карамастан, шул герой — кире, начар. Нәкъ шушы күзлектән караганда, акыллы, тәрбияле, тәүфыйк иясе, бик яшьли зур заводның баш инженеры дәрәҗәсенә лаеклы булган зыялы татар егете Нәҗип — коры, начар кеше, кире герой, ә менә күкрәгендә «Кызыл йолдыз» ордены булган, бер-ике очрашудан Зөһрәне үзенеке итә алган башкорт егете Бәхетгәрәй — хисле, яхшы кеше, уңай герой. Мондый әдәби герой концепциясе безне аптыраштa калдырырга тиеш түгелмени? Әллә авторның шушы корама концепцияне сайлап алуында берәр сер бармы?

Һич онытырга ярамый: әсәр татарның иң затлы авторларының берсе тарафыннан иҗат ителгән һәм ул әдәбиятта беркатлылык күрсәткән әдипләребездән түгел. Аның акылына татар тарихы, аның затына татар акылы сыйган һәм бүгенге көндә дә ул шәхескә хатирәләребездә соклану белән яшибез.

«Йөрәк сере» Идриснең күзаллавында гүзәл ханым Зөһрәнең сурәте яңартылу күренешләре белән дәвам итә бара. Аларның берсе — ир кеше, үз хатынын сөйми, икенчесе — хатын кеше, үз ирен ярата. Икесен дә бәхетләре санаториеда очраштыра. Алар дуслашып та китәләр. Зөһрәнең Идрисне гашыйк иттерүен укучы әсәр башында ук аңлап та, белеп тә өлгерә. Героиняның алга таба портреты күзалландырыла башлый. Әл-

бәттә әлегә Идриснең кемгә, ни өчен, нинди кешегә гашыйк булуы, нидән шулай аһ та ух килеп янып көюләре укучы өчен кызыклы. Автор детальләрне ачык итеп тасвирлаулар, аларга алга таба яңаларын өсти барулар, вакыйгаларны кайта-кайта искә төшерүләр белән укучы күңелендәге кызыксынуларны тулысынча канәгатьләндереп яза. Бер генә тапкыр яки берничә кат кабатланып, яисә өстәп кенә дә түгел, бәлки әсәрнең ахырынача Зөһрәнең портретына аеруча зур әһәмият биреп эш итә. Башка әсәрләренә дә хас бу үзенчәлек «Йөрәк сере»ндә, «Матурлык» хикәясеннән аермалы буларак, бүтән төрле әдәби концепциягә хезмәт итә кебек тоела. Әмма монда да тойгылар шул ук эчке матурлыкны тышкы гүзәллеккә әверелдерүче көчнең тәэсирен бәянләп бирүдән гыйбарәт вакыйгалар сурәтләнелә. Концепциясе шул ук, әмма мотивлары башка, чөнки «Йөрәк сере»ндә героиня тышкы яктан да бик чибәр.

Автор Зөһрәнең портретын беренче сызыкларында болай итеп тасвирлый: «Дулкынланып иңбашына төшкән аксыл чәчләре һәм аяк йөзенә җиткән эре чәчәкле күк атлас халаты белән ул әллә каян ук балкып күренә». Сүз ханымның санаторие бинасының өченче каттагы, кырыйдан дүртенче балконда торып, диңгез өстенә кояш баешын сокланып каравы турында бара. Әйе, ул чор татар күңеле сөя торган төсләрне уйнатып ала автор.

Зөһрәне Идрис ашханәгә кергәнендә күреп кала. Ханым аннан чыгып килә. Йөзгә-йөз диярлек очрашалар. Ә.Еники вакыйганы болай тасвирлый: «Юл бирдем, янымнан гына җыйнак-сылу гәүдәле ханым үтте, нәфис бер хуш ис сизелер-сизелмәс кенә борыныма бәрелеп үткәндәй булды, һәм сирень төсендәге ефәк күлмәгенең чак кына гыжлавы ишетелеп калды». Инде укучы шушы детальләүдән Зөһрәнең буй-сынын, күркәм киемле, затлы ханымнардан икәнлеген хис итәргә өлгерә. Яшен дә беләсе килә. Автор укучыны зарыктырмый, аның тойгыларын аңлап, алар белән идарә итә белеп яза: «Ханым утыз-утыз өчләр тирәсендә булыр. Ак чырайлы ул, чәчләре дә кылган төсле аксыл, әмма шома түгел, ә күпереп, дулкынланып, артка ятып тора. Кашлары нечкә, чәченә караганда шактый то-

нык... ә менә күзләре ни төсле —ерактан күрә алмыйм. Әлбәттә, я зәңгәр, я соры булырга тиеш...»

Автор махсус рәвештә әсәр герое Идрисне, укучыны да ымсындырып, ханымның күзләренең төсе хакында икеләндертеп сөйләтә. Ул укучыга ханым белән ирнең үзара күзгә-күз карап торуларын да белдерергә тели, шунлыктан күзләрнең төсенә махсус игътибар юнәлттертеп, аралары бик якын да түгеллеген шушындый детальләр ярдәмендә, әдәби осталык кысаларында сурәтли. Бу деталь үзе генә дә Идрискә карата ышану хисен арттыра, ханым белән кызыксыну хисен дә тудыра. Әдәби героена карата укучыда ышану хисен тудыру исә — Ә.Еники әсәрләренә хас герой концепциясенең төп үзенчәлекләреннән булып тора. Әгәр дә әдәби герой ышандырырлык түгел икән, ул вакытта ясалмалык өстенлек ала.

Әйткәнебезчә, «Йөрәк сере»ндә Ә.Еники бик баналь бер вакыйганы сөйләргә җыена һәм моның шулай булуын үзе дә яхшы аңлаганын әсәр тукымасында укучыга берничә тапкыр сиздерә, әгәр дә тасвирланган төп герое да баналь тоннарда гына булса, повесте бөтенләй уңышсызлыкка дучар ителәчәген автор тойган, билгеле. Шул сәбәпле әдип бу әсәрендә герой концепциясен үз күңеленә, мораленә, дөньяга карашына һәммә яктан туры китереп төзүгә алына.

«...Төз аякларын берсе өстенә берсен куеп, кулына кечкенә кара ридикюль тотып, ул уйчан-тыныч кына утыра. Бөтен килбәтеннән үз дәрәҗәсен яхшы белгән масаюсыз табигый горурлык сизелеп тора»,— дип тасвир итә автор шушы героинясын, Зөһрәне.

Ханым ашханә ачылуны көтә. Кичке вакыт.

Идрис аңа карап, күзәтеп тора.

Ә.Еники Зөһрәнең сугыш башланган елны унсигездә булуын әсәрдә алга таба берничә кат үзеннән әйттертә, ә хәзер аңа утыз-утыз өч яшьләр. Димәк, вакыйга 1950 нче еллар башында булган, Бөек Ватан сугышыннан соң әллә ни гомер дә узмаган икән.

Зөһрә белән Идриснең «очрашулары» вакыйгалары әсәрдә дәвам итә, алар инде исәнләшә башлыйлар, ә врач кабинеты ишеге төбендә утырганда сөйләшеп үк китәләр. «...Йөрәкнең

акрын гына кысылып, ләззәтле авыртуын тойдым,— дип исенә ала әсәрдә Идрис.— Гаҗәеп, нидән бу? Ханымның матурлыгы мине шулай яшүсмер кебек дулкынланырга мәҗбүр итәме?»

Мондый уйлары аның тәмам беркатлыгыннан килә икәнлеген автор укучыга яшерми ача. Мондый сурәтне әдипнең үзенең дә тирән эчтәлекле геройны иҗат итмәвеннән килә диярәк тә бәяләргә мөмкин. Әмма автор аны үзенең герой концепциясенә туры китереп шулай эшли. Укучы инде әллә кайчан Идриснең Зөһрәгә гашыйк булганлыгын төшенеп өлгерсә дә, Идрис үзе — юк әлегә. Һәм менә укучы күңеле Идрискә: «Гашыйк булгансың бит, юләр!»— дип пышылдый, хәтта аңардан үз итеп кенә көлә, әмма бу аның ачы көлүе түгел, бәлки үзенең акыллы булуын тоюдан, ләззәтле вакыйгалар агышына кереп чуму рәхәтлегеннән кытыклануы гына. Шушы рәвешле укучы, әсәрне уку дәвамында, әдипнең герой концепциясенә тәмам бирелеп, берегеп, ярәшеп китә, хәтта аны үз итәргә, аңа берничә «сабак бирергә» өлгерә. Бу чара укучының үзен үк беркатлыландыруга, аның хәтта үз рухы тантанасына ирешә баруына ярдәм итә.

«...Әйе, сүз дә юк, ул чибәр иде,— дип искәртә тагын автор, Идрис исеменнән сөйләп, шушы гомуми тасвирны интим детальләр белән куертып җибәреп.— Якыннан аның йөзе бик чиста, тик кечкенә колакларыннан түбән яңак сөяге читендә ак мамык төкләр күзгә чагыла. Ләкин алар аңа бик килешәләр кебек, ничектер аны йомшак итеп, мөлаем итеп күрсәтәләр. Аз гына кайтарылып торган алсу иреннәре дә аның йомшак кебек, бик саф кебек, дорфа-ямьсез сүз әйтә алмый кебек... Алкаланып колак артларына төшкән куе аксыл чәче дә, ап-ак муены да, хәтта аз гына җәенкерәк борыны да — барысы да аңа тулаем бер сөйкемле йомшаклык биреп тора кебек». Сүз дә юк, ефәккә төренгән ханымны Ә.Еники шушылай бөтенләй дә асылташка әверелдерә. Хәер, башкача бәянләсә, Идриснең «колактан ашып» гашыйк булуының сәбәбен ничек искәртергә, укучыга җиткерергә мөмкин? Мондый сурәтләр идиллиянең күркәм мисалларыннан түгелләрмени?

«Йөрәк сере»ндә алга таба Ә.Еники Зөһрәнең портретына бәйле һәр детальне аның табигатен һәм холкын ачыклар өчен

файдалануга күчә бара, шуның белән героеның тышкы һәм эчке сыйфатларында уртаклыкларны укучы да җиңел таный. Йомшак табигатьле бу ханымның «тик күзләре генә икенче төрле тәэсир калдыра,— дип яза ул,— кашларының, чәченә караганда, коңгырт булуы, керфекләренең озын һәм кара булуы, аның зәңгәр күзләрен караңгылап торган шикелле, һәм күләгәгә яшеренгән бу күзләр кешегә каядырерактан сагаеп-сагаеп карыйлар кебек...»

Хисләренә бирелгән Идрис бу ханымның күңелендә сер барлыгын чамалый, ул аны «ачылмаган чәчәк бөресенә» тиңли. Хәтта: «Әгәр ачыла калса, күңел күптән сагынып эзләгәнен табар төсле...»— дип тә укучыга белдерә. Кайвакытта Зөһрә Идриснең күзенә чалынмый, әмма ир аны һаман эзли, таба. Өч-дүрт көннән соң очрашулары шул ук бакчада, эскәмиядә була. Алар «иске танышлардай» сөйләшәләр. Монда да автор Зөһрәнең портретына укучыны игътибар иттертә: «Әйе, аның өстендә бик гади генә итеп тегелгән, ачык изүле, кыска җиңле яшел күлмәк иде. Күкрәге өстендәге кечкенә кесәсенә ак ефәк кульяулыгын төртеп кенә куйган... Бүтән берни дә юк. Тик сул кулының атсыз бармагында кызыл якут ташлы алтын йөзеге бар икән... Әйе, һаман шулай аксыл чәчләре алкаланып йомшак ак муенына төшкән, һаман шулай кара керфекләре зәңгәр күзләрен күләгәләп торалар...» Автор, шушы рәвешле сурәтләп, гүяки героинясын шактый гына матди байлыкларга ия кеше буларак та күрсәтергә тели, әмма кешечә гадилеген дә ассызыклый. Шулай да ханым аерылып та тора икән: ул башкалар кебек диңгезгә су коенырга йөрми, төрле уеннар белән дә мавыкмый. Тыныч һәм сабыр холыклы. Мишәр кызы икәнлеге дә, Чиләбедә үсүе, Ульяновски шәһәрендә телефон челтәре инженеры булуы да тиз беленә. Ул боларны Идрискә яшерми әйтеп бирә.

Ханымның көлү тавышы да ирне сокландыра башлый, «болай көлү гадәттә эчкерсез балаларга гына хас була» дип нәтиҗә дә чыгарыла. Һәм шулар ярдәмендә Зөһрәнең Идрискә карата мөнәсәбәтенә дә ачыклау кертелә: «Ачык, аңлаешлы, якты бер кеше булып тоелды ул миңа. Ничектер җиңел, рәхәт иде аның белән сөйләшүе. Гаҗәп табигый итеп тота икән ул

үзен. Күп хатыннар шикелле, укам коела күрмәсен дип, бер дә юкка һаваланып маташмый икән».

Шушылар әсәрдә мәхәббәт уенына корылган «курорт романы» бәян ителәчәгеннән хәбәр буларак укучыга аңлашылырга тиешләр, югыйсә. Җитмәсә Идрис үзенең гашыйк булуын яшерми сөйли, мәхәббәт хакында фәлсәфә сата, кыю адымга барырга, ханымга йөрәгендәге серен ачып бирергә дә теләгендә бар. Әмма тагын берничә көн уза. Алар очрашмый торалар.

Идриснең, көчле хисләргә бирелеп тә, кыю адым ясый алмавы, пошмаслыгы, вакыйгаларның бернинди үзгәрешсез калуы әсәрне укырга авырлаштыра, билгеле. Андый урыннарда Зөһрәнең чибәр сурәтенең яңа детальләр белән тасвир ителүе шул караңгылана барадыр тоелган тормыш картиналарына кояш нурлары кебек яктылык сирпиләр. Бу исә авторның алга вакыйганы түгел, геройны чыгаруын тагын бер кат расларга булыша.

Кыяфәте укучыга билгесез калган «төссез» Идрис, һәммә төрле буяулар белән купшыландырып бирелгән Зөһрә белән чагыштырганда, бөтенләй башка концепциягә корылган. Берничә детальне исәпкә алмаганда һәм алардан чыгып фикер йөртмәгәндә, аны бәяләп тә, аңлап бетереп тә булмый. Идрис бары тик, З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романындагы шымчы Шубин кебек, авторга вакыйгаларны ачар өчен ярдәмче образ ролен генә үти түгелме? Әмма шунысы да бар, Шубин кебек ул актив геройлар рәтендә карала алмый, бәлки, киресенчә, Зөһрәнең хәлләрен аңларга ярдәм итүче, аңардан вакыйгаларны сабырлыгы белән сөйләтүче буларак кына әсәрдә катнаша. Хәер, идиллияле хатирәләр йомшак рәхәтлек эчендә булырга тиешләр. Әдәбият өчен мондый тасвир, андый герой концепциясе яңалык та түгел. Әмма аның сөйләнелгән вакыйгаларга мөнәсәбәте әсәр мораленең нигезен хасил итә. Герое авторның фикеренә каршы да килергә мөмкин, туры да килә ала. Мондый герой язучыга үз фикерен яшерергә яки ачык белдерергә мөмкинлек тудыра, шул сәбәпле аның әдәби әһәмияте җиңел бәяләнә.

Әсәрдә югалып торган герой, бераз вакыт узуга, кабат күренүгә, тагын аның килеш-килбәтенә укучыны игътибар ит-

тертүдән соң, аңа бәйләнешле вакыйгалар тезмәсе башланып китә. Шушы рәвешле язу Ә.Еникигә героен искә төшерергә дә, башкалары белән бутамаска да, характерлап бирергә дә ярдәм итә. Күп очракта язучылар геройларының портретын исәпкә алып тормыйлар, аларның килеш-килбәтләре дә ачык искәртелми, шул сәбәпле кемнең кем икәнлеге дә төгәл күз алдына килми. Бу, әлбәттә, әдәбилеккә хилафлык китерә. Ә.Еники, киресенчә, әсәр геройларын укучы мөмкин кадәр тулырак итеп күз алдына китереп бастырсын өчен, аерым тырышлык күрсәтә. Аның максаты — герое танып беленергә тиешле. Шушы портретларны бирүе белән генә дә ул геройларын реаль тормышта яшәүче кешеләр итеп күзаллауны укучы күңелендә барлыкка китертә, моның белән әсәренең тәэсир көчен арттыра.

Берничә көннәр узуга, Идрис, мәсәлән, Зөһрәне тагын да мондый сурәттә очрата (бу иртәнге вакыт була): «...Паркның төп аллеясы буйлап Зөһрә ханымның каяндыр кайтып килгәнен күрдем. Бик гаҗәпләндем мин бу хәлгә. Күзләремне ала алмыйча, аны көтеп тора башладым. Өстендә аның халат өстеннән генә кигән жакет, башында ияк астыннан китереп бәйләнгән шакмаклы йон косынка иде. Килеп җиткәч, ул миңа «хәерле иртә» диде, бит урталары аның кызарган иде, гадәттә күләгәләнеп торган күзләре, чык бөртегенә нур төшкәндәй, куанычлы елтырыйлар иде, ашыгып килгәнгә, ахрысы, түшләрен тибрәтеп, тирән сулый иде». Боларда Зөһрәнең инде ничәнче тапкыр киемен алыштырганлыгын, нинди шатлыклы хисләр кичерүен, Идриснең аңарга карата йөрәк җылысы белән эретелгән яхшы мөнәсәбәтен, ханымның үзенең дә тирән хөрмәтен — барысын-барысын берьюлы тоябыз. Ул шулай булырга да тиеш. Әдәби сурәт тормышны төрле яклап яктырту гына түгел, укучы күңелен дә шул тормышны полифоник яңгыраштa кабул итәргә этәргәндә генә уңышлы була. Шунысы кызыклы, Ә.Еники тасвир кылган бу күренеш-портретта бер генә ачык билгеләнелгән төс бар, ул — «бит урталары аның кызарган иде» дигән сүз-сурәттән гыйбарәт. Ханымның халаты, йон косынкасы, күзләре, башкасы — берсенең дә бу вакытта ачык бер төсе күрсәтелмәгән, алар әһәмиятсез калдырылганнар.

Язучының әдәби максаты аңлашылып тора: укучыны Зөһрәнең бит очларына игътибар иттертү, шуның белән гаҗәпкә дә калдырырга теләү. Идриснең бу күренешкә мөнәсәбәтен язып узу белән бергә соклану хисе тагын да көчәйтелә.

Зөһрә әллә кайдан түгел, почтадан кайтып килә икән. «Карты» белән телефоннан сөйләшкән.

Әсәрдә алга таба Зөһрәнең көлү авазлары тагын да калкурак итеп алга чыгарыла. Идриснең хәтерендә автор аны төрлечә яңарта: мәсәлән, «шундый сихри итеп ханым бер көлеп куйды да ашыгып вестибюльгә кереп тә югалды», яки, «Зөһрә ханым ничек итеп көлде! Кошлар сайравына биргесез иде бу көлү!.. Гүяерактан үзенә чакырып торган сихри бер өн ул!» һ.б.

Идрис Зөһрәгә инде өметсез гашыйк була. Аларның бергә «Дендрарий» паркына барулары, бу бакчаның тарихчасы, агава агачына бәйле риваять — болар барысы да укучыда тирән дулкынлану тудыралар.

Алга таба вакыйгалар Идриснең Зөһрәгә мәхәббәтен ничек тә аңлатырга тырышуы белән бәйле. Әмма турыдан-туры әйтсә, ханымның хисләрен кимсетер сыман. Хәер, Зөһрә аны ярты сүзеннән аңлап ала һәм мәхәббәтен дә кире кага. Ә бу кире кагуны ул да үпкәләтерлек рәвештә әйтергә теләми, Идрисне хөрмәт итүен, аңа мөнәсәбәте дә яхшы булуын искәрткәч, «кызыклы бер тарих» сөйләргә, ягъни «башыннан кичкән мәхәббәт тарихын» бәян итәргә була. Аңлашылып тора, Зөһрәнең ни әйтергә теләгәне шушы тарихка яшерелгән. Димәк, анда әсәрнең эчтәлеген ачарга тиешле мәгънәле киная бар. Бу «тарих»VIII бүлекле повестьның VII-VIII бүлекләрендә сөйләнелеп бирелә. Зөһрә аны берничә көн дәвамында, кичен-кичен, кисәкләп кенә Идрискә, Идрис — укучыга җиткерәләр.

Ә.Еникинең геройлары күңелләре түрендә саклanган һәм әйтергә теләгән төп теләк-сүзләрен бервакытта да турыдан-туры әйтеп бирмиләр, бары тик кинаядә, метафорик планда белдерәләр. Зөһрә дә шулай эшли. Хәер, бу повестенда башка геройлар да шушы хәлдә. Әмма монда Зөһрәнең сөйләгән «тарихы» әһәмиятлерәк тоела. Шуны аңлап, әсәрнең идеясен дә укучы шуннан эзли. Хәер, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәне дә

нәкъ шулай эшләгән[1]. «Йөрәк сере»ндәге VII бүлеккәчә сөйләнеп киленгән вакыйгалар бөтенләй дә исәпкә алынмыйча калдырыла киленгән. Шунлыктан Ә.Еникинең бу әсәренә бүгенге көнгә кадәр өлешчә генә анализ бирелгән дияргә тулы хакыбыз барлыгын төшендерү авыр түгел.

Димәк, «Йөрәк сере» повестенда авторның укучыга җиткерергә теләгән идеясе әсәрдәге төп героиня Зөһрәнең Идрискә мөнәсәбәтенә, Идриснең исә Зөһрәгә булган якты хисләренә бәйле. Ханым тарафыннан сөйләнелгән үз мәхәббәте «тарихы» исә шушы бәйләнешне аңлар өчен китерелгән әдәби иллюстрация ролен үти. Нәҗип кебек егетне дә үзенә лаек күрмәгән Зөһрә, уйлап караганда да аңлашыла, Идрискә үзенең йөрәген багышлый аламы? Юк, әлбәттә. Идриснең драмасы Нәҗипнеке белән аваздаш.

Ә.Еники башка әсәрләрендә дә «сер эченә серне» шулай яшерә белгән. Ул әдәбиятка менә шушы рәвешле, кинаяле геройларны биреп, яңа герой концепциясен алып килгән һәм шушы рәвешле әдәби-тарихи процесска яңа үсеш этәргече биргән әдип булуы белән дә кызыклы.

*Февраль, 2009.*

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ИРОНИК РЕАЛИЗМ

*(Камил Кәримовның «Ком сәгате» романы уңаеннан)*

### I

Камил Кәримовның язучы буларак әдәби теле һәрвакыт аерылып торды. Ул төртмә кебек тә, уйнаулы уйчан сыман да, бәяләүче дә, үгетләүле дә кебек тоела. Әмма боларның барысын да бергә кушканда гына бу тел аңлашыла башлый. Кемнәрнеңдер матур дип саналган теле җилләр белән бергә кырлар-болыннар аша йөгереп әлсерәтсә яки Париж, Рим,

---

[1]***Карагыз:****Сверигин Р.Х., Хатипов Ф.М.* Әмирхан Еники // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.6.— 60-90 еллар әдәбияты.— Казан: “Раннур”, 2001.— Б.111.

Каһирә, Истанбуллардагы биек манараларга уралып йөреп, инде дә тау сыртларына бәрелеп китеп, чәчләрне сыйпап үткәндәй хис калдырса, К.Кәримовныкы бөтенләй башка, ул күңел идәненә коелган эре борчакларны хәтерләтә, ул борчакларның кайда таба сикерәселәрен, маңгайгамы, башка җиреңәме бәреләсен-чиртәсен белеп тә бетереп булмый. Бу — ирония теле, мактаучы, аркадан сыйпаучы һәм кемлегеңне ачык белдерүче бәяле һәм бәһале тел. Ә ирония теле ул — бик тә җитди итеп, әмма «астан» кистереп сөйләүче көлке теле.

Бөтен иҗаты буенча К.Кәримов шушы тел белән яшәде, аны укучысына тәкъдим итте, эндәшми торганында — сагындырды, күп сөйләп ташлаганында — куркуга салды. Укучысы аны иң тәүдә менә шушы теле өчен яратты. Аны юмор теле дип белде. Бу яктан К.Кәримов классик әдипләребездән Ш.Мөхәммәдов, З.Һади, М.Әмир, М.Мәһдиевләрнең данлыклы дәвамчысы булды.

К.Кәримов әсәрләрендәге тел сөйли, әмма сөйли белеп кенә, күп түгел, бераз гына сөйли. Сүз борчаклары сикерешеп-сикерешеп кенә куялар. Ә аннары шул сүзләренә нәтиҗә итеп язучы бер җөмлә бирә, ул яки чеметтерә, яисә яңа сүз башламына тема ача. Аның «Ком сәгате» дә шушы формага көйләнгән. Бу кадәр дә ашкынулы тел башкача хәрәкәт итә алмый, нәтиҗәдә вакыйгалар озынга сузылудан имин кала.

Кайбер язучылар әсәр эчендә тематик үстерелешне тәэмин итә алмыйча интегәләр. Бу бәладән котылу өчен аларга К.Кәримов әсәрләрен уку, форма-стильдә аның өлгесенә тартылу шактый зур файда бирер иде.

Ироник тел башкача була да алмый. Анда һаман да сүзләр ниндидер бер ашкынулы ләззәт җебенә теркәләләр. Алар өзелеп калганда, инде икенчесенә күчәргә язучы каләме өлгерә. Бу тел сурәт матурлыгын тудыра. Күп вакытта аның артыннан җитешеп тә булмыйдыр, уйлап, нәтиҗә ясарга да мөмкин түгелдер сыман. Әмма К.Кәримов монда да үзен чын мәгънәсендә әдип итеп күрсәтә, укучысының зиһен мәйданына бер төзек җөмләле фикер берәмлеге ташлап калдыра, аны үзлегеңнән дәвам иткәнеңдә, нинди нәтиҗәгә килергә мөмкинлегеңне белеп торасың. Ул үз уе белән безне аптырат-

мый, аны укучыга көчләп тә такмый. Әмма нәкъ К.Кәримовча фикерли башлыйсың. Аны шуның өчен дә фикер остасы дияргә тулы нигез бар.

К.Кәримовның берничә җөмләсенә генә игътибар итик. Махсус сайлап алып түгел, очраклы рәвештә теләсә кайсына тукталып карыйк. Менә Мәдияр белән Фазыл исемле каһарманнары кич клубка чыгалар. Фазыл, актан киенеп килгәненә күрә, ятсыну хис итә. Вакыйга Актаныш төбәгендә бара. Мәдияр аңа болай ди: «Актаныш кызлары — деликатес алар!»

Әдипнең каһарманнары да ироник телле. Бу тел белән болай да һәр авылның яшьләре һәм өлкәннәре сөйләшәләр. Язучы бу телне халыктан «алган». Турыдан-туры күчереп түгел, билгеле. Үз күңеле аша уздырып.

Татар — төртмә телле халык. Күрше белән күрше иртә таңнан шушы К.Кәримовтагычарак ироник тел белән сәламләшмәсә — яши алмый. Кемдер бу телне күтәрә ала, кайсылардыр — юк...

Тагын да очраклы гына, ягъни махсус сайлап-сайланып тормыйча тукталган сәхифәгә күз салсак, күрәбез, К.Кәримов алга таба болай яза: «Башта егетләр сәгате суга, аннан соң кызларныкы... Хәер, яшь чакта шулай ул... Ә өйләнгәч, хатыннарның сәгате алга китә, ирләрнеке гел артка кала...» Бу юлларны укыганда укучы әллә ничә төрле уй эчендә йөзә. Сүз борчаклары коелган, алар күңел идәнендә сикерешкәннәр. Автор нәрсә турында әйтте әле дип, символларның мәгънәләрен эзләп аптыраш юк. Алга таба укуыңны беләсең: «Егетләр, Кырлай бүреләре кебек, якты клуб учагын ташлап, берәм-берәм Карурмандай кара урамга шыла тордылар».

Менә бит ничек! Монда Г.Тукайның «Кәҗә белән Сарыгы» да, татарның «Карурманы» да аһәң биреп ала. К.Кәримовны аңлар өчен татар булып туарга кирәк, анысы хакында сүз дә юк. Җитмәсә, кызлар белән боткалары пешмәсен аңлаган егетләрнең, «Кәҗә белән Сарык» бүреләре кебек, берәм-берәм качуларын карагыз инде!

Ә вакыйга дәвам итә, әлегә әсәрнең беренче сәхифәсе дә ябылмаган, ә Мәдияр белән Фазыл инде кызлар озата киләләр.

«Алар өч чакрымлы юлның икенче яртысын таң атканчы кайттылар. Төннең тәхетеннән төшкәненә сөенеп, хуҗасыз этләр өргәне ишетелә. Сәер дә тиз үтте бу төн! Төн кичмәделәр, ә юл уңаеннан барганда, бер күләгә аркылы гына атлап чыктылар гүя...»

Һәм сез дә кушылырсыз: никадәр тасвир, никадәр күзәтүчәнлек һәм фикерли белү, тел белән эшләү осталыгы! Истә дә кала. Әмма бу сурәтләр җәелеп ясалган акварель буяулардан гыйбарәт түгел, алар төртмә-төртмә рәвештә, майлы буяулар тыгызлыгы белән бирелгәннәр. Җитмәсә ирония алардан аңкып тора. Ни сокланырга, ни чырай сытарга өлгермисең.

Бу ирония теле коры тел түгел шул. Һәр сүзләр тезмәсенең өске һәм аскы агымы бар. Ирония ул көлдерми, аның максаты бары көлкегә калдыру гына. Әмма ул мактап, зурлап, чөеп, күкрәкләрне киерелдереп көлкегә калдыра. К.Кәримовның каләменнән «коелган», инде синең күңел бүлмәңнең идәнендә сикерешкән сүз борчакларының берсен булса да тотып алырга дип хәтерең иелергә өлгерми, аның икенчесе маңгаена чиртеп ала. Зиһенне ирония дә нәкъ менә шулай сугара, сафландыра.

Дөрес, безнең борчаклар турында фәлсәфә коруыбыз хакыйкатьнең һәммә ягын да ачып бетерә алмый. Әмма ул бәяныбызның асыл нигезе дә бар, чөнки К.Кәримовның әдәби тел җәһәтендәге осталыгын азмы-күпме ачып бирергә ярдәм итә ул. Әгәр дә башка төрле символлар табып, кем дә булса әдипнең язу үзенчәлеген ачык аңлата ала икән, рәхим итсеннәр, ризалашырбыз кебек. Ә К.Кәримовның «сүз борчаклары» шытканрак килеп чыгалардыр сыман.

## II

Ком сәгате дигәндә, «үзара нечкә көпшә белән тоташтырылган ике пыяла савытчыкның берсеннән икенчесенә билгеле бер вакыт арасында ком коелып тора торган прибор»[1] күздә тотылуын хәбәр итә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге». К.Кәримовның «Ком сәгате» романында ул үзенең туры

[1] ***Карагыз:*** Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда.— Т.II.— Казан: Татар.кит.нәшр., 1979.— Б.138.

мәгънәсендә дә катнашып ала, ягъни су бораулаучы эшендә кирәкле җиһаз икән ул ком сәгате.

Шул ук вакытта ул символик мәгънәгә дә ия. «Ком сәгате» геройларыннан Фазыл гомере буе су бораулаучы булып эшләгән, менә аны илле яшендә пенсия чыгарганнар, язмыш сәгатенең комы колба-савытчыкның бер ягына агып беткән. Ул аны икенче башы белән әйләндереп куя. Ком яңадан ага башлый. Бу гади агым түгел, бу аның язмышының кабатлануы кебек килеп чыга. Фазыл үзе узган барча төбәкләрне кабат әйләнеп чыгарга тиеш. Аның һәр су скважинасы бораулаган авылында кемедер калгандыр сыман. Алар агайның якты истәлеге. Бу истәлекләр бер-бер артлы кабатланачагын укучы да аңлап өлгерә. Фазыл үзенә су бораулаучылар вагонын ала, шунда яшәргә ризалык итеп, шул вагон белән сәфәргә чыгып китә. Һәр тагып барган машина шушы яшел вагонны кайсы да булса бер авылга илтеп куячак. Бу — әсәрдән көтелгәне, фабуласының мантыйгы. Моның белән әсәрнең өлгесе күзаллана. К.Кәримов шушы өлгедә романын ахырынача җиткерергә тиеш кебек. Әмма әсәрдәге вакыйгалар барышы укучы алай җиңел генә күзаллаганча булып чыкмый. Яшел вагон Шәле авылына якын юл янында тукталып кала. Геройның хатирәләре генә «сәфәргә чыга». Шушы рәвешле автор укучы күнегә башлаган фабулага үзгәреш кертә һәм әсәрен тулы ике өлешкә аерып куя. Аның бу «ачышы» фабулага зыян итәдер сыман хис туа, әмма автор моны билгеле бер максатларда эшләгәндер дигән уйга килергә мәҗбүрбез. Талантлы һәм тәҗрибәле әдип юктан гына «мөгез чыгару» юлына басмый түгелме соң?

Фазылның яшәеше-тормышы сәер. Ул өйләнгән булган, баласы үсә. Эшләгән акчасын да аларга биреп бара, фатирын да шуларга калдырган. Ә ул үзе кебек су бораулачылар рәтендә, әсәрдә әйтелгәнчә — зимагор. Аның авыл саен сөяркәсе була ала. Укучы да әсәрдән шуны көтә. Менә «Ком сәгате»нең Дон-Жуаны шул сөяркәләренә сәфәр чыкты инде, дибез. Ә юк икән шул.

Автор әсәренең башында ук укучыны татар Дон-Жуаны маҗаралары белән мавыктырып алган иде түгелме соң?

Фазылның Казанда Зөмәйрә белән кич кунып чыгулары, ул бүлекнең дә «Зөмәйрә» дип аталуы шуңа ышандырмадымы?

Авторны татарның замана Дон-Жуаннары бөтенләй дә кызыксындырмый икән шул. Вакыйгаларның барышы башка бер үзән белән ага. Актаныштагы Аккүз авылында калган Әлфинәне Фазыл утыз ел буе сөйгән. Алар кавышмаганнар. «Ул кызны күргән кеше утыз елны күпсенмәс»,— дип әйтеп куя Фазыл. Һәм ул укучыны ышандыра да. Әмма шик тә бар. Роман җиде бүлеккә бүленгән. Алар һәммәсе дә төрле хатын-кыз исемнәре белән аталган, ул бүлекләр тагын да бүлекчәләрдән тора һәм сурәтләнеләчәк вакыйгаларга бәйле исемләнгәннәр. Ул хатын-кызларның һәммәсе белән дә Фазыл йөреп-сөешеп чыгар сыман. Ә юк икән шул. Аларның берсе — Динә — Фазылның энисе.

Хәер, темадан киткәнче, дигәндәй, искәртеп үтик: «Ком сәгате»ндә татар Дон-Жуаны да бар, ул — пилмән бәбәкле Фәрит. Автор аның хатын-кыз итәгенә ябышырга гына торуын бик яхшы итеп ачып бирә. Фәритне укучыларына авылга килгән «командировка» хезмәткәрләре арасында таныштыра язучы. Аннары бу егетебез, Актанышка машина белән йөк ташучы сыйфатында килеп, мунчага хатын-кыз артыннан кереп тотылган, унбиш тәүлеккә хулиганлыгы өчен утыртылган, су бораучыларга туң җирләрдә сигез куб метрлы чокыр казырга мәҗбүр ителгән тоткын рәвешендә рисвай була. Шушы Дон-Жуан Фәрит образы Әмир, Фазыл һәм Мәдияр кебек үз хезмәте көченә таянып, фидакарьлектә яшәүче каһарманнарга әдип тарафыннан каршы куела.

Фазыл сугыш вакытында Шәледә көне-төне икмәк иккән Динәдән туа. Ураза вакытында хатыннар урак белән иген уралар. Су да эчәргә ярамый. Хикмәт хәсис Габдулла муллада. Ул үзе көндез йоклап, төнлә ашап ураза тотучы исәпләнелә, ә халыктан шәригать кушканны таләп итә: ураза нинди генә авыр эштән һәм эсселектән дә бозылырга тиеш түгел, имеш. Тик сорау тумыйча калмый. Ничек инде автор сөйләгән шушы «сасы мулла» көмәнле Динәдән ураза тотуны таләп итте икән? Бу кадәр үк аңарга хәсис булырга ярамагандыр бит инде! Әллә шәригать хөкемнәрен белү мәсьәләсендә мулла түгел, халык

наданмы? Көмәнле хатыннарга ураза тоту ярамый бит, әгәр алар ураза тотсалар, көферлек була түгелме соң? Шушыны да Габдулла мулла белмәгәнме? Көмәнле хатыннар уразадан азат бит алар! Ә монда — киресенчә, Габдулла мулланың хәсислеге алга чыга, Динә аның тарафыннан уразаны бозуда гаепләнелә.

Авторга бу мәсьәләне кабартып алу төгәл максатларда кирәк булган, билгеле. Ул аның ярдәмендә дин-шәригать мәсьәләләрендәге бездә хәзергәчә сакланган наданлыкны, муллаларның хәсислеген ирониягә ала түгелме? Бу вакыйганы укучы бер дә уйлап чыгарылган дип белергә теләми, чөнки иманы камил: К.Кәримов сурәтләгән вакыйгаларын тормыштан һәм нәкъ тормыштагыча ала. Бу аның иҗат кредосы. Бу аның реализмы. Әмма ул натурализм түгел. Натурализмга ук кереп китмәс өчен авторга тормыш дөреслеген ирония аша бирү ярдәм итә.

Фазыл, әсәрдәге төп геройларның берсе буларак, авыр тормышта үскән, кимсетелгән, фронттагыча батырлыкны таләп итүче хезмәттә (монысын су бораулаучылар хакында Актаныш райкомының икенче секретаре Галимҗанов әйтә), хәтта йортсыз-җирсез, ачлыклы-туклы зимагор хәлендә гомер итә. Хәер, ул гына түгел, ил белән диярлек шул хәл. Су бораулы мастеры Әмир дә шундыйлардан. Алар елына берничә тапкыр гына гаиләләрен күрергә, анысын да акча алган көннәрендә генә мөмкиннәр. Аның каравы хуҗалар дип исәпләнелгән түрәләр башкача яши, башкача гомер сөрә. Аларның хәтта сәясәтләре дә дөрес түгел. Араларында «кукуруз сәясәте»н культуралы көтүлекләр белән алыштыруда башлап йөрүче, шәрә мәкаләләр язучы министр да бар. К.Кәримов аның әүвәле кемлеген хәтта публицистик планга күчеп хәбәр итә. Ә аннары алар Актанышта очрашалар. Министр үзе белән ак «Волга»да инженер Ятманскийны алып килә. Түрәләр барысы да автор каләменнән «симез борынлы» кыяфәтләрендә пәйда булалар.

Министрның Актанышка су бораучылар янына килүе, түрә Ятманский вакыйгалары — болар барысы да, әсәрдәге башка сурәтләр кебек үк, чын мәгънәсендә ирониягә корылганнар. Әдип аларны туктаусыз күкләргә чөеп мактый, һәр әдәби

геройның артында торырга мөмкин булган һәм танылып беленүче прототипларын да, шул исәптән, иронияга ала. Ирония ул начарны юри яхшы итеп күрсәтү, караны юри ак итеп сурәтләүдән гыйбарәт. Ироник бәяләмә, сурәт, күренешне укучы әүвәле әдип язганча туры мәгънәсендә кабул итә, аннары гына, үз фикере һәм аңы аша уздырып, язылганнарның иронияга корылганлыгын, кире мәгънәгә ия икәнлеген төшенә. Министр да, әле генә язучы каләменнән рәнҗешле публицистик планда бәяләнгән герой, инде мактала. Ул бораулаучылар белән чәй эчкәндәй итә. Моны казылган кое суы дип кабул итә, аннары кар суы булуын белә. Чиркана. Әмма Актаныш кары икәнлеген искәртәләр, ул кабат йөзенә сөенеч билгеләре чыгара. Имеш, Актанышның кары аның өчен газиз, туган ягыныкы бит! Министрның шушы бер-ике сәхифәлек вакыйгада өч тапкыр кыяфәте, ничә кат йөзе, кыланышы, сүзләре капма-каршыга үзгәреш кичерә. Әмма автор теле һаман да аны мактый, олылый. Министр су бораулаучылар белән чирканмый кул бирешеп күреште түгелме? Ә ул алып килгән Ятманский ничек?

Аны министр бораулаган җир катламнарын үз кулы белән алып, тотып тикшерсен өчен бер айга Актанышта калдырып китә. Гаеп, имеш, аңарда. Су кирәгенчә һәм проектта каралганча чыкмаган.

Хәбәрдар кешеләр белә булыр: җирнең геологик катламнарын тикшерү методлары һәрвакытта да йөз өлеш дөрес нәтиҗә бирә алмый. Әлегә кадәр бер генә фәнни өлкә дә хакыйкатьне хатасыз, тулысынча белдерүгә дәгъва тотмый. «Симез борынлы» Ятманскийның, никадәр генә исәп-хисаплары, сызымнары дөрес булмасын, ялгышуы ирексездән.

Әмма әдип бу мәсьәләдә сызымчыларның сукырлыгыннан ирония тудыра һәм дөрес эшли. Әгәр дә без бүгенге фәннең уңышсызлыкларына кул чабып торсак, гыйлем-фән үзе үсешеннән туктаячак. Хәзерге фәндә шундый юнәлеш калыкты: галимнәр конференцияләрдә фәнни «сговор» (килешенү) төзиләр дә (укучыга яхшы билгеледер дип беләбез, фәлсәфә өлкәсендә бу «сговор» дигән сүз очраклы түгел, бәлки дөреслекнең килешенеп билгеләнүенә бәйле хәл ителүен

күрсәтүче термин буларак кулланыла) һәм шушыны хакыйкать итеп белдерәләр. Бу дөнья күләмендә шулай. Ул метод белән ачышларны «ясау»ның файдасы да, хатасы да бар булыр. Автор нәкъ менә шушындый фәнни сукырлыктан көләдер сыман.

Ятманскийга карата министрның мөнәсәбәте Фазылны да, укучыны да сөендерәдер кебек хис кала. Әмма асылда бу карары министрның мәгънәсез икәнлеген дә аңларга ярдәм итә. Моны хәтта бүлекчәнең ахырындагы вакыйга да раслап тора. Менә министрның кул биреп хушлашып, бораучылар яныннан китеп баруы. «Фазыл үзе дә сизмәстән, йола кушканча күрешеп: «Мин Фазыл булам!»— дип ычкындырды. «Ни хәл, Фазыл?!»— диде аңа министр»[1].

Хәл белешү хушлашканда әйтелә торган сүзмени инде? Әмма әсәрдә бу ирония тудыру өчен хезмәт итә, сүз борчагы, бөтенләй көтелмәгән якка сикереп, маңгайга китереп бәрә.

III

Ком сәгатенең, җиһаз буларак, эшләү принцибына кабат игътибар итсәк, борыннары белән үзара тоташтырылган колба-савытчыкларның берсеннән икенчесенә ком савыла, дидек. Ком бер яктан икенчесенә агылып беткәч, башаяк әйләндереп куясың. Тагын шул ук вакыт аралыгында ком савыла. Артмый да, кимеми дә.

К.Кәримовның «Ком сәгате» романында шушы ком сәгате абстракт рәвештә кулланыла, әсәрнең композициясен хасил итә. Әгәр дә игътибар итсәк, ком сәгатендә, ком савыла башлаганда, әүвәле колбаның авызындагы бөртекләре сузылып төшә, акрынлап комда воронка-борын хасил була. Аннары өске, авыздан ерак катлам коела бара. Вакыт-вакыт бу савылу тәртибе үзгәреп тә куя. Анда очраклылык зур роль уйный. Әмма комның савылуын берничек тә тизләтеп яки кысып булмый. Бу романның да эчтәлеге нәкъ шушы рәвештә ачыла. Әсәрнең «Ком сәгате» дип аталуы да менә шуңардан килә.

---

[1]*Кәримов К.* Ком сәгате: Роман, повестьлар.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2000.— Б.209.

Композицияне тема итеп чыгару белән әдипнең әдәбиятка зур яңалык алып килгәнлеге аңлашыла башлый.

Баштарак әсәрнең фабуласы белән бәйле берникадәр канәгатьсезлек хисе дә кичерәсең. Бу хакта искәрткән дә идек. Инде ул мәсьәләгә әйләнеп кайтырга мөмкин. Әсәрнең композициясе ком сәгатенең эшләү принцибына охшатып корылганлыктан, аның фабуласы да аңа буйсынырга тиеш, әлбәттә. Монысын да К.Кәримовның ачышы буларак күзаллау дөрес булыр иде. Әсәр тулысынча бер принципка буйсындырлуы белән камил булып килеп чыккан. Ком сәгатенең соңгы комы ничек кинәт савылып бетсә һәм шуны күреп торганда ничек вакытның тукталып калуы кебек хис күңелдә туса, К.Кәримовның «Ком сәгате»н укып тәмамлаганда да шундый ук тойгылар эчендә каласың. Менә әсәрнең каһарманы Фазыл, үз бәхетенә ирешү өчен барысын да эшләгән егет, Әлфинә белән гомерлеккә кавышырлар, аңлашырлар сыман, алар хәзер бергә, бер кабинада. Әмма шунда Язилә пәйда була. Ул язгы ташу вакытында, Бөгелмә аша юл табып, бөтенләй мөмкин түгел сыман вакытта, кинәт, төн уртасында ашкынып килеп җиткән. Вәгъдәләшмәгәннәр дә, югыйсә. Фазыл аңа беркеме дә түгел. Ә Язилә — максатчан.

Аның аркасында Фазылның бәхете, мәхәббәткә багышланган киче өзелә. Соңгы бөртек ком савылып төшкәндәй тоела. Ком сәгате кинәт туктап кала. Әсәр тәмамлана. «Ком сәгате»н автор тагын-тагын әйләндереп куярдыр сыман. Әсәрнең композициясе дә моңа тулы мөмкинлек бирә, югыйсә. Бәлки шушы корылмада әсәрнең дәвамнары да барлыкка килер, кем белә? Әмма хәзергә «Ком сәгате» туктап калган хәлендә.

Әдәбият белән кызыксынучылар хәбәрдардыр: К.Кәримов яшьлегендә су скважиналары бораулаучы булып эшләгән[1]. Бу факт әсәрен язганда авторның шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянганлыгын раслап тора. Хезмәте җиңелләрдән булмаган. Фазылның күргәннәре аша әдипнең язмышын да чамалау мөмкинлеге бар. Дөрес, ул бары тик үзенең генә тормышын

---

[1]***Карагыз:*** *Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.* Совет татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә.— Казан: Татар.кит.нәшр., 1986.— Б.272.

бәян итеп чыккан дия алмыйбыз. Әмма авторның шәхси тормыш тәҗрибәләре тәэсирендә вакыйгаларның реалистик планда ачылуын һичничек инкарь итү мөмкин түгел. «Ком сәгате» буш фантазиягә корылган әсәрләр рәтендә йөрми, анда саташу һәм саташтыру, башка әдипләргә һәм әсәрләргә ияру дә юк.

Әсәрнең каһарманнарыннан егет кеше Фазыл һәм аның хезмәттәшләре зур акча эшләүчеләр. Әгәр дә бүгенге чорның хыялый күзлегеннән карасак, алар бәхетле булырга тиеш иделәр бит. Әмма бәхет акчада түгел икән шул. Зур акчалар эшләп алып кайткан Фазылны Шәледә әнисе тарафыннан инде сатылырга өлгергән, үз көчләре белән салынган ятим йорты көтеп тора. Көтеп тора, дип, көтеп тормый шул. Бу йорт инде аларныкы түгел. Әнисе колхоздан алган ссудасын түләп бетерә алмаганга саткан аны. Авылдашлары, бигрәк тә җирле җитәкчеләр күпме мәрхәмәтсезлекләр кылганнар. Автор боларны белдереп үтми кала алмаган. Язучыларны туган авылы һәм авылдашлары гөл туфрагында гына үстермиләр шул! К.Кәримов Шәленеке түгелме?

Әсәрнең башыннан ахырына кадәр шушындый аяусызлык, мәрхәмәтсезлек, мәгънәсезлек белән тулы тормыш вакыйгалары реалистик планда чагылыш таба. Гадел җәмгыять буларак хыялланылган социализм заманында да ул шушындый сурәтендә, инде яңа, монысы да гадел дип аталган демократия чоры да шушындый ук сыйфатта. Берни үзгәрмәгән. Ком сәгате бер башыннан икенчесенә әйләндерелеп кенә куелган. Һаман шулай ук тормыш комы ага бирә, савыла бара.

Хәер, бу хакыйкатьләр, кемнең-кем булуы халыкка күптән мәгълүм. Алар турында күпме каләм карасы түгелгән, күпме бәгырьләрнең каннары кипкән. Тагын күпме язарга мөмкин? Барыбер файдасыз!

Ә К.Кәримов шушы хакыйкатькә бөтенләй башкача караш тәрбияләүгә алынган. Тормышка карата ироник мөнәсәбәт, тормыш авырлыкларына, үткәнгә шушы әсәрендәге кебек ироник караш татар укучысына җитми иде түгелме?

Дөрес, татар әдәбиятында мондый хисләрне тәрбияләүче әсәрләр элекләрне дә бар иде. М.Мәһдиевнең повестьлары нәкъ менә шушылай, авыр һәм мәрхәмәтсез тормышка карата

ироник мөнәсәбәт тудырып язылганнар иде түгелме соң? «Без кырык беренче ел балалары», «Ут чәчәге», «Торналар төшкән җирдә»һәм башка әсәрләре белән М.Мәһдиев татар әдәбиятында ирония алымын файдаланмадымы? Әйе, дибез. Ул да шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянды, ул да тормышның авырлыгына карата ироник мөнәсәбәт тәрбияләде. Һәм менә К.Кәримов бу әдәби юнәлешне, әдәби агымны тагын да биегрәк баскычка күтәрде. Без инде хәзер татар әдәбиятында җитлеккән, көчле агым булып яшәүче ироник реализм методының барлыгы турында белдерә алабыз. Ул оптимистик социалистик реализм кысаларында да яшәгән икәнлеген аңлыйбыз, беләбез. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Реализм, әдәби иҗат юнәлеше буларак, романтизм сыман, үзендә әлегә без күз алдына китереп җиткерә алмаган күптөрле мөмкинлекләрне яшәтә, үстерә килә. Вакыты җитеп, аны тарихи бер дәвердә тормыш тәҗрибәсе туплаган һәм формалашкан әдипләр үз иҗатлары белән үстереп җибәрәләр.

Бездә, фәндә һәм тәнкыйтьтә, иҗат методларыннан, аларга яратмыйча гына «изм»нар дип карап, ятсыну һәм курку яши. Моның сәбәпләренең берсе — иҗат методларының табигатен белмәүдән, аңламаудан гына, югыйсә. Хәер, сүзебез ул хакта түгел, башкада: татар әдәбиятында бүгенге көндә яңа бер иҗат методының тәмам формалашып җитүе һәм яшәве хакында, ироник реализм турында. Аның тормыш дөреслеген өйрәнү һәм чагылдыру механизмын хәзер күзаллау авыр түгел. Ул тормыш хакыйкатен, бигрәк тә аның авырлыгын ироник планга корып ачудан гыйбарәт. Электә үк язылган ироник әсәрләр һәм ирония алымнары әлбәттә аның тамырын хасил итә, әмма аның метод буларак формалашып җитүе К.Кәримовның «Ком сәгате» романына карый. Моңа автор үзенең барлык иҗаты үсеше дәверендә килде. Бу әсәргә татар әдәбиятының тарихи барышының бер затлы нәтиҗәсе буларак та бәя бирергә кирәк.

*12 март, 2008.*

# БЕЗНЕҢ ФӘНЗАМАН

Бүгенге көннең чын әдибе хакында сүз кузгалса, иң тәүдә татарның Фәнзаман Батталын телгә алырлар иде дә, аның дөньякүләм мәшһүр О’Генри һәм Газиз Нәсин белән бер рәттә, хәтта ки кайбер үзенчәлекле яклары белән өстен дә торуын искәртеп куярга онытмаслар кебек. Әмма... Әмма дими дә булмый. Сәбәбе шунда — безнең татар әдәбиятын укудан, аңлаудан дөнья халыклары мәхрүм. Хәтта үзләренең бу яктан никадәр чарасыз икәнлекләрен төшенүдән аз гына да арырак китә алмыйлар. Алар уйлыйлар: имеш, татар халкы күптән урысча яза, урысча сөйли, урысча яши. Хәер, урыс белән гомергә сайрашып яшәвебез аркасында, газиз Г.Тукаебыз әйтмешли, тел-лөгать һәм әхлак алмашканбыз да алмашынганбыз инде. Бер-беребезне сөештерү гадәтләребез дә юк түгел. Тик урыс та татар әдәбиятын белми, белә дә алмый калган. Ул тәрҗемәи ярым-йорты китаплар аны безнең эчке тормышыбызның тирәнлегенә алып керер дәрәҗәдә түгелләр. Безгә рәхәт, анысы: урыс телен белүебез, аларның әдәбиятын өйрәнүебез, бу исә Анналарын, Базаровларын ялгышмый тануга, урыска нәрсә кирәклеген кыланышыннан ук аңлавыбызга китерде.

Һәр милли әдәбият үз халкын, аның вәкилләрен яза, дөньясын биниһая якты талант кояшының нурлары белән яктыртып бирә. Менә шуңа күрә дә, кайсы гына халыкны өйрәнсәләр дә, галимнәр иң тәүдә аларның телләрен, гореф-гадәтләрен төшенергә тырышалар, моның өчен һәм сөйләм, һәм язма әдәбиятлары белән танышуга ихлас күңел салып эшкә керешәләр. Бу — мең тапкырлар танылган, хакыйкый чара икәнлеге ачыкланган дөрес юл.

Әмма безнең татар белән дөнья халыклары кызыксынмыйлар. Барлыгыбызны белсәләр — рәхмәт, диям. Аннары, алар безнең әдәбиятыбызны асылына төшеп аңламаслар, чөнки әдәбиятыбызны төшенүләре өчен мәдәниятебезне белүләре, кабул итә алулары кирәк. Ә безгә — җайлы, ә безгә — күңелле. XIX йөзнең соңгы чирегендә данлыклы бабаларыбыз Европага таба йөз белән борылганнар да, Жан-Жак Руссо,

Вольтер, Гейне, Гете һәм башкалар хакында, аларның фикерләрен актарып ташлап, җиңел кулдан бәхәс кыла-кыла, аларга ияртеп урыс әдипләрен дә өйрәнеп, безнең фәһемдә бөек кызыксыну шаукымы белән сугарылган мең төрле төсләрдән гыйбарәт мәдәният бакчаларын чәчәккә күмеп, дәртебезгә аңлау, кабул итү көчен биреп калдырганнар. Менә шул үсештә ничек Тукаебыз, Такташыбыз, Җәлилебез, Туфаныбыз, Акъегетзадәбез, Бигиевыбыз, Камалыбыз, Ибраһимыбыз, Исхакыебыз һәм башкаларыбыз туган кебек, сүз уйнаткан кебек язганында да йөрәк-бәгырьләргә утырган юшкыннарны кубарып ташлаучы Ф.Батталыбыз да дөньяга чыккан. Дөньяга чыккан да, олы бер баһадир адәм кыяфәтендә, каш өстенә кулын куеп: «Абау, сез нигә шушы кадәр ваклар?»— дип шаяртып та аласы иткән.

Ул йомшак чеметә, боргачлап аптыратмый, күсәк күтәреп ору гадәтендә юк. Бездә күпләр, сүз яза башласалар, шулкадәр ерактан һәм тирәннән алдыралар ки, гүяки фикер сабаннары мәгънә туфрагын каергалап салыр сыман. Әмма бу кыланышлары җир өстен тырнап барулары кебегрәк килеп чыга. Тавыклары түтәлгә керә башласа, бакча читәнен сикереп узар өчен җай чамалап уйланып йөри-йөри, көнен, төнен, ничәмә гомерләрен уздыра. Инде менә сикереп менде бу, дисең. Инде дә йөгереп керде дә түтәлләрне актарып ташлады, әшәке җан, дисең. Әмма ул кикрик каһарманы, бичаракаем, максатына ирешә дә алмыйча егылып үләргә өлгерә.

Ф.Батталда хәтта чебие дә андый түгел. Инде карыйсың, әсәренең каһарманы Америкага барып чыккан. Мактанып торырга вакыты юк. Үз дигәнен итеп, милли туфрагыбызга кайтып та җиткән.

Ф.Баттал вакыйгаларны җыйнак төзи, аның фикерләре ныклы нигезгә корылганнар, сүзләре якты һәм ямь булып тезелеп китәләр дә, саф чишмә кебек челтерәп, зиһенгә агылалар, күңелләрне кытыклап алалар. Аларны укыганда күңелләргә сафлык үзе тула, еллар буе килгән юк-бар уйларыңнан, тормыш юлларының тузаннарыннан арынасың. Аның ул бер-бер артлы бер дә тукталып булмыйча укыла торган хикәяләре, әдәби парчалары бары тик чын татарның талант

җимеше, әлбәттә. Башка халыкларда ул вакыйгалар болай була алмыйдыр сыман. Ф.Баттал әдәби сүзе-җөмләсе, уе-фикере белән ничек чып-чын татар булса, вакыйгаларны тасвирлап бирүдә дә, каһарманнарын сурәтләүдә дә асыл татар, соклангыч милли әдип. Ул хәтта шушындый булуы һәм була алуы сәбәпле дә дөньякүләм бөек әдип. Дөньяның ирешелмәгән кыйтгалары, табылмаган утраулары юк дияргә ашыкмагыз! Әле әнә күптән түгел генә Төньяк диңгез-океан киңлекләрендә Йайа утравын ачтылар. Татар әдәбияты һәм әдипләре дә дөнья халкы өчен әлегә ачылмаган бөек кыйтга белән бер.

* * *

Тикшергәндә, ачыклык керткәндә — төгәл билгеле була: безнең Ф.Баттал совет юморыннан үсеп чыкты. Аның әсәрләрен без, укучылары, совет җәмгыятеннән көлү буларак кабул иттек һәм аларда сурәтләнгән хакыйкатьләр ярдәмендә дөньяны ачык аңларга, тоярга, бәяләргә өйрәндек. Көлкеле идек, көлкеле иделәр, әмма хәлләребез еларлык та булган икән шул.

Бу сүзләребезне язганда Ф.Батталның ике юмористик һәм сатирик хикәяләр җыентыкларын күздә тотабыз. Аларның беренчесе — «Сакалыңа ут капса...» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 96 б.) дип атала, икенчесе — «Гөнаһ шомлыгы» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.— 247 б.) дип исемләнгән. Совет юморы, яки советча юмор — үз тарихы һәм традицияләре белән яшәде. Аның һәр үсеш-яшәеш этабының үз төсе, үз фәлсәфәсе, үз картиналары бар иде. Узган гасырның беренче чирегендә формалашып җитеп, хәтта социалистик җәмгыять таркалып төшкән шул ук гасырның 90 нчы елларында да ул үлмәскә тырышты, аны алыштырган яңа тип юмор әдәбиятыбызда нәкъ менә шул ук 90 нчы еллар ахырында формалашып җитте. Ул да милли Камырбатырыбыз кебек булып чыкты, көн үсәсен төн үсте, төн җитешәсен көн өлгерде. Аны бишегеннән күтәреп алып, алга таба тәпи йөгертеп җибәргән кеше дә Ф.Баттал иде, комедия һәм юмор-сатира остасы Зөлфәт Хәкимне дә аның янәшәсендә атасак, тагын да Камил Кәримовны һәм бер дистәләп исемне искә алсак —

һичбер хата түгел. Аларның һәммәсен бергә, бераз күпертеп, «батталчылар» дип атарга да мөмкин, әлбәттә. Бөек Батулла агабызның татар юмор-сатирасында башлап җибәргән һәм аерым бәхәсле сөйләшүне дәгъвалаган «батуллаизмы» белән чагыштырып, бу ике мәктәпнең кайсына да беренчелекне бирә алмыйча аптыравыбызны монда искәртеп узарга тиешбез. Әмма сүз башыбыз — Фәнзаман Баттал, «изм»нарга кереп чуммыйча гына, матур әдәбиятыбызның җанны савыктырыр гүзәл бакчаларына сәяхәтебезне яңартып җибәрүебез хәерлерәк булыр.

Без Ф.Батталны — «советча юмордан үсеп чыкты», дидек. Әмма ул аның бөтен бер тарихыннан түгел, узган гасырның 60-70 нче елларында куәт алган этабыннан тамырланып килде. Бу табигый да, чөнки Ф.Баттал шул чорда каләмен чарлап эшкә керeште. Әдәбиятның юмор-сатира өлкәсендә Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, алар янәшәсенә ирешеп килгән Шәүкәт Гали, Гамил Афзал, Мөхәммәт Мәһдиев имзалары өстен куелган чордан иде ул. Бу дәвернең үз хикмәтләре, үз максатлары, үз стратегиясе булды: совет җәмгыятендә сыйнфый-сәяси мәсьәләләр чишелгән, хәл ителгән, ә менә әхлаксызлык, тәртипсезлек, аңсызлык элементлары яшәп калган,— шулар белән көрәшергә кирәк, диделәр. Без хәзер ул фәлсәфәдән көләргә яратабыз. Әхлак-әдәп мәсьәләләрен бик тә сай өлкәгә саныйбыз, яманлыкны кул ишарәсе белән генә дә хәл итү мөмкин дип уйлыйбыз. Һәм ялгышабыз. Кешелекнең асылы — әдәп-әхлакта. Ул икенчел түгел, ул — беренчел, үтә дә архи һәм катлаулы мәсьәлә. Әдәбиятта XX гасырның башыннан үстерелеп килгән сыйнфыйлык һәм партиялелек мәсләгеннән котылу, кешелекнең үз стихиясенә әдәбиятны кайтару, шуның белән аны сәясәттән, коммунистик идеяләрдән арындыра башлау чорының да, ни хикмәт, нәкъ менә 60-70 нче елларга туры килүе тарихыбыз өчен хәерле булганлыгын инде хәзер аңлауга ирештек. Югарыда, баш очында Дамокл кылычы булып коммунистик идеология эленеп торды һәм аның үтә сак һәм сизгер хезмәткәрләре тырышып эшләүләрендә булдылар. Әдәбият исә яңа җилләр булачагын тойгандай үзен хис итте. Моның өчен без «сыйныфсызлык әдәбияты» хакындагы, ул вакытта

бөтенләй дә хорафи тоелган мәсьәләне алга куйган, шул идеалларны өстен чыгарырга омтылган тәнкыйтьчеләргә рәхмәтлебез. Әмма аларның да эшләре җиңеллек белән бармады. Югары белем алып чыккан яшьләребезнең колаклары данлы-шанлы марксизм-ленинизм белән дыңгычлап тутырылган һәм тиздән килеп ирешәчәк коммунизмның бөек хезмәт кырларына ул фидакарьләребез батырларча ашкынып тора иделәр. Дөрес, үзләрен тынычлыкта калдырганнары да араларында булгандыр — дөньяда барысы да тигез хәлгә кереп бетми.

Менә шул чор әдәбиятыбызга Ф.Батталны — бөек каләм иябезне бирде. Ул да тәрбияле, хәтта ки советча тәрбияле иде. Аның бу советчалыгын «Яңа прораб», «Хатынны ничек кулга алырга», «Кайнар характерым» һәм тагын да берничә дистә хикәясенең эчтәлеге дәлилләп тора. Ул советча гына түгел, хәтта ки чын коммунистларча да булгалады. Әмма безнең коммунист җитәкчеләребез шикәр чөгендерен мал чөгендереннән, солычаны-сарутны солыдан, арыш саламын бодайныкыннан аера алмаганнары кебек, гаделлек белән гаделсезлекне дә бутый торган аңгыралардан иделәр. Алай түгел дип бәхәсләшергә теләүчеләр Ф.Батталның китапларын ачып укысыннар, ул аларны бармактан суырып чыгарып язмаган, әсәрләрендә тормышның үзен, аның хакыйкатьләрен тасвирлаган. Менә шуңа күрә дә Ф.Баттал әле башы-аягы буталу дәвере — аударылыш елларында, ягъни узган гасырның 90 нчы елларында да кызыл галстуклы һәм кызыл япмалы трибуналы әдип буларак та кабул ителде. Башкача мөмкин дә түгел иде.

Һәм безнең татарны милли хис, милли мәсьәлә тоташтан демократ ясады. Сизенмичә дә калдылар күпләр. Милләтенең татар булуын, милләтнең үз әнкәләредәй газиз икәнлеген аңлау-төшенү белән бергә алар дертләп уянып киттеләр һәм ашауларын да оныттылар. Бу хисләрдән мәхрүмнәр исә дөнья малларын бүлешү җаен караганнар. Безнең татарда демократия милли мәнфәгать белән бәйле кабул ителә, аңардан башка күзалланмый. Ул газиз Г.Тукаебызның «Туган тел»ен гимны ясады, шуның белән бергә демократия үзе дә милли горурлыгыбызга әверелде. Ә демократия исә яшәешебез мәйданының

түренә гади кешенең — аның хәсрәтен, шатлыгын, бәхетен — барча мәнфәгатьләрен кайгыртуны китереп салды. Татар әдәбияты гади кешегә мөкиббән итте, югарыдагыларны сөйми-өнәми, тәмам яратмый башлады. Язучылар үзләрен милләтнең асылы буларак тойдылар. Алар чын мәгънәсендә милли аристократия иделәр. Ф.Батталның иң сөйгәне — гади халык, гади кеше, аның яшәү рәвеше, тормышы, барлыгы-юклыгы, фикере-сүзе, холкы-фигыле иде. Совет чорында иҗтимагый-сәяси торыш хакында хәсрәтләнүдән ләззәтләнгән милли әдәбиятыбыз кешелеккә таба йөз белән теләр-теләмәс кенә, бик авыр борылды. Моңа кадәр «кайбер кимчелекле элементларны» көйдерүче юмор-сатираның демократик әдәбият агымына килеп керүе кайсы әсәр белән башланды икән дигән сорауны үз алдыбызга еш куябыз. Матур әдәбиятыбызга бәйле сорау бирелә калса — аның төгәл җавабын, хәтта датасын да беләбез. Ул әсәр — «Пәйгамбәрләр тарихы», әлбәттә, датасы — 1992 нче ел. Әмма кайберәүләр ул китапка бугазыннан буып ташларга теләп ябырылдылар. Бу хәл иске тормышның яшәп калырга теләп якалашуыннан шулай килеп чыкты. Аларны җен бутады, аларның җеннәре буталды. Ф.Батталның шул елларда «Гөнаһ шомлыгы» китабы басылып чыкты. Ул һаман да шул ук советча юмор иде. Әмма анда «Кияүнең «кимчелеге», «Бик каты әйтте...», «Сабак» һәм башка берничә хикәяләрендә ачык чагылган «башкачалык» та сиземләнә иде. Әдипне зирәклеге бөек итте һәм ул аңа шуның өчен дә гомере буена хезмәттә булды.

Ф.Батталның 2000 нче елда Казанда «Идел» китапханәсе» наширлегендә бастырып чыгарган «Юлын белгән адашмас» исемле 367 битле китабы бар. Ул тоташ публицистик язмалардан гыйбарәт. Әсәрләре хронологик тәртиптә бара. 1992 нче елның маенда Ф.Батталыбыз милли сукмакка кергән «социализм баласы», алга таба бер дистә ел дәвамында диярлек демократиянең ни-нәрсә икәнлеген эзләп гаҗизләнә. Югыйсә җавап бик төгәл: демократия ул — гади халык мәнфәгатьләрен яклау, гади халыкның теләк-омтылышларын бар нәрсәдән өстен кую! Бу билгеләмә бөек грек фәлсәфәчесе Әфләтүн тарафыннан 24 гасыр элек дәлилле төшендерелгән. Ф.Баттал аны

советча аңлавы белән яшәп, демократияне сайлау ирегe, сүз ирегe кебек, нәтиҗәләрне сәбәбе-нигезеннән башка гына күзаллый. Ә талантның үзенчә булырга хакы бар. Бу китабы Ф.Батталның чын мәгънәсендә яңа чор әдибе төсен ала баруын ачык күрсәтеп тора. Китапка сүз башы язган тәнкыйтьче Мансур Вәли-Барҗылы аның авторының үткен каләм иясе икәнлегенә кат-кат басым ясый һәм җыентыктагы барча публицистик язмаларының тупланып бирелмәвен искәртүне кирәк таба (китапның 5-8 битләрендәге «Сатира батыры» язмасы хакында сүз бара). Дөрес яза: Ф.Баттал — фидакарь. Аның публицистикада да шундый булуын «Замандашларым» (Казан: «Ихлас”, 2013.— 192 б.) китабы тагын бер кабат раслый. Ул андагы язмаларында рухлары белән үзенә якын кешеләрне бәяли, бәянли.  Кызыклы да, уңышлы да хәбәрләр. Кешеләрне бәяләве — бер хәл, алардан Ф.Баттал үзен дә эзлидер сыман тойгы калдырыла, ул үзенә дә читтән караш ташлыйдыр кебек. Бу да, әлбәттә,— фидакарьлек, күңеле сафлыгыннан килә. Ә талант иясенең күңеле караңгы була алмый.

* * *

Ф.Батталның бөек талант иясе икәнлеген тәкрарлар өчен «Сигезенче оҗмах» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 351 б.), «Менә шулай яшә!» (Казан: «Идел-Пресс», 2008.— 384 б.), «Көлмә кешедән...» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.— 383 б.) китапларын да дәлил итәбез. Алар юмористик һәм сатирик әсәрләреннән, төрле планлы язмаларыннан төзелгәннәр. Дөрес, берсендәге хикәянең икенчесендә дә кабатланган очраклар бар. Әмма бу кабатланып басылган әсәрләре, талантлы язылган булулары сәбәпле, ул кабатланылуларын аклыйлар. Ә менә «Башыңны сакла, кызым!» хикәясен укыганда котларың очарлык. Кая ди ул көлү, елап җибәрүдән чак тыелып каласың. Заманага хас вәхшилекне язганда Фәнзаман аганың бөек каләме хакыйкатькә бәйле штрихларны «басыбрак», «кәгазьне тырмабрак» язып куя. Мондый урыннар аның әсәрләрендә очраучан. Әдәби әсәрләрне тигез генә, сикәлтәсез генә язылырга тиеш дип белгән сак күңелле укучылар, мондый урыннарны укыганда, «әтәч җибәрде», «фальш ясап алды» диярләр,

әлбәттә. Бу хикәягә бәйле дә ул сүзләр дөрес булачак. Акланырлык та түгелдер сыман. Язучы язганнарга карасак, ямьсез килеп чыккан. Чибәр Рәмзияне баянчы инде «харап иткән» булган икән. Имеш, ерткыч егетләр хәзер нишләсә дә ярый.

Болай ук кирәкми иде. Бу — әдипләрчә түгел! Моны яшереп калырга ярамас, язучының үзенә дә шелтәле искәртми мөмкин түгел. Дөрес, укучының хисләрен кызганудан, әсәрдә тасвирланган ситуацияне бераз йомшартырга, трагедияне юморга борырга теләүдән бу шулай килеп чыккан, бөек талантыбызның аягы таеп киткән, дия алабыз. Әмма әйтмибез, чөнки сәбәп аңардан түгел, бәлки заманабыздан килә. Без хәзер барча бәлане җилкә аша җиңел үткәреп җибәрү ысулларын психологларның һәм шарлатаннарның төрлечә бастырылып таратылган киңәш китапларыннан өйрәнеп бетеп киләбез. Монда әдибебез шушындый коры тәэсиргә бирелгән, анысын да аңларга тиешбез. Шулай да Ф.Батталның бөек таланты аклауга һәм акланугa мохтаҗ түгел. Бәлки менә шул «фальш тоелган» урыннарның кайвакыт әһәмияте зуррактыр да әле? Алар җәмгыятебезнең йөзен күрсәтү алымнарының яңаларыннан түгелләрме?

Ф.Батталның талантлы язу сере гади, хәтта, әйтер идек — үтә дә гади: ул бер-бер тормыш фәлсәфәсенең җеп очын эләктереп ала да аны җай гына сүтә башлый. Чияләнеп беткән, ягъни «фальш тоелган» җирләрен дә сак кына җайлап җаептөзәтеп җибәрә. Хикәя формасындагы йомгагына урап бетерә дә, әсәрен укучы алдына «тәгәрәтә». Күренеп тора — бик гади, үтә дә гади. Әмма аны шулай итәр өчен язучылык сәләтең генә аз, моның өчен Ф.Батталныкы кебек бөек талантка ия булуың кирәк! Бу О’Генри һәм Г.Нәсин иҗатларында да нәкъ шулай.

*Декабрь, 2013.*

## «ОЧА ТОРГАН КЕШЕЛӘР» ЯКИ АК ТӨС ТАНТАНАСЫ

*(Г.Гыйльманов иҗатына бәйле)*

Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» романы 2007 нче елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан бастырылып чыгарылган шул ук исемдәге «Роман, повесть, бәяннәр» җыентыгында дөнья күрде. Моңа кадәр ул алдан «Идел» журналында, журнал варианты буларак, укучыга тәкъдим ителгән иде.

Күләме белән бу роман зур түгел, китапта алдагы 150 сәхифәне алып тора. Язылышы белән кызыклы, укучыны үзенә җәлеп итә. Вакыйгалары һәм геройлары, Г.Гыйльманов каләменә хас булганча, аерым бер күңел җылысы белән ачылалар. Каршылыклар геройларның үзара юктан гына үпкәләшүләреннән, бер-берсен якын итмәү, аңламауларыннан, үз «эго»ларының өстен куелуы сәбәпле барлыкка киләләр, шушы «су» белән даими сугарылып, шушы «су» белән вакыйгаларда үстереләләр, конфликт дәрәҗәсенә җиткерелеп, ахырда чишеләләр. Бу конфликт эчке каршылык төсен ала, әдәби герой бөтен сурәтләнелеше белән тышкы дөньяга каршы куела. Аның үз дөньясы гына хакыйкый, үз карашлары гына дөрес, үз әдәбе генә әдәп, ягъни бөтен яктан да ул үзе булып кала. Вакыйгалар барысы да аның барлыгын һәм өстенлеген раслау өчен хезмәт итәләр. Мондый геройлар үзләре шулай ук ак яки кара була алалар. Романда Г.Гыйльманов нәкъ менә шушы ике төсне уңышлы файдалана, чагылдырган тормыш һәм табигать картиналарын да шушы буяулар белән сурәтләп бирә. Моның да уңышлы як булуын искәрергә тиешбез. Вакыты-вакыты белән әдәби картиналарда аерым төсләр дә барлыкка килеп ала тора, мәсәлән, төп геройның балачак хатирәләреннән калган кояшлы көннәре яки кыр чәчәкләреннән җыйган букеты, яисә авылга кайткач, клевер чабарга барырга ниятләнеп-сөйләшеп йөрүләрендә клеверны күзаллавы, кызыл-бакыр чәч һәм зәңгәр күзләр — болар шушы

ак һәм кара төстәге күренешләргә аерым-аерым тörтке-нокталар рәвешендә төс биреп алучы тере картиналар.

Г.Гыйльманов бу романында махсус рәвештә ак төсне өстен чыгара. Әсәренең теле дә моңа хезмәт итә. Автор шушы төсне бирү өчен стилистик модельләрне оста файдалана, бигрәк тә әйтемнәр, мәкальләр, хикмәтле сүзләр романда еш кулланылалар. Укучы мондый хикмәт-аксиомаларның, берсен икенчесе алыштырып килеп, тезмәләргә әверелеп китүләрен дә уңай кабул итә. Алардан артык та, ким дә түгелләр сыман дигән тойгы кала, чөнки бер мәкальгә икенчесе бәйле, икенче-сен өченчесе ачыклый, конкретлаштыра, өченчесенә дүртенчесе мәгънәви яктан берегеп китә. Мондый урыннарны, Д.Заһидуллина термины белән әйтсәк, стильдә җөмләләрнең вакыт-вакыт «җем-җем җемелдәп китүе» очраклары дип атар-га тиешбез. Ул «җемелдәүләр»дә автор бик оста рәвештә ха-лык мәкальләрен дә, үзе уйлап чыгарганнарын да, хәтта ярым-хикмәт, ярым-аксиома рәвешендә булуларына да карамастан, уңышлы кертеп җибәргән. Мәсәлән: «Кайсыдыр изге китапта әйтелгән бит: «Алла безгә биргән рухны нык сагына»,— дигән» (романның беренче битләрендә үк бу сүзләр). Һәм ав-тор шушыңа бәйле үз фәлсәфәсен тезә башлый. Стильдәге ул «җемелдәүләр» аерым төс алган картиналар белән үзара ярәшеп, романның укучыга тәэсирен камилләштерәләр. Әсәр көчле җәлеп итә. Бер сулышта диярлек укыла. Артык аклыгы, артык буталчык булуы, артык таркау вакыйгалардан торуы һәм аларның гүяки очраклы рәвештә бергә җыелулары кебек тойгылар уятуы, инде кайдандыр таныш булган, римейка элементларының төрле культураларга хас әдәби әсәрләрне һәм кинофильмнарны искә төшерүләре — болары шулай ук үз рольләрен башкаралар. Романны анализламаган очракта, уку өчен генә укыганда — әсәрләндерә, бик тә яхшы хис-тойгылар калдыра. Анализлаганда исә, аның эчтәлеге көтелмәгән яктан ачыла. Бу ягы белән Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр»е үзенең үк «Албастылар»ына да, А.Хәлимнең «Өч аяклы ат»ына да, Н.Гыйматдинова, Ф.Бәйрәмова, М.Галиев, З.Хөснияр, З.Хәким әсәрләренә дә тартым. Бу әдипләр һәм аларның иҗаты татар әдәбиятында бердәм көчле әдәби агым

барлыгын раслый. Без аларның барысын да «постмодернистлар» дип атыйбыз. Араларында нинди әдип булуы ачык аңлашылып торганы, постмодернизмның һәммә якларын да үз иҗатында раслый, үстерә, милли үзенчәлекләрен тагын да ныгыта алганы Г.Гыйльманов, әлбәттә. Шунысы кызыклы, бу әдип-әдибәләр бер-берсен кабатламыйлар, әдәби дөньяларын үз стихияләрендә, үз карашлары эчендә, үз фәлсәфәләре белән бәйле яшәтә беләләр.

Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» романы һәм аның бүгенге укучы өчен иң әһәмиятле ягы — җиңел укылуы белән дә кызыксыну уяту көченә ия булуында. Андагы туктаусыз кабатланучы символлар, символик һәм мистик эчтәлеккә ия әдәби картиналар, уйдырма һәм чыннан да халыкта таралган яки юк мифлар, әкиятләр, дөрес һәм ярым-дөрес сынамышлар, аларга геройларның игътибар итүләре һәм әсәр барышында шуларның дөрескә чыгулары яки геройларның боларны хак дип искәртүләре, халыкта булган яки булмаган йолаларны халыкта сакланып кына калмаган, онытылган яисә хәзер дә бар, әмма аңа игътибар гына итми торылган дигән фикерләр уздырылу — болар барысы да авторга карата да укучыда соклану тойгыларын уяталар һәм әсәрнең талантлы язылуын раслап торалар.

Төп геройлары да бик кызыклы бирелгән. Романда өч Сәүбән хакында сүз бара. Беренчесе — Сәүбән үзе, авылда туган, ак йөзле, сыек зәңгәр (күк) күзле, бакыр чәчле — Венера планетасы кешеләре шундый, имеш. Һәм анда әтисеннән калган гадәт бар: ул — «оча торган кеше», ягъни таудан да сикерә ала, биек йортның балконыннан да төшеп китә, башкача да. Аның арка-сыртында канатлардыр сыман. Автор укучыны шушы характеристика һәм портретлары белән тулысынча ышандыра.

Сәүбән, мәктәпне бетергән елны, колхозда бригадир булып эшләүче көрәшче егет Рәмис белән каршылыкка килеп, яраткан кызына көнчелеге аркасында сугышып, тәмам кыйналып, икенче көнне авылдан бакча артлатып кына чыгып кача. Казанга килә. Авиация институтына укырга керә. Аның шушы китүеннән 18 ел буе авылга бер генә кайтмавы әсәрдә берничә

кат әйтелә. Ә роман поезддан төшкән, авылына таба атлаучы, күңеле моңлы булуы йөзенә чыккан, «җыйнак кына мыек җибәргән, тыйнак кына, әмма ыспай итеп чәчен кистергән... кырык биш яшьләр чамасы булыр» (романның иң тәүге беренче абзацыннан) — шушылай Сәүбәннең портретын сурәтләү белән башланып китә. Әгәр дә мәктәпне бетергәнендә Сәүбәнгә кимендә унсигез булса (яки иң күбе 18 булсын), аның тагын да унсигез ел авылга кайтмавын искә алсак, аңа бу вакытта 35–36 яшьләр чамасы булыр иде. Әмма авторның белдерүеннән без аңа инде 45 яшьләр тирәсе икәнлеген беләбез. Дөрес, романда Сәүбәннең авылына бу юлы кайтканындагы яше төрлечәрәк бирелеп барыла. Әмма автор аны кырыктан киметми. Һәм без моны Г.Гыйльманов махсус рәвештә шулай эшли дип уйларга мәҗбүрбез.

Икенче Сәүбән — ул беренче Сәүбәннең өрәге, бала чагында калган Сәүбәннең җаны дип аңларга кирәк. Әмма аңа нигәдер 12 яшь. Әгәр дә Рәмис белән сугышуына һәм авылыннан Сәүбәннең чыгып качуына бәйләп карасак, бу өрәккә уникe генә яшь була алмый.

Романның башында ук бу өрәк белән дә очрашабыз. Ул авыл капкасы янында Сәүбәнне унсигез ел буена кайтырмы дип көтеп утырган. Аңлашыла, бу — аның тынычлыгын югалткан җаны. Шушы мистик образ романның тәэсир көчен бермә-бер арттыра, укучыда шик һәм уйлану тудыра, күңелендә интригалы тойгылар хасил итәргә этәргеч бирә. Хикмәти мәгънә алып, чынбарлык белән хыял, тышкы дөнья белән эчке дөнья буталышы (яки кушылышы) барлыкка китерелә. Әсәр үзенең реалистик эчтәлеген шушы өрәк килеп күренүдән башлап, ягъни беренче битләрендә үк югалта. Фэнтези дөньясы башланып китә. Ул әлбәттә аклы һәм каралы гына. Монда барысы да яки ак: дөнья да (әйләнә-тирә мөхит) һәм андагы кешеләр дә (Ак әби, Ак бабай һ.б.), яисә кара гына: тау эче, болытлы яңгырлы төн, кайбер кешеләр (Зәлифә, Рәмис, хатыны Сәвия һ.б.). Әсәрдә буталчык урыннар берсен икенчесе алыштыра. Монда автор түгел, герой бутала. Вакыйгаларны ул бер логикага салырга тырыша, әмма мантыйкта алар төрлечә килеп чыгалар. Шул сәбәпле Сәүбәннең сөйгәне

Сәвия дә көмәндә баласын кай очракта елдан артык, икенче бер логик тезмәле ачыклауларда хәтта ике ел һәм аннан да артык йөрткән кебек аңлашыла. Баланы табу вакыйгалары да әсәрдә төрлечә сөйләнелә.

Бу бала Сәүбәннең улы булып чыга. Нәкъ аның үз өрәгенә охшаган әле, җитмәсә. Шулай ук 12 яшендә. Әүвәле Сәүбән аны үз баласы итеп танымый, аннары гына, вакыйгаларны исенә төшереп, андагы буталчык урыннарга ачыклык кертә. Бу — шизоанализ юлы, шизакатьлек стихиясе. Шул Сәүбән, Сәүбәннең улы, романдагы өченче Сәүбән буларак, алга таба тагын да фэнтези элементын вакыйгага әверелдерү һәм үстерү өчен хезмәт итә башлый.

Әсәрдә ике Сәвия бар. Аның берсе — Сәүбәннең үз хатыны, икенчесе — яшьлегендә яраткан Сәвиясе. Алар авторның әхлакый карашларын яктырту өчен хезмәт итәләр. Бу яктан Зәлифә образы да уңышлы файдаланылган. Бер геройларына әсәрдәге вакыйгаларның сюжет йөген йөкләп, икенчеләренә әхлак-әдәп карашларына бәйле фикерләмәләрне биреп, Г.Гыйльманов, башка әсәрләрендәге кебек үк, «Оча торган кешеләр» романында да әдәби образларны бирү системасына ия булуын таныта. Бу аның, әлбәттә, уңышы дип хаклы рәвештә бәяләнергә тиеш.

Шулай да «Оча торган кешеләр» (романның тулы исеме: «Оча торган кешеләр, яки Иясез язмышлар хакында бәян») әсәре кемнәр һәм нәрсә хакында соң? Анда мантыйк та, тормыш дөреслеге дә юк сыман да, бар сыман да тоелса да, аңа ничек һәм нинди бәя бирергә?

Бу сорауларның үзләрендә үк җаваплары бар. Романның тулысынча ак төс эчендә, ак төс тантанасы белән язылуы, моңа язучының стилистик табышлары да хезмәт итүе, вакыйгаларның осталык белән сайлап алынуы, ак әби һәм бабайларның күплеге, кешеләрнең күңелләрендә шәфкать хисенең өстен чыгарылуы — болар барысы да хастаханә атмосферасының чагылышы. Сәүбәннең тормыш картиналарында логикасы булмау, вакыйгаларның "римейка" тәртибендә төзелүе — төп геройның шизакатьле (шизофреник) булуын раслыйлар. Бу романны, шулай итеп, шизоанализ

принцибына корылган дип әйтә алабыз. Әсәр татар постмодернизмының гүзәл үрнәге буларак хаклы рәвештә бәяләнергә тиешле.

*2005–2011.*

## САРМАН ДАМИР

Сарман якларында һәркемнең Дамир Хәйрулла улы Гарифуллин хакында мәктәп елларда ук ишетеп үскәнлегенә шигем юк.

Шулай бервакыт, өлкәннәрнең: «Безнең клубка Сарман Дамир киләсе икән!»— дип сөйләшүләреннән белеп алгач, халыкка тотачак нотыгын тыңларга һичшиксез без дә барырга иптәш малайлар белән хәл итеп куйган идек. Билгеле булды, мәктәп директорыбыз Нәкыйп Әмирович Арслановтан, кич клубка чыгарга рөхсәт сорап, гариза язып үтенергә тиеш икәнбез. Әмма өметебез куш килмәде. Ул көнне районыбыз Сарманның югары кешеләре безнең Дүсем авылыннан Минзәлә елгасы гына аерып торган Ләшәүтамак авылындагы уртак мәдәният сараебызга күпләп киләселәре билгеле булды. Димәк, бала-чагаларның ул тирәгә эзләрен дә бастырмаячаклар. Җитмәсә, анда сөйләнәчәк нотык бик җитди булып, җыелырга тиешле өлкәннәргә дә утырыр урын җитмәячәк икәнен белдерделәр. Имеш, без әле пешмәгән!

Яшүсмер вакытлар иде. Андый яшьтә дә кылны кырыкка ярмагач, ди. Иптәшләрем дә әле кайчан-ничек үзләренең пешеп өлгерәчәкләрен көтеп утырачак түгел икән. Дустым Әгъләмов Расих, этисеннән ишетеп: «Ул анда җеннәр турында сөйлисе!»— дип, инде икенче көн рәттән котырта. Җеннәрне күргән юк, анысы, әмма ишеткән бар, бик хикмәтле нәмәрсәләр икән алар, судан да коры чыгалар, ди, утта да янмыйлар, ди.

Дамир абый килергә көннәр якынайган саен, Дүсем һәм Ләшәүтамакта гына түгел, хәтта Әмерекәдәге җеннәр мәсьәләсе дә халык алдына куелып, уңнан-сулдан тикшерелеп, кем күргән дә кем юклыгы ачыкланылып, бәхәс мәйданнарында сүз айгырлары йөгәннәреннән чыгарга өлгергән иде. Күрше Әхмәдишин Ленар: «Берни дә белмисез,

менә минем әти күргән ул җенне. Таудан утлы тәгәрмәч булып ургылып-бөтерелеп төшә икән. Әле ярый Минзәлә елгасына юлы туры килеп, әти шуннан бу якка чыгып котылган!»— дип, эткәсе Хәмидулхак абыйдан отап алганнарын сөйләп бетерергә өлгерми, аны яшькә дә буйга да кечерәк икенче күршем — Кәлимуллин Дилбәр бүлдерә: «Тешләрен ялтыратып, күзләрен утлы тәгәрмәч итеп уйнатып килде дә колагымнан алды, менә, шунда пешкән эзе хәзер дә бар!»

Озак эзли торгач, дус-иптәшләрем чыннан да пешкән булырга тиеш дип, Дилбәрнең колак очындагы сипкел галәмәтен табып куанышалар: «Ул җен атаң Котдүс абый булгандыр әле!» — диюче юк. Аңа Халиков Әмир һәм башка күрше малайлары кушылып сөйли торгач, сүз тәлинкәләре артыгы белән әйләндерелеп, күңелләргә шом төшеп, кичке эңгердән шөлли-шөлли, йөгерешеп өйләребезгә таралышабыз. Ул вакытларда юрган астыннан борын төртергә дә куркышып йоклаганнар әле дә хәтердән китмәгән...

Ә Дамир Хәйруллович Гарифуллин, ягъни Сарман Дамир килгән көнне җен-мазар хакында телгә алып сөйләшер кеше янәшәдәге ике авылның берсендә бер калмаган иде. Җитмәсә, һәммәбезне сөендереп, мәктәбебез белән тезеп, мәдәният сараена алып киттеләр. Өлкәннәрнең җыелышы алдыннан без бала-чагалар өчен Дамир абый шулай ук нотык белән чыгасы икән. Бу хәбәрне ишетүгә, һәммәбезнең үз җеннәре котырынып алды, күпләребез, төзек сафларны бозып, куанышып клубка йөгердек, төртешә-этешә беренче урындыкларны алдык, туйганчы шаулаштык-гөрләштек. Укытучыларыбыз безне тыя алмый гарык булдылар. Беренче килеп кергәндә суык кебек тоелган зал эсселәнә барды. Бүрекләр очты, бияләйләр саташты, алар артыннан бишмәтләр, инде чират итекләргә килеп җитеп бара иде, сәхнәдәге кызыл постау ябылган озын өстәл янына Дамир абый чыгып баскан икән, аны шәйләп, һәммәбез тын калдык. Кешеләрнең сөйләүләреннән ул бөркет карашлы, асыл телле, пәһлеван егеттер сыман иде, ә монда куй күзле, җиңел гәүдәле йөгерек абзый елмаеп басып тора.

Менә ул муенындагы зәңгәр галстугын күлмәк якасы астында тәртипләп алды. Кулында китаплар икән, аларны

өстәлгә куйды. Директорыбыз Нәкыйп Әмирович тә сәхнәдә күренүгә, без һәммәбез үрә торып бастык, исәнләштек. Дамир абыйның йөзеннән әлеге дә баягы елмаюы китмәде. Кызыл япма-постаулы өстәл артына утырырга да өлгермәде, данлыклы нотыгын тотар өчен тагын да кызылрак булган трибуна артына килеп, җитмеш кырлы графиннан салып су эчте дә: «Атеизм...»— дип сүзен башлап китте. Без ул сүзнең мәгънәсен чамалый идек. Бу әлеге дә баягы җеннәр мәсьәләсе инде, дидек.

Озакламый минем борынга йокы керде. Күземне йомып кына алдым инде, югыйсә, шаулашуларга уянып киттем. Дамир абый ялкынланып һаман да сөйли иде, минем дусларның күзләре утланган, колаклары торган, чәчләренә кадәр кабарып-кабарып ала. Һәммәсе дә авызларын ачканнар, кош тоталармыни! Мин дә Дамир абыйның сүзләренә колак куйдым...

— Бу җеннәрнең кулларында күпшәле хан заманы фирүзә мылтыклар икән. Шарт-шорт аталар, ди. Мылтыкларының күпшәләре быргыныкы кебек, очына таба җәенке икән. Шалт кына койма башыннан сикереп төшкәннәр дә, салмыш баштан төнге, күзгә төртсәң дә күренмәслек урамнан җырлап кайтып килүче Салмытдин белән Чүмретдиннең, юк ла инде, Сәлимгәрәй белән Гыйльметдиннең якларыннан эләктереп алмасыннармы. Тегеләр, беләсез инде андый вакытта, шыр җибәргәннәр. Гыйльметдин ычкынып өлгергән, Салмытдинне тегеләр койма аша гына ыргытканнар да, өйгә алып кереп, базга салганнар...— Дамир абый сүз кызуыннан ут яна идеме, ярты чиләкле графинның төбенә җитеп килеп бара, тагын бер стакан салкын суны юк итте һәм, тамагын йомшак кына төзәткәләп, нотык галәмәтенең җеп очын төйнәлеп калган җиреннән ялгап алып китте.— Әйткән идем инде, бу җеннәр шулай ук икәү икәннәр, тыкрык янындагы иске йортта яшиләр икән, дип... Гыйльметдин боларның кулыннан җиңел генә котылуына сөенеп кайткан да ятып йоклаган. Ә Сәлимгәрәйне эзлиләр, ди. Кичә кич Гыйльметдин белән җырлап узганнар иде, белсә, шул белер, диләр икән.

Килеп уяталар моны. Тора. Махмыр. Башын тоткан. Аны шул хәлдә күргән халык: «Һай, әллә Сәлимгәрәй хараплар гы-

на булдымы икән?» — дип лаф орган. Ә бу: «Юк ла инде!»— ди икән, әмма ничек, җеннәр алды аны, дип халыкка әйтсен инде? Ләм-мим...

Бер көн юк Сәлимгәрәй, икенче көн... Ә теге йортта җеннәр төн куна бәйрәм итәләр. Табак-савыт кагалар, мылтык шартлаталар, мичтә кибаб кыздыралар. Исе бөтен авылга тарала. Гыйльметдин йоклый алмый йөренә: «Сәлимгәрәйнең үтен кыздыралар, хәерсез җеннәр!»— дип аһ-ух кила. Әмма барырга курка, кешегә дә әйтә алмый. Юләрләнгән диюләре бар.

Өченче көнне Гыйльметдинне милициягә чакырткач кына, барсын да аларга бәйнә-бәйнә сөйләп бирә, бичара. Районнан наряд чакыртып, бәреп керәләр, мин сиңа әйтим, теге җеннәр оясына. Сәлимгәрәйне йолып алалар йонлач авызларыннан. Тәмам харап итәсе булганнар икән.

Баксаң, бу өйдә бер карт кына әби яшәгән, җитмештән узып киткәндә җан тәслим кылып, гүр иясе булган. Авыл белән олылап җирләгәннәр. Йола кушканча инде еллыгын да уздырганнар. Һәм менә шәһәрдән оныклары кайтып төшкәннәр дә ничә көн бәйрәм иткәннәр. Яннарында юан-юан марҗалары да бар икән. Сәлимгәрәй, өйләнгән кеше бит инде, шул җеннәргә килеп капкан, чукынчык...

Дамир абый беразга сүзсез кала. Без инде, әкиятләрдән укып-белеп үскән бала-чага, пәһлеван Салсал һәм Гали батырларны күз алларыбызга китереп, аларның ничек орыш мәйданында маһирлыклар күрсәтүләрен, җен-пәри һәм дию кебек җыен хәшәрәтләрне зөлфекарь кылыч аша уздырып, чукмарлар белән тәпәләп, Дөлдөл тояклары астында таптатып бетерүләрен чамалап утырадыр идек, ә ул безгә бер наряд милициянең калын-калын марҗалар өстенә ябырылуы хакында юк-бар сөйли — бераз үпкәләшеп тә куйдык.

Вакыт бик соң иде инде. Сорау-җавап алышуга күчкәч, сүзләрнең тагын да озынгарак сузылачагы мәгълүм булды. Һәркемне җен һәм пәри мәсьәләсе кызыксындыра иде.

— Күтәр башыңны, синең турыда сөйлиләр! Кара әле бу Пәри Яхинны, һаман йоклап утыра! — дип, Нургалиева Рәмзия арка чокырымның йомшак мендәренә кан саварлык итеп китереп төртте. Мине үртәгәндә: «Пәри!» — диләр иде,

ягъни Фәрит — Пәри! Сарайлы авылыннан Рәмзиянең әле генә акылы хушланып, катлап-катлап мине мыскыллавы иде бу. Җитмәсә, кулын күтәреп: «Бездә дә бер пәри бар!»— дип кычкыра бирде. Әле дә ярый Дамир абый тәмам арып, аның хәлен аңлап алган директорыбыз Нәкыйп Әмирович, гыйлемле итүе өчен зур рәхмәтләр белдереп, нотык кичәсен япты.

Дамир абый Гарифуллин шушы рәвешле минем күңелгә гайре табигый, адәм башына килмәгән серләрне белүче кеше буларак кереп калды. Аның хакында тагын да: «Ул борынгы комган хәрефле китапларны укый икән, кая барса, шуннан җыеп кайта, бер бүлмә тутырык борынгы кулъязма китаплары бар!»— дип, колактан-колакка күчереп сөйли иделәр. Имеш, аның ул бүлмәсе мәгарә икән дә, ул Сарман янындагы тау куышында икән. Аны елга бер мәртәбә ача икән дә, Әбугалисина кебек укып чыга, шуңа күрә белмәгәне юк, ди. Һәм мин боларга чын күңелдән, шулайдыр дип ышана идем. Китаплардан могҗиза иясе кешеләр хакында укысам, алар Дамир абый кебек күз алдыма килеп баса иделәр. Хәтта бөек физиклар, әдипләр, шагыйрьләр дә шул чамадарак сыманнар.

Үсә төшкәч, шушы гыйлем чишмәсе белән танышып, сөйләшеп утырырга, сүз көрәштереп алырга да исәпләр барлыкка килә башлады. Дамир Хәйруллович һаман да безнең мәдәният сараена әле шагыйрь, әле нотыкчы, әле башка рольләрдә килә, сәхнәгә чыга, сүзсез мәхрүм калдырмый торган иде. Әмма аралар ераклаша барды...

Һәм менә СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре белән фәнни экспедициядә юлыбыз Сарман якларына да төште. Профессор Нил Юзиев, кулъязмалар белгече галим Марсель Әхмәтҗанов белән бергә Дамир Хәйрулловичның мәгарәсенә аяк бастык.

Дамир абый берничә еллар элек «Акмулла урындыгы»н башкортларга биреп җибәреп, безнең татар зыялылары алдында гөнаһлылар исемлегенә кертелгән чаклар иде бу. Аның исемен дә телгә алырга теләмиләр. Сатлык, диләр, башкорт, диләр, һәм башкасы... Татар белән уйнап булмый шул...

Менә шундый авыр вакытларында беренчеләрдән булып арадагы сукмакны яңартучылардан булганбыздыр кебек истә калган. Дамир абый да, ялгызлыкта изаланган җанындагы караңгы уйларын яшереп, колач җәеп каршы алды, җитмәсә данлыклы һәм риваяти мәгарәсенең ачкычын да күз карасыннан читкә куйган җиреннән чыгарып, борынгы китаплар тезелгән киштәлекләр белән тулы бүлмәсенең ишеген ачып җибәрде. Шул керүдән ике-өч көнгә мин шунда калдым. Агайларның сүзләре башкачарак идеме, алар күп вакытларын Дамир Хәйрулловичның кабинетында уздырдылар, шактый катлаулы тоелган сүзләренә мине катыштырмадылар. Хәер, минем кебек яшь галим-голамәнең урыны китап тулы мәгарә эче булырга тиеш инде!

Бу борынгы кулъязмалар халкыбызның бөек рухи байлык иясе икәнлегенә бәхәссез дәлил. Китап! Тарихың бөек булса, ике нәрсә кала: китап һәм бина. Шуңа күрә дә басып алучылар аның берсен яндыралар, икенчесен җимерәләр. Никадәр җимерелгәннән һәм таланылганнан соң да борынгы таш биналарның кайсылары әле бүгенгәчә сакланып калганнар, никадәр көлгә әверелдерелсәләр дә, борынгы китаплардан кайсылары, кулдан-кулга күчеп, килер көннәргә ядкәр итеп тапшырылган.

Хәйрулла улы Дамир Гарифуллин, фидакарь көчен түгеп, борынгы китапларны югалудан саклап җыеп калдырган икән, моңа инде һәркайсыбыз мең рәхмәтледер дип беләм. Әйе, бүген андый кулъязма китапларга карата мөнәсәбәт халкыбызда уңай якка үзгәрде, борынгы китапларның мәртәбәсе артты, кадере үсә төште. Ә элгәргерәк вакытларда аларны “тере килеш” җиргә күмә торган иделәр. Азмы яндырдылар, чүплек базларына чыгарып ташладылар? Ә Дамир абый аларны капчыклап җыйган, диләр. Белмим, алай бик җиңел генә җыю мөмкин булдымы икән?

Бүген Дамир Гарифуллин шәҗәрәләр төзү, борынгы нәселләр белән бәйле тарихларны барлау белән мәшгуль. Чыннан да Сарман ягында юк-бар нәселдән чыккан затлар юктыр... Исеме дә Сарман бит аның! Шушындый да җырларга әверелгән берәр төбәкне тарихлар beләдерме икән? Париж, ди-

ярсез бәлки! Әйе, кешелек киңлекләре белән карасак, Сарман кебек үк җырларга әверелгән Париж да бир бит әле! Мәртәбәләре төрле кебек кенә... Сарман... Сарман — Сарман инде ул, Париж түгел.

Сарманга килгән кешеләр каерып печән чаба торган болыннарны, Зәңгәр тауны эзләтеп аптырата. Ә үзенең шул болыннарда йөргәнен, шул ук Зәңгәр таудан яулык болгавын сизми кала. Сарманнан аерылгач кына аңына килә. Безнең татарның акылы төштән соң инде ул, нишлисең бит!

Борынгы китаплар Сарманны Сарман исемле могул кабиләсенә нисбәт итәләр, аларның бик тә садә тавышлы булуларын белдерәләр. Бәлки ул чыннан да шулайдыр? Мондагы авылларның кайсыларында типтәрләр, кайберләрендә борынгы болгарлар, берничәсендә хәтта башкортлар да, казаннар да яшәгәннәр. Кыргызы да, могулы да булгандыр инде, борынгы китаплар алдамаслар, чөнки аларны иманлы кешеләр, гайбәт һәм ялган сөйләүдән уттан курыккандай котлары очып торган галим-голамә язган түгелме?

Өстәлемдә Дамир абыйның дүрт бәйләмнән гыйбарәт «Чыгарсыңмы каршы алырга?» дигән җырлар, шигырьләр, робагыйлар җыентыгы. Яр Чаллыда 2003 нче елда 400 сәхифә күләмендә затлы итеп чыгарылган китап бу. Ул «Чыгарсыңмы каршы алырга?» дигән, 1963 нче елда ук язылган, Валерий Әхмәтшин көйгә салган бөек җыр белән ачыла. Аның сүзләре авторы Дамир Гарифуллин икәнлеген һәрбер татар белсә дә, бер дә шикләнми, халыкныкы, дип әйтерләр.

Бу җыр чыннан да халык рухы, халык моңы, халык сагышы, халык өмете белән сугарылган. Кирәк бит шулай булырга, шагыйрь Дамир Гарифуллинның йөрәге бер мизгелдә татар халкының йөрәге белән бер ритмда тибеп алган да мәйданнарга җыр түгелгән, колактан колакка гына түгел, җаннан җанга, иртәдән кичкә, кичтән иртәгә күчеп, илләрдән илләргә ирешкән. Мин аны ерак Себер авылларында да, Рязянь, Нижгар якларында да, Петербург, Мәскәү калаларында да гади халык авызыннан меӊ тапкырлар ишеттем. Аны шахтерлар да, солдатлар да, төзүчеләр дә, игенчеләр дә җырлый.

Хәтта татар телен ипи-тозлык кына белгән яшьләр авызыннан да ишетергә туры килгәне булды. Бу җыр Дамир Гарифуллин белән Валерий Әхмәтшинның үзләренә куйган бөек һәйкәлләре генә түгел, хәтта Сарманга гына да түгел, бәлки бөтен татар милләтенә дан һәм мәртәбә хисапланыла.

Сарман шул ул! Кая гына барсак да «Сарман җыры» безнең Казан татарының визит карточкасы икәнлеген үз язмышымда ничә тапкырлар татыганым булды. Әлбәттә Сарманны үлмәс җырлары данлыклы итте һәм халыкка танытты. Ә җыр белән дан алу бик азларга гына тәтегән бәхет ул!

Дамир Гарифуллинның «Чыгарсыңмы каршы алырга?» дигән җыентыгының «Беренче бәйләм»е «Җырлап ачыла күңел» дип ата. Мин аннан 56 җыр санадым, күңелемдә һәммәсенең көен искәрергә тырышып карадым, шигъри юлларының яңгырашлы булуларын, сүзләрендә һәм гыйбарәләрендә моң барлыгын тойдым. Аларны язган шагыйрь өчен шул минутларда кичергән куанычшатлыкларымны мәкаләмдә яшереп калдыру намусыма хилафлык китерү булыр иде.

«Кемдер сүз яза, кемдер көй чыгара, кемдер җырлый башлый. Шулай итеп халыкның яңа җыры туа»,— ди Дамир Гарифуллин, шул ук җыентыкның «Җырлы авыл — нурлы ай сыман» дип аталган «Икенче бәйләм»ендә. Ә сүзен ул: «Һәр авылның үз җыры булырга тиешме? Тиеш, минемчә»,— дип башлап китә. Юмарт сүз. Анда Сарман районына караган авылларныкы гына түгел, Арча, Актаныш, Буа, Тукай һәм башка район авылларына да дан җырланган, хәзер ул авылларның да үз җырлары бар икәнлеге күренә. Шагыйрь аларның һәммәсенең үз үзенчәлеген, башкалардан аермалы ягын таба алган. Моңа ничек соңланмыйча калып була? «Юбилейларда әйтелгән багышлаулар» бәйләме дә шул нисбәттән аерым игътибарга лаеклы.

Инде дә «Шагыйрьләрдән сүз котәләр» һәм «Робагыйлар» дип исемләнгән «Өченче» һәм «Дүртенче бәйләм»нәре исә Дамир Гарифуллинның шигърияттәге хикмәт һәм кыйтга жанрларында сүз җәүһәрләрен тезүче әдип булып әверелүен раслыйлар. Алардагы мәгънә һәм формалар да камил, төгәл.

Тик менә ул аларның бер бүлеген нигә «Робагыйлар» дип атады икән — монысын ук аңлап җиткермәдек, чөнки робагый дигән жанрның үз форма таләпләре бар, төрки халыкларда робагыйларны «тарана» дип тә атыйлар. Аларда дүрт фәлсәфи башлангыч, дүрт төрле аңлау юлы, дүрт тарафлы идея бирәмлеге, дүрт хасиятле эчтәлек, дүртле ритм формалары һәммәсе бердәй катнашырга һәм укмашырга тиешләр. Безнең соңгы елларда шигырьләрен робагый дип тәкъдим итүче татар шагыйрьләребез шигърияткә хилаф килерлек гамәл белән шаяртмыйлармы дигән уй күңелне борчыса да, тырышлыкларына мәртәбә диярәк, аларга кул чабарга мәҗбүрбез.

Дамир Гарифуллинның күңелгә бал булырлык олы бер китабыннан егетебез, артык гайрәтләнеп, бер кашык дегет тапкан икән, димәгез, туры юлда да ат абына, «гафу боерамыз»! Әмма дә шагыйребезнең ул кыйтга вә хикмәтләренә соклануыбызны шулай ук яшерә алмыйбыз! Меңнәрчә мисаллар китереп, алар хакында бәхәс кылып шактый сүз куертырга була. Шулай да, Дамир Гарифуллинның үзенә сүз бирик:

Бу дөньяда тормыш үзе
Оста ясый исәпне,
Кемдер җыеп китеп бара
Сиңа дигән чәчәкне.

Яки:

Яшәү әйбәт, күмелсәң дә моң-зарга,
Анысы да булмас күчкәч мазарга,
Гомер дигән нәрсәнең бел кадерен,
Сатып алып булмый аны базарда.

Болармы начар, телгә алырлык түгел? Шушы кыска шигъри юллыкларга шагыйрь яшәү мәгънәсен дә, фәлсәфәсен, шигъриятен дә, прозасын да һәм башкаларын да сыйдырган. Шәрык аһәңнәре Дамир Гарифуллинның шигырьләрендә икенче сулышын ачкан, бу тагын да куанычлы күренеш.

Әдип соңгы елларда шактый кызыклы табышларга юлыкты. Алары аның фәнни ачышларына бәйле. Шулардан

берсе — Таҗетдин Ялчыгол белән бәйле, аның туган төбәге, туган авылы, Азнакай ягыннан булуы хакында… Хәер, болары инде башка тема, башка мәсьәлә!

## ХӘМИТ ЯРМИНЕ ИСКӘ АЛГАНДА

XX йөзнең башында татар фольклористикасы европа фәннәренә хас юнәлешне алды, дисәк, бер дә хата булмас. Узган гасырның урталарында аның яңа фәнни нигезләрен ачыклаган галим Хәмит Ярми иде. Язучы Гомәр Бәширов белән үзара аңлашып алып барган күпьеллык уртак эшчәнлеге дә уңышлы дәвам итте. Һәрвакытта да аяз күк кебек көләч йөзле, зәвыклы һәм зыялы Х.Ярми үзенең замандашлары күңелендә дә бары тик якты истәлекләр генә калдырган. Журналист Мәгъсүм Гәрәев, аны искә алганда, бигрәк тә Хәмит аганың калку буйлы булуына, һәркемгә карата хөрмәтле мөгамәләсенә, сүздә тапкырлыгына һәм көлке сүзгә осталыгына сокланып сөйләгәннәре хәтеремдә яңара. Ул вакытта: «Хәмит ага эчке мәдәнилеге тышка бәреп торган шәхесләрдән иде, бер вакытта да кешегә сүз тәртәсенең башы белән төрттереп китүне үз күрмәде. Моның сәбәбе — аның татар халык авыз иҗатын яхшы белүеннән генә түгел, бәлки шул белемнәрендә үзен тәрбияләвеннән дә килә иде. Халык иҗатының функцияләре күп булган кебек, аның кадере дә зур. Хәмит ага мөгаен халык акылын җыйган әдипләребезнең иң соклангычларыннан берсеннән булгандыр»,— дигән иде олпат әдибебез Мәгъсүм Гәрәев. Аның бу сүзләрендә хаклык зур. Себер егетен казаннар менә шулай хәтерләрендә калдырганнар, милләтебез аңа игелекле хезмәтләре өчен бүгенге көндә дә мең кат рәхмәтле.

Татар фольклористикасында Х.Ярминең урынын төгәл билгеләр өчен фәнни хезмәте елларын, язган әсәрләрен санап, күрсәтеп үтү генә аз. Максатыбыз — аның фәнни карашларының гомуми нигезләрен билгеләүгә һәм татар фольклористикасына керткән өлешен ачыклаудан гыйбарәт. Шуңа күрә татар

фольклористикасының Х.Ярми чорына кадәр үсеш үзенчәлекләрен күзәтү зарурлыгы да туды.

I

Европа фәннәренә хас юнәлештә, ягъни европача фән тибында татар фольклористикасы XIX гасырда ук формалашты, дибез. Аны мәгърифәтче К.Насыйри (1825–1902) эшчәнлеге белән бәйлибез.

Энциклопедист галим буларак К.Насыйри күп өлкәләрдә эш итте һәм фәнни фикерләмәләре нигезен фольклористик карашларга корды. Ул тел, тарих, әдәбият, этнография һәм хәтта география (җәгърафия), тыйбба (медецина), химия һәм математика-физика кебек фән өлкәләрендә дә шушы юнәлештә эш итүне уңышлырак дип күрде. Моның шулай икәнлеген аңлау өчен К.Насыйриның фәнни карашлары белән, мәсәлән, Ш.Мәрҗани (1818–1889) фикерләрен чагыштырып карау гына да җитә. Тарих өлкәсендә һәм дини фәлсәфәдә Ш.Мәрҗани борынгы чыганакларны барлау, алардагы фактларның төрле яклап тикшерелүе, һәммә куелган мәсьәләгә тәнкыйди караш аша хакыйкатькә килү юлын сайлаган булса, К.Насыйри халык авыз иҗаты саклаган хәбәрләрдән чыгып, андагы фактларны барлау ярдәмендә, халык аңы, күзаллавы аша тарихи дөреслекне ачуны төп фәнни методы итте. Моның башкача түгел икәнлеге аларның шушы өлкәләргә караган фәнни хезмәтләренең эчтәлегеннән дә аңлашылып тора. К.Насыйри белән Ш.Мәрҗанинең урам чатында йөзгә-йөз очрашып та үзара исәнләшмичә үтәрлек дәрәҗәдә дошманлашулары да тарихтан билгеле факт. Татарның шушы ике бөек галименең фәнни карашларында принципиальлек саклаулары аркасында бу.

К.Насыйри татар фольклористикасы өлкәсенә караган фикерләмәләрен тарих фәне һәм тел гыйлеме, үзенең әдәби иҗат эшчәнлеге белән бергә үрелдереп алып барды. Халык иҗаты аны бигрәк тә этнографиягә бәйләнештә кызыксындырды. Шунлыктан К.Насыйриның хезмәтләре төрле фәнни өлкәләрне үз эченә ала һәм синкретик характерда иде. Моның сәбәбе турыдан-туры аның татар фикерен европалаштырырга омтылыш белән бәйле булды. XIX гасырда урыс һәм европа тибы фольк-

лористикасы да шушындый ук кысаларда үсте. Фольклор фәне галимнәрне этнографик планда күбрәк кызыксындыра иде. Әлбәттә К.Насыйри да моннан читләшә алмады. Ул хәтта әдәби телне дә, төрки телдән күчеп, Казан теленә нигезләү кирәклеген үзенең фольклористик карашлары тәэсирендә хәл итте.

Х.Ярми исә К.Насыйриның татар фольклористикасы өлкәсендәге эшчәнлегенә мөкиббән киткән галимнәрнең берсе иде. Аның хакында: «Ул бастырып чыгарган мәкаль һәм әйтемнәрдә батырлык, дуслык, турылык, кеше белән кеше арасында булган мөнәсәбәтләрне ныгыту, экиятләрдә кешенең, бигрәк тә хезмәт кешесенең үзенә каршы торган көчләрне үз акылы, үз тапкырлыгы бик оста җиңеп чыгуы турындагы мотивлар үзәк урын тоталар»[1],— дип язып та чыкты. Бу сүзләр хаклы рәвештә Х.Ярминең фольклористика өлкәсендә сайлаган принципларына да турыдан-туры карыйлар, аның халык иҗатына мөнәсәбәтен дә ачып бирәләр.

Х.Ярми чорында татар фольклористикасында халык иҗатына карата ике принципның яшәгәнлеге фәнгә яхшы мәгълүм. Берсе аның татар халкының героик эпосына бәйле булса һәм аны барлауга барып тотышса, икенчесе хезмәт кешесенең тапкырлыгына, булганлыгына һәм уңганлыгына мөнәсәбәттә үстерелде. Беренчесен бигрәк тә Н.Исәнбәт эшчәнлегенә бәйләргә булыр иде, икенчесен Х.Ярми яклап чыкты. Билгеле, бүгенге көндә бу ике юнәлешнең тарихы һәм үзенчәлекләре татар фольклористикасы тарихында җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, шулай да аның шактый кискен алып барылганлыгын шул чор фольклористикасы үсеше белән бәйләнештә яхшы күзалларга мөмкин. Дөрес, Х.Ярми башлангыч фәнни тикшеренү чорында «Идегәй» эпосы белән махсус кызыксынды. Монда да аның кайсы фәнни принципны сайлавы галимнәргә яхшы таныш дип беләм.

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары.— Казан: Татгосиздат, 1848.— Б.105.

Х.Ярминең фикердәше Г.Бәширов булганлыгы хакында искәрткән идек. Алар бергә татар халык әкиятләрен томлыкка туплап, берничә кат бастырып чыгаралар[1]. «Татар халык иҗаты» дип аталган 524 битлек хезмәтнең дә авторларыннан берсе Г.Бәширов[2]. Аларның хезмәттәшлеге аерым өйрәнелергә тиешле вакыйгалардан санала ала.

II

Татар фольклористика фәне XX йөз башында европачалык тибында формалашып җитте, дияргә кирәк. К.Насыйри башлаган эшне Габделгаллэм Фәизханов дәвам итте, Г.Тукай, Х.Бәдигый, Ф.Туйкә, Г.Рәхим, Ф.Сәйфи-Казанлы һәм башкаларның эшчәнлеге татар фольклористикасының аерым филологик өлкә буларак аерымлануына юл ачты. Күпчелек очракта аларның хезмәтләре халык авыз иҗаты материалларын җыюга корылган булуга карамастан, фольклорны халык әдәбияты үрнәкләре югарылыгында өйрәнеп, аны этнографиянең бер өлкәсе сыйфатында тикшерелүеннән-яшәвеннән арындырдылар, әдәби үзенчәлекләре ягыннан бәяләп, татар фольклористикасының әдәби-теоретик нигезләмәләрен барлыкка китерделәр. Аларның бу эшчәнлеген «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә Г.Сәгъди узган гасырның егерменче елларында уңай бәяләп үтә, әмма, татар фольклористикасының алга таба үсеш мөмкинлекләрен күз алдында тотып булырга кирәк, бу өлкәдә шактый күп эшләр башкарасы барлыгын да махсус рәвештә ассызыклый[3].

Ф.Туйкә «Җырлар әхтәрисе» җыентыкларын, Г.Бәдигый «Мәкальләр», «Табышмаклар» китапларын чыгарсалар да, аларда анализларның булмавы галимне борчыган[4]. Татар

---

[1]Татар халык әкиятләре.— Т.1. / Төзүчеләр: *Разин Г.*һәм *Ярми Х.*— Казан: Татгосиздат, 1946. — 318 б.; Шул ук.— 1950, 1956, 1958.

[2]***Карагыз:*** Татар халык иҗаты /*Бәширов Г., Госман Х., Шамов А., Ярми Х.*— Казан: Татгосиздат, 1954.— 524 б.

[3]*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: Дәреслек-кулланма.— Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты, 1926.— Б.189-190.

[4]Шунда ук. — Б.189.

фольклористикасында әдәби-тәнкыйди юнәлештә беренче анализны биргән кеше Г.Тукай санала. Аның «Халык әдәбияты» китапчыгы бүген дә фәнни әһәмиятен югалтмаган хезмәтләр рәтендә аталып йөртелә. «Шура» журналында басылып чыккан Җ.Вәлидинең мәкаләләре һәм Мәхбүбҗамал Акчуринаның «Кыз егълату» мәкаләсе, Ф.Сәйфи-Казанлының «Аң» журналында 1914 нче елда басылган «Халыкның әдәби иҗаты» мәкаләләр циклы, татар халык авыз иҗатына гомуми караш ташлау юнәлешендә булуга карамастан[1], татар фольклористикасының шактый кызыклы һәм куанычлы үсеш алуы хакында сөйлиләр. 1917 нче елгы революциядән соң, фольклорист Ф.Урманче сүзләре белән әйтсәк, «20 нче елларда татар фольклористикасында тагын да җитдирәк казанышлар барлыкка килә»[2]. Әмма бу өлкәдә шактый җитди мәсьәләләрнең күп вакытларга чишелми калдырыла килүләре дә мәгълүм. Шушы чорда барлык тарихи дәверләр каты инкарь астында калдырылган кебек, татар халык иҗатына карата катгый тәнкыйть тә яши, аның урынына яңа дәвер халык авыз иҗаты әсәрләренең барлыкка килүенә зур өмет уятыла. Мондый хәл әлбәттә озакка бара алмый. Халыкның борынгыдан үстерелеп килгән авыз иҗатына хөрмәт белән карау, бу мирасның иҗтимагый тормышта да әһәмиятен төшенеп эш итүне Казанда 1939 нчы елда оешкан Татар тел, әдәбият һәм тарих институты фольклор секторын җитәкләгән Х.Ярми үз кулларына ала[3]. Ул татар фольклорын барлау һәм җыюны Себер якларыннан башлауны мәслихәт күрә[4].

## III

Х.Ярми XX йөз башы татар зыялылары үрнәгендә үскән Төмән егете. Хәмит Ярмөхәммәтов 1904 нче елның 5 нче маенда Казар исемле кечкенә татар авылында Хөснетдин мулла га-

---

[1]*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. — Б. 189.

[2]*Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты: Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек.— Казан: Мәгариф, 2002.— Б.21.

[3]Шунда ук.— Б.21.

[4]Шунда ук.— Б.21–22

иләсендә дөньяга килгән, башлангыч белемен дә әтисеннән алган, унтугыз яшеннән матбугат, язу эшенә тартылган. 1923 нче елдан Төмән губерна комитетының «Юксыллар чаткысы» газетасында аның хезмәт биографиясе башланып китә. Укытучы да, китапханәче дә булып эшли. 1929 нчы елдан ул Халык мәгарифе Төмән округы бүлеге инструкторы, 1930–34 нче елларда Казан дәүләт педагогия институты студенты, аннары аспиранты була. «Кызыл Татарстан» газетасында бүлек мөдире, Язучылар союзы идарәсендә җаваплы секретарь, Татарстан китап нәшриятында тәрҗемәче, редактор булып 1939 нчы елгача эшләгәннән соң, тулысынча диярлек фәнгә тартыла һәм озакламый фольклорчы-галим булып таныла.

Х.Ярми татар халык авыз иҗатын җыю-барлауга, аны фәнни нигездә өйрәнүне тернәкләндереп җибәрүдә зур көч куйган. Татарлар яшәгән төбәкләрдә аның аяк эзләре калмаган авыллар аздыр, мөгаен. Фольклорны җыйнау, аны тәртипкә салу, тикшерү эше гаять катлаулы, тынгысыз җан булуны сорый торган өлкә. Х.Ярми моның белән генә калмый «Татар халкының поэтик иҗаты» дип аталган күләмле монографиясен 1967 нче елда бастырып чыгара. Бу хезмәт бүгенге көндә дә татар фольклористикасы өлкәсендә үзенең әһәмиятен югалтмаган кыйммәтле гыйльми чыганак булып тора. Аны югары уку йортларында фольклористика фәне буенча дәреслек итеп файдаландылар. Дөрес, бүгенге фәнни күзлектән караганда бу монографиясендә галимнәр кайбер җитди кимчелекләр дә күрәләр[1], әмма халык авыз иҗатын гыйльми нигездә гомумиләштерү һәм системага салып өйрәнү ягыннан караганда, ул татар фольклористикасы фәнендә ныклы таяныч була алды.

Филология фәннәре докторы, фольклорчы-галим Х.Ярмине бүгенге көндә дә галимнәр татарның затлы зыялы шәхесләренең берсе буларак искә алалар. Ул чын мәгънәсендә эшенә бирелгән, хезмәтләренең татар мәдәнияте үсешендә аеруча әһәмиятле булачагын күз алдында тотып эш иткән гыйлем иясе. Карьера, үз мәртәбәсе хакында уйлауны читкә куеп, Х.Ярми

[1]***Карагыз:*** *Даутов Р.Н., Нуруллина И.Б.* Совет Татарстаны язучылары.— Б.571.

халыкның акылына, зирәклегенә сокланып яшәгән шәхесләребезнең берсе сыйфатында хәтерләребездә саклана.

Яңа гасыр башларында безгә Себердә еш булырга туры килде. Х.Ярминең якташларына карата хөрмәтебез һәр барганыбыз саен арта торды. Аларда сакланган борынгы китаплар тарихыбызны, мәдәниятебезне башкача аңларга этәрде. Ә бу әле башланып кына килә торган юл сыман тоела.

## ОСТАЗ

*(Нил Юзиев хакында истәлек)*

### I

Нил Гафур улы Юзиевнең үзе белән танышканчыга кадәрле шәхесе хакында хәбәрдар, галимлеге турында ишетеп тә һәм китапларын укып та белә идем. Казан дәүләт университетында студент елларымда хезмәтләренә һәрдаим мөрәҗәгать итәргә туры килде. Фәнни тикшеренүләре тирән һәм мәгълүматлы, поэтиканың катлаулы мәсьәләләрен аңларга ярдәм иткәнлеген профессорларыбыз да еш искәртәләр иде. Бигрәк тә татар шигърияте, шигырьнең «тууы» һәм «ясалуы» кебек каршылыклы һәм бәхәсле төшенчәләрне ачыкларга аның китапларыннан шактый әһәмиятле үзенчәлекләрне өйрәнү мөмкин булды. Күп кенә лекцияләрдә тыңланылган фәнни күзәтүләрнең дә Н.Г.Юзиев хезмәтләреннән алынганлыгы искәрелә барылды. Галим буларак аның мәртәбәсе голамә каршында зур иде. Ул эшләгән юнәлештә поэтика мәсьәләренә багышланган хезмәтләрнең, дөнья күләмендә караганда да, бик сирәк очравы халкыбыз өчен горурлану хисләрен тудыра иделәр. Шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк, поэтика буенча язылган күп кенә хезмәтләр Аристотельгә нигезләнеп, бер-берсен кабатлап, үзара охшаш һәм бертөрлерәк язылган булсалар да, Н.Г.Юзиев мәсьәләгә бөтенләй дә үзенчәлекле яктан килеп, кызыклы фәнни тикшеренүләр уздырып, шигъриятнең асылын яңача һәм кабатланмас юнәлештә ачып бирүгә ирешкән иде. Бигрәк тә әдәби иҗатка мөкиббән киткән студентларның һәркайсының

шәхси китап киштәлегендә аның хезмәтләрен күрергә туры килде.

Ул вакытларда без, студентлар, мөмкинлек булган саен, һәртөрле әдәби кичәләргә, тантаналарга ашыга идек. Җитмешенче еллар ахыры, сиксәненче еллар башы. М.Х.Хәсәнов, М.З.Зәкиев кебек галимнәрне трибунада, президиумда күреп кала алуыбызга сөенгән чаклар. С.Хәким, Х.Туфан, Н.Арыслан кебек шагыйрьләребезгә соклану хисе йөрәкләребездән ташып чыга. Алкышларны кызганмадык. Хәзер уйландыра, данлы шәхесләребез булган. Соклана да белгәнбез. Бераз сәеррәк тә тоелганбыз. Дөресрәге, хисләр ташкынын соклануга әверелдерә алганбыз икән.

Университетны бетергән елны мин аспирантурада калдырылуымны белдем. А.Г.Әхмәдуллин чакыртып алды да, шундый фикер барлыгын, ә кафедрада мәсьәләнең әлегә куелмаган булуын төшендерде. Әмма бу тәкъдимнән баш тартырга теләгәнемне аңа яшерми әйтергә уйладым. Ул вакытта ук үземне әдәби иҗатка багышлаган идем инде. Фәнгә китү ниятемдә дә юк. Авылга кайтып, укытучы булып, шул ук вакытта әсәрләр дә язармын, ә бәлки район гәҗитәсендә эшләрмен дип йөрим үземне. Дусларым: «Син нәрсә, кире кага күрмә, юләрләнденме әллә! Мондый мәртәбә кемгә тәтегән әле!»— дигәч, ә кайсылары исә, киресенчә, баш тарта калсам, үзләрен минем урынга тәкъдим итәргә үтенеп киңәшләр бирделәр. Миңа әлегә барыбер иде. Кызганыч, гыйлем дөньясына китсәм, әдәби иҗат эшчәнлегемне фәнгә корбан итәргә тиеш булачакмын. Бәясе артык зуррак шул.

Азат Гыйльмуллович кабат чакыртып алды. Аспирантураны Нил Гафурович җитәкчелегендә узачагымны искәртте. Данлыклы шагыйрь Илдар Юзеевнең абыйсы икәнлеген дә исемә төшерде. Уйланырга кушты. Язмышымны үз агышына салдым. Ни булса, шул... Хәерлегә! Эһ, шәхесем тирәсендә кайбер укытучыларымның сүз куертуларын да ишеттереп торучылар табылды. Кандидатурамны төрле яклап үлчиләр дә, бәялиләр дә һәм кисәләр дә икән. Хәлләрнең алай ук киеренкелеген белгәч, тәгаенлап, калырга булдым.

Инде Нил Гафурович белән кабинетында таныштык. Елмаеп кына сөйләшә. Калын кара чәчләрен җилкәсенәчә үстергән, вакыт-вакыт аларны артка сыпырып куя.

Ни фикерләр белән калгандыр, белмим, әмма мин канәгатьсез чыктым. «Нәрсәгә кирәк булды әле миңа бу фән дөньясы?»— дигән соравым һаман да күңелемнән китми, бер авыр боз кисәге кебек бәгырь дәрьясында калка-чума һаман да йөзә иде. Җитмәсә җәйге хәрби лагерьларда (җәй суык яңгырлы булды) салкын тидергәнмен, туктаусыз авырыйм. Имтиханнарга әзерләнеп тә булмый, күзләрдән яшь ага, температура. Хәер, аспирантурага керә алмасам да исем китмәячәк иде. Әмма бер-бер артлы алынган яхшы билгеләр генә кире чигенергә ирек бирмәделәр.

II

Фәннең кырыс мантыйк дөньясы булуы җәмәгатьчелеккә яхшы мәгълүм. Монда туктаусыз көрәш бара. Кайберәүләр хәтта андый тартышлар белән мавыгып та китәләр. Хакыйкатьне табу өчен әһәмияте зур булган бу эзләнүләр «көрәшен» көнкүрешкә күтәреп чыгалар һәм аны үзара тарткалашуга әвереллдереп җибәрәләр. Хәтта шактый тәҗрибәле галимнәр дә бу вәсвәсә тозагында калалар. Мондый интригаларда күбрәк яшьләр харап була. Нил Гафуровичның иң тәүге киңәше дә шушының белән бәйле иде. Гаугалардан мөмкин кадәр читтә булу һәм үзең дә җәнҗал куптармау. Һәр катлаулы мәсьәләне чишү юллары бар, һәр бәхәсне хәл итү мөмкин икән...

Дөресен әйтим, бу хатирә-истәлекне язуы миңа нигәдер авыр. Остазымның таләпчән галим булганлыгын яшермим. Хикмәт анда гына да түгелдер. Ул үз фикере булган кешеләрне хөрмәт итә иде. Зур галимнәрдән Гали Халит һәм Рашат Гайнанов та ни сәбәпледер миңа үз укучыларына гына тәтегән хөрмәтле мөнәсәбәтләрен күрсәтә тордылар. Моны остазыма карата яхшы бәяләмәләре аркасында дип белә идем. Әмма аларның, шул ук вакытта, Нил Гафуровичка оппонентлар да икәнлегенә игътибар ителмәгән. Остазыма һәр эзләнүләремнең нәтиҗәсен сөйләргә килгән саен, хәтерлим, аның бүлмәсендә

һаман да алар була һәм кызу-кызу бәхәсләренең шаһиты хәлендә калырга туры килгәли иде.

Н.Г.Юзиев татар әдәбият фәненең координацияләүче акылы мәртәбәсенә күтәрелгән галим иде. Ул җитәкчелек иткән елларда биш томлык әдәбиятыбыз тарихы язылды, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ һ.б. язучыларыбызның күп томлыклары төзелде. Болар һәммәсе дә галимнәрнең фидакарь хезмәтенең нәтиҗәсе иде. Югары уку йортларының һәм фәнни үзәкләрнең галимнәрен, язучыларны бергә туплап, уртак максатка юнәлдерү эше олы авторитет иясе булуны таләп итә. Нил Гафуровичка шунлыктан туктаусыз гыйльми эшләр белән шөгыльләнергә туры килә иде. Җитмәсә аспирантлар белән җитәкчелек итү, яшь галимнәрне әзерләү. Ә алар, яшьләр, килә һәм, канат чыгаруга, башка «гыйлем ояларына» китә торалар...

Аспирантураны тәмамлаган елымда Нил Гафуровичны фәнни хезмәтләре өчен орден белән бүләкләделәр. Бу вакыйга аның яңа бер каршылыклы төркем буларак оешып маташкан оппонентларын кузгатты. Бәхәсләр гаугага әверелде. Дөньялык бер мизгелдә буталып беткән хәлдә калды. Остазына орылган «күсәк»нең каты башы укучыларына да тими кала димени?

III

Хәвеф белән килгән караңгы болыт дөньялыкны үзенчә «тигезләп», бәлаләргә дучар итеп уза икән ул.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият бүлеге икегә аерылып, текстология һәм кулъязмалар лабораториясенә Н.Г.Юзиев мөдир итеп билгеләнде. Мин дә шул бүлектә идем. Безгә яңа ремонтланган бинадан яхшы бүлмәләр бирделәр. Нил Гафурович, гадәте буенча, һәркайсыбызга кереп, фәнни эзләнүләребезнең ни дәрәҗәдә һәм кайсы юнәлешләрдә барганлыгын белешеп чыга торган иде. Киңәшләрен бирми калдырмый. Әмма ул аларны көчләп такмый, фикер итеп кенә әйтә.

Бүлек утырышларын Нил Гафурович элеккечә зур әзерлек белән оештырды. Тәмамланган фәнни хезмәтләрне һәммәбез-

дән укыттыра, фикерләр тупларга вакыт бирә. Утырышта һәркем үз сүзен әйтергә, килешмәгән мәсьәләләрне ачыкларга тиеш. Ул утырышларга һәммәбез зур әзерлек белән килә, бәхәсләр дә куба. Ә ахырда Нил Гафурович үзенең фикерләрен әйтә һәм тикшерелгән хезмәткә бүлекнең биргән бәясен конкретлаштыра.

Әдәбият буенча һәр фәнни теманың эшләнеше һәм өйрәнелеш дәрәҗәсе Нил Гафуровичны һәрдаим кызыксындырганын белгәнлектән, галимнәребез һаман да эш белән, гыйльми эзләнүләр белән мәшгуль иде. Бу — туксанынчы еллар башы. Җәмгыятьтә һәм илдә барган үзгәрешләр фән дөньясына да тәэсир итми калмадылар.

Фәнни эзләнүләрнең әһәмияте кими башлады. Перспективалы күп кенә темалар да «ябылгалады». Хәзер, шушы XXI гасыр башында аларның кирәклеге һәм әһәмияте яңадан көн тәртибенә басты, әмма, кызганыч, ул вакыттагы олы галимнәребезнең күбесе арабызда юк инде. Туксанынчы елларның җимергеч «җиле» тынычланырга маташканда гына моны сиземли башладык бугай?

Нил Гафурович үз бүлеге галимнәренә фәнни-тикшеренү эшендә зур иркенлекләр куя торган иде. Ул беркайчан да ашыктырмады, әмма билгеләнгән вакытка хезмәтеңне җитештерә алмавыңны да өнәмәде. Аның куйган иркенлекләреннән теләгәнемчә файдалануны тәртипсезлек санаганлыгымнан, һаман да фәнни-тикшеренү эшләремне алга җибәрергә тырыштым. Әллә никадәр борынгы язмаларны, документларны, гәҗит һәм журналларны өйрәнеп чыгылган. Фәнни эзләнүләрдә чыннан да иркенлекнең әһәмияте зур аның. Галим булып җитлегү бер-ике көнлек белем казану гына түгел, ул гомер буена туктаусыз алып барыла торган олы хезмәт. Нил Гафурович куйган иркенлекләрдән нәтиҗәсез файдаланган вакытларым булганлыгы бер дә хәтеремдә калмаган. Ә менә ашкынып эшләү, шуның белән бергә ашыгулык галәмәтләре күзәтелгән. Андый хаталануларымны остазым гафу итә кебек иде.

Нил Гафурович бер тапкыр үзе белән мине Минзәлә, Сарман, Әлмәт якларына археографик экспедициягә дә алды. Фәнни конференцияләрдә дә очраша идек. Әмма ул бервакытта да

миннән үзенең иярченен ясамады. Фикердәше булу өчен дә лаек түгел идем. Шунлыктан күп вакытта аннан читтә кала бирдем.

IV

Аспирантураны бетергәннән соң, кандидатлык диссертациямне яклагач, мине Казан педагогия институтына эшкә өнди башладылар. Бу хакта белеп алган Нил Гафурович моңа каршы чыкты һәм бүлектә калуымның мәслихәт икәнлеген белдерде. Язмышымның шушылай хәл ителүенә бераз үпкәләп тә йөрдем. Шулай да үз урынымда калып, әле шактый эзләнүләр алып барырга мөмкинчелек барлыгын аңладым һәм остазымның сүзенә колак салдым.

Казандагы Габдулла Тукай музеена мине директор итеп куячакларын белгәч тә Нил Гафурович каршы чыкты. Безнең сөйләшү озак дәвам итте. Элекләрне кем шакып керсә, аңа урын түрдән иде. Бу юлы остазым һичкемне кабул итмәде. Кинәт боегып һәм авыраеп калды. Минем белән инде министрлыкта сөйләшү булганлыгын, ризалык та биргәнемне, «биек таулар» вәгъдә итүләрен дә әйттем. Остазым, күзләремне ачарга теләп, ул вакытта бик хаклы сүзләр әйткән булган: «Алар шулай инде, әүвәле әлләниләр белән кызыктыралар, аннан соң: «Андый сүзнең булганы юк!»— дип кире кагалар»,— диде. Сүзләренең хаклы әйтелгәнлеген соңыннан күп тапкырлар, кат-кат искәрдем.

Шушы 1993 нче елда «Тукай җәмгыяте» оешты. Аны юрист Гарипов Равил Гарипович, эшмәкәр Рөстәм Закиров белән башлап йөрдек. Язучылар һәм галимнәр тупланды. Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, Тукай бүләге иясе, галим Нил Гафуровичны шушы җәмгыятьнең президенты итеп сайлап куйдык. Ул «Тукай энциклопедиясе» буенча эш җәелдерде. Һәр елны апрель аенда «Тукай укулары»н оештырды. Чит иллärдән килгән галимнәр белән дә музейда еш була иде. Һәрвакыттагыча сабыр, тыныч, уйчан...

Нил Гафурович мәгънәле шаяртулар, җор телле сүз белән сөйләшергә ярата иде. Музейга эшкә китсәм дә, бүлек белән бәйләнешне өзәргә ирек бирмәде. XII гасыр шагыйре Сөләй-

ман Бакырганиның иҗат мирасын барлауны һәм әзерләп чыгаруны йөкләде. Аны тәмам итүгә, «Татар шигърияте һәм мифологиясе» дигән темага фәнни-тикшеренү эшен тапшырды. Мин болар өчен аңа рәхмәтле идем. Аркадашларым исәпләнелгән галимнәрнең кай вакытларда, араларында юклыгымнан файдаланып, үземне эт итеп салуларына көенә торган иде. Ә татар фәне дөньясында андый «изгәләүләр» булгалап торганлыктан, моңа алай ук күңелне ватмаска кирәклеген дә искәртми калмый иде. Әлбәттә, ул хәлләр онытылмый, никадәр генә яхшы мөнәсәбәтеңне сакларга тырышсаң да, кемнең кемлеген хәтер искәртми калмый икән шул...

V

Нил Гафурович сырхауханәгә керде. Озак авырды. Аннан чыккач, мине чакыртып алды. Бардым, Илдар абый Юзеев белән чәйләп утыралар.

— Кара авыруга даруын тапканнар икән, Фәрит! — диде Нил Гафурович.

Илдар абыйга карадым.

— Әйе, тапканнар! — диде ул да.

Күңелләргә шатлык-сөенеч тулды. Болай да чандыр Нил Гафурович суырылып калган. Хәзер авылга китеп, җәйне шунда уздырырга, тәмам тазарып кайтырга исәбе. Шулай да минем фәнни эшнең торышы белән дә кызыксынды. Язачак хезмәтемнең план-проспектын ул кышта гына бүлектә тикшергән идек. Нил Гафурович канәгатьсезлеген белдергән иде. Бу юлы да шуны кузгатты һәм:

— Борынгы шагыйрьләрнең иҗатын, биографиясен ачыклау юлында эшләреңне дәвам исәң иде. Аның менә шулары кыйммәт. Шушы анализларыңа бәйләп шигъри символиканың да эчтәлеген ачарга омтыл! — диде ул, киңәш биреп.

Мин фәнни табышларымны бәян иттем.

Мактамады, әмма:

— Дөрес! — дип ассызыклады. — Дини мифология һәм мистика белән бәйләп тикшерергә кирәк. Нәтиҗәсе көтелмәгәнчә һәм ачышларга бай булачак!

Нил Гафуровичны артык сүз белән ялыктырырга теләмәдем. Төшләр символикасы буенча хезмәтемне тәмамлавымны, тагын да бүтән юнәлештәге тикшеренү планнарым барлыгын сөйләп тормадым. Ул һаман да эшкә дәртләндерә бирде. Шигырьләрем хакында сүз чыкты. Нил Гафурович мине бары тик фәнгә генә хезмәт итәргә тиеш дип белә иде...

Җәй ахырлары күп төрле мәшәкатьләре белән килеп җитте. Музейда кырыкмаса-кырык төрле эш иде. Нил Гафуровичның мине чакыртуы хакында хәбәр биреп берничә аркадашым әйтте. Көне дә аталган иде. Әле дә Нил Гафурович Казан артындагы Сасмак авылында ял итә икән. Остазыма гыйльми эзләнүләрем хакында отчет бирү өчен язмаларымны туплап куйдым.

Иртәгә очрашабыз дигән көн...

Әмма аның вафат булуын шалтыратып әйттеләр. Күкне томалаган болытларның күзләре бүселеп китте, коеп-коеп яңгыр яварга тотынды.

Нил Гафурович Юзиевнең вафаты хакында телевизордан да хәбәр иттеләр. Мәрхүм үзенең гүре итеп Сасмак авылы зиратын сайлаган икән.

Җеназада мәртәбәле галимнәр сүз алып сөйләделәр. Нотыкчылар арасында аның оппонентлары да бар иде. Өстән һаман да туктый алмыйча яңгыр яуды.

Нил Гафуровичны озатырга халык авыллары белән чыкты. Сасмак авылы зиратының туфрагына гыйлем энҗесе яшеренде. Ул көнне күкләр тыела алмыйча онытылып еладылар да еладылар...

*9 май, 2000.*

# ХӘЙДӘР

*(Мин белгән язучы Гайнетдинов Хәйдәр)*

I

< Кызыл муенса.>

1982 нче елда Хәйдәрнең (Хәйдәр Гайнетдиннең) «Ут теле» исеме белән шигырьләре җыентыгы басылып чыкты. Ул вакыйга студент елларымда булды. Тулай торакта шунда ук сүз таралды. Җыентыкны күрәсе, сатып аласы, укыйсы килү теләге белән күпләр яна башлаганнардыр? Мин дә китап кибетенә йөгердем. Әмма җыентыкны сатып алып бетергәннәр икәнлеген ишеткәч, соңаруым өчен күңелдә хәсрәтләнү күләгәсе барлыкка килде. Шушылай ул китапны башкалардан алдарак укымый калырмынмы икән дип тә борчылдым. Юкка булган. Ул заманнарда кулда яхшы китапны булдыру зур бәхет санала иде. Икенче көнне килүемә, киштәлектә «Ут теле» бар иде.

Сатып алдым, шул кичне үк укып та чыктым һәм күңелдә бу китапны «Кызыл муенса» дип атау теләге туды. Моның сәбәпләре дә бар иде. Беренчедән, аның һәр шигырендә куплетлары гүяки аерым-аерым яшиләрдер сыман тойгы калдырдылар. Икенчедән, аларны үзара ниндидер сизелмәслек җеп кенә бергә җыеп, бер шигырь ясап торадыр төсле. Ул җеп менә-менә өзелә дә, шигырь-муенсалар куплетларга-төймәләргә таралалар да китәләр. Өченчедән, монысы инде «кызыл» булуларына хәйранлыктан, шигырьләре һәммәсе дә дөрес, тәртипле, ягъни коммунистик тәрбия идеологиясенә аңкытылганнар. Ә югыйсә, «Яшә партия — яшик без!» ише лозунглар да аларда, социалистик хезмәт батырлыгын данлау да юк, әмма коммунистик хис эченнән-тышыннан аңкып тора. Шуңа да «Кызыл муенса» инде ул.

Шул төртек фикерләр күңелдә ясалдылар.

Ә мин әле яшь, максималист егет. Үземнең фикеремне һәр кешедән, һәрнәрсәдән өстен куючы беркатлы адәм баласы аның шигырьләрен әлбәттә үз буразнамнан чыгып, мөгаллимнәрем өйрәтмәләре нигезендә бәяләдем. Менә хәзер, вакытлар үтеп, мин-минлек буразнасы арка-сырт тузаны белән

каплангач, хәтер тутыкса да, шигырьләрен кабат укыганда шул хаталарым исемә төштеләр дә, ул «мирасым» сынык калай кисәкләре сыман ялтырап җаныма тия башладылар. Алардан котылу өчен тәүбә итәргә, үзләрен сөйләп бирергә телимен. Ахмак булуымны сез дә аңларга тиешледер, әгәр дә тәүбәм кабул ителсә? Адәм баласының бәхете тәүбә итә алу мөмкинлегендә түгелме?

Әдәбият идеология коралы буларак үзен күрсәткәндә — укучыларын дөрес яшәү серләренә өйрәтә башлый. Совет әдәбияты шул юлда туды, үсте һәм бер дәвер эчендә «картаеп», үз өйрәтмәләрен үзе ашый башлады. Әдипләр моны сизеп-аңлап тордылар. Бервакыт Гариф ага Ахунов: «Үз әсәрләремне үзем ашап бетереп китеп барам бугай инде»,— диде. Нигәдер Аяз абый Гыйләҗевне дә исенә алды, шул санга кертте. Мин аны аңламаганмын. Ул үз идеалларына каршы күтәрелә баруынмы искәрткән, әллә инде шул идеаллар яшәүдән туктаугамы борчылган? Бу сораулар хәзер дә борчый күңелне.

Хәйдәр журналист һәм шагыйрь, язучы буларак, әлбәттә тулысынча диярлек, идеология вәкиле иде. Әмма ул үзен шул чакларда да коммунистик идеология хезмәтчесе дип санамаган. Безнең татар дөньясында демократия тойгысы һәм хисләре чирләшкә, зәгыйфь, мескен бала сыйфатында дөньяга килде, баздагы бәрәңге сабагы кебек үрмәләп китеп үскән булды. Аның һәр ягында коммунистик идеология һәм шул идеологиянең куәтле күләгәләре иде.

II

Минем хаталы уйлавымда Хәйдәр (мин аны Хәйдәр абый дип йөрттем, югыйсә) телгә усал, төгәл, иң хәтәре — батыр иде сыман. Аның әйткәннәрен күпләр күтәрә алмаганнар кебек исемдә. Катгый итеп әйтелгән төгәл сүз кешенең үзенә кайтарыла. Хәйдәрнең иң көчле шигырьләреннән берсе «Әйтер сүзем» дип атала. Аңа кереш буларак, эпиграф итеп Муса Җәлилнең «Соңгы җырым палач балтасына башым куйган килеш язылa» шигъри юллары алынган.

Эчтәлеге дә гадидер сыман. Лирик геройның тел очында әйтер сүзе тора, әмма ул үзелмичә «сабагында калган җиләк кебек» кипкән. Сусыл чагында шуны замана авыз иткән булса, уйнап-көлеп алга омтылачак икәнлеге дә белдерелә. Әмма ул сүз әйтелми калган. Хикмәт шунда ки, әгәр дә ул сүз әйтелсә, шул әйтелгән сүзенә лирик герой кол булачагын белә, әйтми калдырса — ул әлегә аңа үзе хуҗа. Заман уза, ә сүзе лирик геройның тел очында кала.

Торгынлык чоры интеллигентының, тулы бер чор шәхесенең холкы да, сабырлыгы да, һәлакәте дә чагылдырылган шигырь бу. Хәйдәр дәвер һәм заманны күңеле аша уздыра, тоя, хәтта үзгәртергә мөмкин дип санаучы затлы әдипләребезнең берсе булды. Бу шигырендә аның лирик герое кызыклы күзәтү ясый: «Ак күбеккә баткан заман чаба, бу болытлар, гүя, ап-ак күбек»,— ди ул һәм шигырьнең беренче аккордында белдерелгән шул сүзләр ахырда әсәрнең фәлсәфәсен төйнәп кую өчен хезмәт итә: «Узып китте заман, карап калдым, баш очында һаман ап-ак күбек...»

Шагыйрьләр хыялны, өметне, хиснең сурәтен тасвирлаганда болыт символына еш мөрәҗәгать итәләр. Бу шигыре белән Хәйдәр, заманалар узуга карамастан, хыялның, өметнең, хиснең яшәешен кешеләрнең күңелләреннән югалтмавын тасвирлый. Аның лирик герое — идеалист, аңардан тәүфыйк, мәртәбә, акыл бөркелеп тора. Әмма ул үз сүзенә үзе кол булудан курка, аны әйтми калдырып, замананың «уйнап-көлеп чабуына» ярдәм итмәгән, ягъни шул кирәкле, тиешле сүзен күңелендә җыеп, сүзенә, шул рәвешле үзенә хуҗа булса да, тик ахырда барыбер шул әйтми калдырган сүзенә коллыкка төшкән түгелме?

Хакыйкатьтә шулай килеп чыга да: күңелендәге сүзен кеше әйтергә тели, әмма белдерми калдыра, кат-кат үлчи, нидәндер курка, ахырда шул әйтелмәгән сүзе аның үзен үк юк итә. Бары тик сүздән гамәлгә күчү генә кешене коткарып кала ала. Бу әле әйткән сүзеңдә тору, аңа тугыры калу гына түгел, бәлки рухыңны сүз авырлыгыннан азат итү юлы да.

Хәйдәр сүз кешесе иде. Әмма сүздә талымсызлык күрсәтмәде. Гадел хөкем итәме, юкмы — аңа бу хакта

искәртергә туры килә иде — алар аны борчымый, ул бөеккә әверелә барды. Ак болытлар биеклегенә ирешү юлында кирегә борылырга теләмәгән шәхес гаделлекне үз күз күреме белән үлчи.

III

Татар шигъриятенең XX йөздә үсеше чын асылы белән иң күркәм бакчаларны хәтерләтә. Бездә әдипләр шул дәвергә хас булганча бишьеллыклар, унъеллыклар белән буын-буын килделәр. Аны, дөресен әйткәндә, тормышны бишьеллыкларга бүлеп өйрәткән коммунистлар партиясе карарларын тормышка ашыруда төп идеологик коралларның берсе саналган матбугат һәм нәшрият шулай итеп күрсәтә иде. Алар һәр бишьеллыкка яңа әдипләрне ачарга, мәйданга чыгарырга үзләренә йөкләмә алганнар, алар да иртәрәк җитешкәннәрне соңартырга, борынламаганнарны ашыктырырга тиеш иделәр. Шул рәвешле әдипләр дә бишьеллык яки унъеллыклар булып «тудылар». Алтмышынчы елгылар илленче еллар ахырында демократик хис белән бай хәлдә романтик рухны балкытып аваз салдылар. Җитмешенче елгылар буыны узылган авырлыкларда ничек исән калынган икәнлекне фәлсәфә итте, сиксәненче елгылар сабыр интеллигент холкына сокланды, туксанынчы елгылар, ягъни шул чорда үз шигъри фәлсәфәләрен булдыручылар һәм әдәбият мәйданын яңа сүз белән тотучылар борынгы тарихыбызны, туган телне саклау һәм үстерү, мөстәкыйльлек хәсрәтен чигүне тасвирлауны, шушылардан фикер коруны кадер ясадылар. Әмма болар арасында алтмышынчы елгылар, демократия һәм романтика хисе белән бергә, һәр чорның шигъри буыны тәэсире белән үзгәрә, камилләшә баргандай тоелып, мөкатдәс хакыйкать бәянчеләре булудан туктамадылар. Якты күләгәләре сусаган ил туфрагына ләззәтле дым вәгъдә итә торды.

Хәйдәр сиксәненче еллар буынының иң талантлы шагыйре иде. Алар бер-берсен иҗатта танымаучы, тормышта санга алмаучы, тәнкыйтьтән аек акыл, затлы бәя, дөрес үлчәү өметендә яшәүчеләр булып тарих сәхнәсенә шәхси драмаларын трагик герой сурәтендә уйнап кереп киттеләр. Бу иҗтимагый

һәлакәтебезнең ачык тамашасы иде. Ә тамашачы хәлендә калганнарга бары тик тетрәнү, шуның белән бергә күңел юанычы халәте килми мөмкин түгел. Һәм шулай булды да.

Хәйдәр белән 1990 нчы елның июнь ахырында таныштым. Аңынчы мин аны күреп-танып белмәдем. Ул вакытта завод эшчесе идем. Казан йортлар төзелеше комбинатында өченче цехта формаларга салучы, аңа өстәмәдә төзелештә хезмәт куючы, алар белән бергә журналистика һәм әдәбият белгечлекләре буенча филология фәннәре кандидаты, тагын да шигырьләре, хикәяләре матбугатта күренгәләп алгалаган кешеләрдән булсам да, күңелем тулы сагыш уты яшәгән чаклар бу. Очраклы рәвештә генә «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә кердем. Кичке вакыт. Журналистлар таралышырга өлгергән. Госман Садә һәм Хәйдәр Гайнетдинов бүлмәсенә уздым. Йомышым да юк иде сыман. Редакциягә менә-менә яшь каләмчеләр кунакка килергә тиешләр икән. Өметле талантлар! Андыйлар ниргәсендә йөрергә бер дә насыйп булмаганлыктан, тизрәк китү җаен уйладым. Радиодан Хәйдәр «Пәйгамбәрләр тарихы»н газеталарында бастырырга вәгъдә иткән. Ә аннары галимнәр арасыннан бу эшне башкарып чыгарырлык кешене эзләгән, муллаларны йөреп чыккан. Ышандырып, җаваплылыкны үз җилкәсенә алырлык һичкемне табалмаган.

Беренче соравы да шул булды:

— Пәйгамбәрләрне беләсеңме?

Аның күзлеге калын, олы иде. Күзләре шарлар булып, бөтен бар йөзен каплап алгандай тоелды. Җавабым җиңел һәм гади чыкты:

— Беләм!

Ул шунда ук:

— Бер айдан язып китер!— диде.

— Ярар,— дидем.

— Вәгъдәме?— диде ул, ышаныргамы-ышанмаскамы кебек хис белән янган хәлендә. Инде күзләре дә кечерәеп, йөзенә дә елмаю чыкты.

— Ярар,— дидем.

— Булды, сөйләштек!— диде ул. «Күрербез», имеш.

Сүз беткәнне аңлап, әлегә кемнән әмер алганымны да төгәл генә белмичә, бүлмәдән чыгу ягына атладым. Хушлашасы идем.

— Тукта әле, болай гына китәсеңмени?— диделәр.

Тыелып калдым. Ни хакында сүз барачагын көттем. Әмма алар икесе дә чыгу ягына атладылар. Коридорның тәрәзәле очына килдек. Дөнья барышын сөйләшеп алу булды. Госман Сәдадән:

— Ул абый кем?— дип, «Хәзер киләм» диярәк киткән кешене сорадым. Гаҗәпләнде.

— Шушы бит инде гений Хәйдәр!— диде ул.— Аны да белмәскә!

Хәйдәр әйләнеп тә килде. Әмер дә итә башлады:

— Балалар күтәрелә. Алар белән очрашуга кирәбез. Без очрашуны алып барырбыз, сөйләрбез. Сиңа да сүз булыр, пәйгамбәрләрнең берәрсе хакында кыскача гына хәбәр бирергә әзер тор!— диде ул миңа.

— Ярар,— дидем, гадәтемчә гади һәм җитди төстә.

Ул көнне очрашуда Йосыф пәйгамбәргә бәйле вакыйгалардан бераз сөйләдем. Балалар үз әсәрләрен укып сөендерделәр. Редакция хезмәткәрләре белән очрашулары озакка сузылмады. Сәгать эчендә таралыштык та.

Бер айдан «Пәйгамбәрләр тарихы»ның газета вариантын редакциягә китердем. Хәйдәр, кулына язмамны алып, авырлыгын үлчәгәндәй итте дә, өстәл тартмасын ачып, аны шунда салды, япты. Аннары:

— Ярар, булган бу!— диде.

Мин үз эшемә киттем.

Вакытлар узгач, «Пәйгамбәрләр тарихы» китабым басылып чыккач, интервьюлар биргәнемдә һәм сүз ара сүзләр чыкканда Хәйдәргә бу эшкә юнәлтүе өчен рәхмәтләремне әйтүне гадәт иттем. «Пәйгамбәрләр тарихы»ның газета варианты «Яшь ленинчы»да басылып чыккан вакытта Хәйдәр анда эшләми иде инде. Аңа рәхмәтләрем язмаларым дөнья күрүдә төп рольне башкарган мөхәррирләрне бәлки кимсеткәндер, алар алдында соңарып булса да гафу үтенәм. Кичерә күрегез!

IV

<Мажаралар кешесе.>

Хәйдәр авантюралар остасы кебек тә иде. Аны, турыдан-туры, ул авантюрист дип әйтеп булмый, хата чыга. Хәйдәрнең авантюралары бары тик мажаралык белән дөньяны ямьләндерергә омтылышыннан килә иде, дисәм, ялгышмамын. Баштан ук тирәнтен уйлап, әмма импровизацияләргә урын калдырып, асылда акыллы шуклыкка корылган андый гамәлләрен ул ышаныч, мәртәбә белән оештырып алып бара белде. Әлбәттә мажара-авантюралардан могҗизалар да көтелә. Бу очракта шушы мажарада катнашучыларда сабырлык, белми калучанлык тойгысы да сорала. Кеше юләргә калырга теләми, шунда ук саклану инстинкты уяна һәм мине ахмакка калдырырга итә бу дип уйлый. Шул сәбәпле күп вакытларда мажараларның ахырына кадәр барып җитә алмыйча, шул мажарадан могҗиза килеп чыкмый кала, уеннан уймак кына табыла. Хәйдәрнең могҗизалар коруы аның шуклыгыннан килгәнгә, дуслары аның нәрсә уйлаганын тиз төшенә иделәр. Үзләренең дә шул уенга катнашып китәргә осталыгы җитә.

Хәйдәрнең мажара-авантюрага бару җаен белүче кеше икәнлегенә беренче танышуда ук ышанырга туры килде. «Пәйгамбәрләр тарихы»н яздырырга теләп галим-голамә белән элемтәгә керүендә үк аңа бу эшне башкарып чыгу өчен кимендә биш ел вакыт кирәклеген, әзерлекле кешеләрнең юклыгын, әдәби тоемга һәм коры интузиазмга таянып кына берни дә барып чыкмасын, коммунистик тәрбия алган фән әһелләренең динне аңларлык хәлдә түгеллекләрен кат-кат әйткәннәр. Миңа килеп төртелүе очраклы хәл икәнлеген, авантюра юлы белән эш итүен шунда ук төшенү генә җитмәгән, галимнәрнең «булдыксызлыгын» махсус агрессив рәвештә искәртүләренә хәйранлыгым да ярдәм иткәндер бәлки? Шулай да яшьли борынгы китапларны укып белүем, татар кулъязмаларын өйрәнүләрем, шул максатларда Рәсәй киңлекләрендә язмалар өйрәнеп йөрүләрем, әдәби иҗат белән шөгыльләнүем ул эшне дөрес башкарып чыгуыма төп ярдәмчеләр иде.

Хәйдәр үзе белән сак булырга һәм үлчәп сөйләшергә өйрәтте. Асылда барлык фикер алышуларыбыз әдәбият тари-

хына бәйле, яки аның үз көнебез хәле тирәсендә әйләнде. Хәйдәрнең хәбәрдарлыгы киң. Югары белеменә өстәп ул әле әдәби курсларда укыган, Мәскәүнең бөек галимнәренең лекцияләренә йөргән. Әдәбиятка бәйле иркен карашлы кешеләр сирәк була. Хәйдәр татар әдәбиятының киләчәген хакыйкатьне мификлаштырып тасвирлау белән бәйле әсәрләр иҗат итү юлында дип белә иде. Аның көчле әдәби әсәр миф тудырырга тиеш дигәне халкыбызның борынгы дөньяга карашын яңартырга кирәклек мәсьәләсенә килеп төртелә торды. Әмма ул мифларны фәнебездә кем өйрәнгән, тәртипкә салган соң? Бу өлкәдә галим һәм язучы Галимҗан Гыйльманов шөгыльләнүен белгәч, зур кызыксынуын сиздереп, аның хезмәтләре дөнья күрүен зарыгып көтеп алды. Аерым томнар буларак алар басылып чыккач, өстәл китабына әверелделәр бугай. Шушы юлда эзләнүләре Хәйдәрне галим-фольклорчы Фатих Урманчиев белән дуслаштырды.

Аңа ничектер, әдәби әсәрнең тормыш хакыйкатен мифологик танып белү дәрәҗәсенә җиткерергә, шуның белән әдәби хакыйкатькә әверелдерергә тиешлеген сөйләп, хакыйкатьне хәтта мифик сурәттә бирә белү кирәклеге хакында аңлатып, кай вакытларда мин дә башын шактый катыргаладым. Әмма ул барыбер дә мифик образларны һәм символларны әдәби әсәрдә файдалану, шулар ярдәмендә хакыйкатьнең тасвирын үтемле итеп бирү ягында кала иде. Шушы вакытларда бу юнәлештә язылган «Акча машинасы» хикәямне аңа сөйләп бирдем. Кабул итте. Ә аннары мификлаштыру дәрәҗәсенә җиткерелгән, тормыш хакыйкатен яктыртучы «Әнием, Коръән чыгарсың!», «Авыл мөгаллимнәре» әсәрләремне укырга киңәш иттем. Алар әле аерым китапта басылып чыкмаган, газета-журнал вариантлары гына дөнья күргән булганга, сөйләшүләребез коры калды. Аннары, үз дәрәҗәмне белмичә, бөеклеккә баш имәвем дә тәүфыйксызлык кебек тоелгандыр? Хәер, аның «Балдаклы хыянәт» повесте уңаеннан фикерләремне сөйләп тә күңелен сөендерә алмадым. Анда хакыйкатьне мифологик сурәт дәрәҗәсенә җиткереп тасвирлау бар иде бит югыйсә.

Телевидениедә эшли башлауга, анда Хәйдәр импровизация ысулын алып килде. Узган гасырның туксанынчы елларында татар телевидениесе шуның аркасында күтәрелде дә. Кай вакытларда болай да була иде: Хәйдәрнең тапшыруы әзерләнә, әмма туры эфирга чакырылган кунагы килә алмый. Алып баручы журналист буларак ул аны алыштырырга кеше эзли. Таба алмый. Ике сәгатьтән тапшыруы башланачак. Миңа шалтырата: «Килмәсәң, башка чакыру юк, беттең»,— ди. Мин, сәбәп эзләп, әле кичә генә аларда чыгыш ясавымны искәртәм. Ул кабул итми. Кисәтүен кабатлый. Тыңлаучан кеше йөгерә инде. Эш өчен кирәк бит! Хәтта нинди сорау бирәчәген дә алдан әйтеп тормыйча, камера каршысына утырта. Импровизация ысулы әлбәттә көтелмәгән сорауга нигезләнә. Тапкырлык та, белем дә кирәк булгандыр? Ә ул киң мәгълүмат иясе затлы зыялыларыбыздан иде.

Шулай бервакыт үзе килде дә:

— Иртәгә синең турыда материал әзерләү өчен туган якларыңа китәбез. Машинаң белән алып барасың,— диде.— Мөдәррис Әгъләмовыңны да алабыз!

«Жигули» машинасына утырган гына, йөртү осталыгым да чамалы чаклар иде әле бу. Моңа кадәр алдарак минем хакта телетапшыру ясаячагы турында бер тапкыр тел төбемне тарткалап алуын да хәтеремнән җуймыйча ризалаштым. Камерага төшерәчәк операторы Чаллыда икән. «Аны да үзебез белән алачакбыз!»— дип белдерде ул юлда.

Кайттык. Туган якларымны күрсәттем. Мәктәптә матур гына очрашу да уздырдылар, районда да яхшы кабул иттеләр. Туган йортымда кич кунып, икенче көнне Зәй тарафына юнәлдек. Инде белә идем: безнең бу кайтуыбыз асылда аның үз мәктәпләренең юбилеенда катнашу максаты белән дә икән. Анда Мөдәррис Әгъләмов та укыган, Роберт Батулла да, Наил Дунай да, тагын да күпме дан-хөрмәт ияләре, эшмәкәрләр, дөнья гамәлләрен җитәкләүчеләр...

Үз мәктәпләре директорына Хәйдәр, мул елмаеп:

— Үзем генә кайтмадым, менә бүләгем! Үзеннән сора!— дип, миңа төртеп күрсәтте. Хәер, сүз без кайткан машина хакында бара түгелме дип тә уйларга мөмкин иде. Ул арада

берничә күңелле мәзәк тә сөйләп алды Хәйдәр. Маҗарага маһирлыгы аны ал да, гөл дә итә иде шул.

Юбилей бәйрәмнәре бик матур узды. Батулланың шундый оста сөйләүләре, концертларының яхшылыгы — барысы да хәтеремдә.

Китәр алдыннан яныма мәктәп директорлары килеп басты. Юбилей бүләге хакында сүз катты. Мин инде нинди шаяртуга корбан булуымны тәмам аңлап җиткергән идем. Машинамда берничә китабым булып, шуларны бүләк итеп бирим, дидем. Ярый да аңа гына риза булсалар?

V

Минем хакта аерым тапшыру оештырыласын инде белсәм дә, ул турыда сүзне башка кузгатмадым. Берәр ай вакыт узгандыр. Операторының тырыш хезмәтен дә исенә алып, сабырлыктан да файдаланып, Хәйдәр ул эшен җиңел генә ахырына кадәр җиткерде. Аңа шул телевизион тапшыруы өчен зур рәхмәттә булдым.

Хәйдәр җырга бик тә маһир, ул сәнгатьнең дә чын остасы иде. Илһам Шакиров белән туганнар. Хәйдәрнең газиз әнкәсе Гыйльмисафа — Илһам Шакировның апасы. Мөдәррис Әгъләмовка да туганлыклары барлыгын үзләре сөйләгәннәрдән, ишетелгән хәбәрләрдән беләм. Әтисе Гайфетдин ягыннан Хәйдәрнең нәселе әдипләребез Разил Вәлиев, Зөлфәт Хәким, Рафис Сәлимҗановка барып тоташканын 2002 елда «Шәҗәрәләр» китабында шагыйрь һәм галим Дамир Гарифуллин тәфсилләп язып та чыкты, борынгы бабалары Йосыф исемле икәнлеген ачыклады.

Хәйдәр «Иске карурман»ны, «Уел»ны җырлый. Кай вакытларда Илһам абый Шакиров белән килеп чыгалар. Әдәбият, сәнгать турында иркенләп фикер алышабыз. Илһам абый Шакиров гаять тә киң мәгълүматлы, титан шәхес. Бервакыт Хәйдәргә:

— Тавышың Илһам Шакировча матур, терәндергеч. Әмма аның ноталары шулкадәр түгәрәк, камил, матур чыгалар, ул хәтта ярымнарын да төгәл ала. Моңы — искиткеч. Андый җырчы башка юк. Аңа ияреп, аңа охшатып кына җырларга

мөмкин. Тик андый иярчен җырчыны талантлы дип булмас. Ул кеше һөнәрче аталыр. Шулай түгелме?— дидем.

Сүзләремне, бигрәк тә «һөнәрче» дигәнемне авыр кабул итәрен башыма да китермәгәнмен. Аның йөзе үзгәрүеннән шунда ук артыгын сөйләп ташлавымны аңлап алдым һәм, гафу үтенеп:

— Дустым, зинһар, сине әйтүем түгел иде,— дидем.— Син бит җыр җырлап «тамак туйдыручы» түгел. Җырчылар исәбендә йөрмисең, язучы, журналист кешесең!

Әмма ул шушы «һөнәрче» сүзем өчен шактый ныклап үпкәләде, «аркам белән егып түбән салырга», моны башкалар алдында тел куәте белән башкара алу осталыгын күрсәтә белү ягыннан да ачылып китте.

## VI

Дөрес аңларга кирәк, Хәйдәр фәрештә түгел иде. Хәер, адәм баласыннан фәрештә булуны таләп иткән дә юк. Ул мәктәп укытучылары гына укучыларының фәрештә булуларын телиләр һәм моны «баладан кеше ясау» дип атыйлар.

Бервакытны Хәйдәргә, бик талантлы шагыйрь булуын әйтеп, «Ут теле» китабыннан бер шигырен укыдым. Ул бәлки шаяртамдыр дип уйлагандыр. Фикерләренең, сурәтләренең хакыйкатьне тирән ачып, тәэсирле итеп күңелләргә үтеп керерлек кимәлдә икәнлегенә басым ясадым. Ә никадәр гадилек, гадәтилек бу юлларда, табигыйлек!

«Тормыш бит бу!
Дөнья куа-куа
Беттем инде менә өтелеп.
Нурсызланды бугай күңелем дә,
Караучысыз калган өй кебек.

Күпме яшерсәм дә, сорашалар:
әллә каян, читтән уратып.
Сорасалар:
— Хәлем бик әйбәт!— дим,
энкәйләрне була юатып.

Юатырга була сөйгәннәрне,
ышандырып була дусларны.
Бәйләнчекләр очрый калса әгәр:
— Төпченмәче,— дим мин,— юк-барны!

Тик йөрәкне булмый ышандырып,—
чыгар минутларын саный күк.
Елап туйган...
Хәзер ишек шакый
бикләп калдырылган сабый күк...

*1981, январь.*»

Әмма аның шулкадәр ачуы килде. Кулымнан китабын тартып алды да читкә томырды. Аңладым, ул үзенең шигырьләрен, алардагы күңел серләренең ачык сурәтләнүен сөйми икән, дидем.

VII

<Дуслык мәсьәләләре.>

Хәйдәр үз кемлеген яхшы белүче кеше иде. Дәрәҗәсен түбән куймады. Кешене кеше илдә тоткан дәрәҗәсенә карап хөрмәтли. Хәйдәр бу кагыйдәне төгәл үтәп барды дип беләм. Бервакыт ул мөфти Тәлгать Таҗетдин белән килеп керде. Илдә дини сәясәтнең үзгәргән вакыты иде. Татарстан мөфтиятенең оешу җыелышы башлап заманында «Тукай кинотеатры»нда узды. Эшне әйдәп йөрүчеләрдән Зөфәр хәзрәт (ул данлыклы архитекторлар исәбендә республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты да булды) шул утырышның карарларын әзерләргә мине чакырды. Һәр төбәктә мөфти булуга шәригатьтә каршылык юк икәнлеген аңа гына түгел, бу юлы шул мәртәбәле җыелышка аңлатып, шунда ук эшләп биргән карарларым да булышлык иттеләр. Үзем белән алып килгән машинкада оештыру җыелышы барышында ук турыдан язып әзерләнгән шул карарларның кабул ителүендә өлешемне сөйләп, барлык җаваплылыкны үз өстемә алганымны сиздереп:

— Ялгышкан булсам, мөфти хәзрәт, мине ачуланыгыз!— дидем.

Тәлгать Таҗетдин миңа елмаеп карап торды да болай диде:

— Вакытлы, дөрес, кирәкле ул карарларның авторы сез идегезмени?

Шунда Хәйдәр, хәзрәтнең сүзләренә олы хөрмәт күрсәтеп:

— Динне мөфтиләрнең артуы үстереп җибәрә!— диде.

Инде сөйләшүебез тагын да җанланып китте. Кешеләрнең мәртәбәсен төгәл аеручы Хәйдәр оста дипломат шәхес буларак ачылды. Мөфти хәзрәтләренең акылы, белеме, дөньяга һәм дингә, милләткә карашлары күңелдәге икеләнүләрне юып ташлады. Бөек кеше икәнлеген төшендем. Мәҗлесебез иң четерекле мәсьәлә — дөньяви һәм дини кешеләр хакында фикерләшүләр белән уратылып алып барылды. Тәлгать Таҗетдин шунда Хәйдәргә һәм миңа дөньяви кешеләр булып калуыбызны теләп фәтвасын бирде.

Соңыннан да бу очрашуны искә алып сөйләшкәндә, Хәйдәрдән:

— Ни өчен мөфти безнең дин юлыннан китүебезне теләмәде икән?— дип сорагач, ул:

— Беренчедән, Тәлгать Таҗетдин бик акыллы кеше, икенчедән, синең-минем нинди камырдан ясалганыбыз күренеп тора, өченчедән, аларның анда үз дөньялары киштә-киштәлекләрендә мыскалына кадәр бүленгән!— диде.

Аңлаган кешегә шушылар да җиткән, күп вакыйгаларга аның бу билгеләмәләре ачык дәлил иделәр. Кабат ул темага әйләнеп кайтмадык.

## VIII

— Сине Язучылар берлегенә алырга теләкләре бар! — диде бервакыт Хәйдәр.

— Белмим инде,— дидем мин аңа җавабымда.— Ул — «колхоз»га керү кебек нәрсә булмасмы соң?

Бу вакытта инде колхозлар таралып бетеп маташа иделәр. Бер данлыклы һәм бөек журналист-шагыйрь-язучыбыз да Язучылар берлеген колхозга тиңләп мәкалә язып чыккан иде.

— Китапларың бар, исемеңнең танылуы да җиткән. Яңа төр, яңа фикерле кешесең,— диде Хәйдәр.— Аннары, дөрес

аңла, кәҗәң килмәсен, хикмәте дә бар: сиңа ияртеп кенә тагын бер-ике кешене уздырырга кирәк!

Аның оста стратег икәнлегендә, эшне оештыра һәм кора белүендә һичбер шигем юк иде, әмма кемнәр файдасынадыр мине «ширма», хәтта «көтү тәкәсе» итәргә теләвенә хәйран иттем. Артыма качырылып Берлеккә уздырылган кешеләр ахырдан барыбер дә рәхмәт әйтмәячәк, көнчелек күрсәтәчәкләр әле, җитмәсә.

Үз уйларымны сиздермәскә тырыштым. Икеләнгән булдым. Аннары, әгәр дә дустым икән, ни өчен миңа «ширма» язмышын юрый?

— Берлеккә кергәч, язган әсәрләреңне бастырып чыгару мәсьәләсен дә җиңел хәл итәрсең!— диде ул.

Бу сүзләре икеләнү-кирелекләремне юк иттеләр. Ничәмә китабым басылмыйча ятканын, китап нәшриятлары тарафыннан кабул ителми аптыратуларын исемдә тоттым.

Нәкъ Хәйдәр әйткәнчә булды. Аның кешеләр белән сөйләшә белү осталыгы, эшләрне стратегик яктан оста оештыруы үзен күрсәтте. Ә аннары ул, мәсьәлә чишелгәч:

— Амбразурага Газинурлар гына түгел, менә син дә капландың!— диде, вакыйгаларны көлә-көлә искә алып.

— «Колхоз»ны әйтәсеңме?— дип, мин дә шаярттым.

Язучылар берлегенә бишкуллап алсалар да китапларымның, әсәрләремнең басылып чыгуына моның файдасы булмады. Әмма бәлаләре...

— Сине Язучылар берлегенең рәисе итеп күрергә телиләр!— диде ул беркөнне, мине тәмам хәйранга калдырып.— Монысының срогы чыга.

Бу юлы ике аяклап киреләнеп каршы чыктым. Минем ише сүз тыңламаучыларны чәнчә бармак ишәрәсе белән дә җиңәргә өйрәнгән Хәйдәр бераздан килеште. Ишәгеп нуктасы белән бергә ташлап киткән Хуҗа Насретдингә әверелде. Сүзләре дә онытылды. Алар бервакыт кабат һәм кинәт калкып чыгарлар дип көтмәгән идем. Съезд якынлашкан саен күңелгә утны азазлап сала-сала, ризалыгымны алуга ирешге. Әмма мин аңа:

— Беркем белән дә сайлауларын үтенеп сөйләшмәячәкмен, беркемне дә үгетләмәячәкмен, дуслык хакына гына ул уенына катнашырмын, бу юлы да «ширма» булырмын,— дидем.

Язучыларның уенда мине рәисләре итеп сайларга теләге барлыгын күпләр телгә ала башладылар. Әлбәттә ниятемне белү сәясәте генә иде бу, дидем үз алдыма елмаеп. Аларның да билгеле бер уен корбаннарыннан яки уенчыкларыннан булулары бик мөмкин иде. Рәислек һич тә кызыктырмады, ниндидер ят, шикле җир кебек тоелды ул урын миңа. Инде Хәйдәрнең сүзен аяк астында калдырмаска тиеш идем. Ул вакыттагы рәис әфәнде чакыртып, ресторан сыйлары белән кунак итеп, уемнан кире кайтуымны сорады. Аңа бу эшнең миннән тормавын кат-кат, ничә мәртәбәләр аңлатырга туры килде. Ә ул барыбер дә үз шигендә, үз фикере коткысында калды. Мин инде күптән кемнәрнеңдер сәясәте барып чыксын өчен корылган «ширма» гына идем. Рәиснең үз дусларына да качып уйнарга яхшы җай иде бу. Әгәр дустым Хәйдәр шул көчле кешеләрнең берсе икән, мине ул уенга корбан итүенең асыл сәбәбе бар булыр, дидем, ролемне ахырына кадәр башкарырга калды.

Берлек съездының рәте булмады. Ул берни дә хәл итә алмыйча ябылды. Җәй урталарына җыелырга карар ителде. Аскы һәм өске агымнарга иярмичә калуыма сөенсәм дә, хәлемнең көенечле икәнлегенә дә беләм, Хәйдәрнең, дус дип йөргән кешенең, нинди уенга мине корбан итүенә дә хәйранлыкта идем.

## IX

Иң кыены шул — синнән уенчык ясауларын аңлап-белеп торасың, әмма бу тозактан чыга алмыйсың.

— Мине рәислеккә күрсәтсәгез, сикереп торам да, мин булырга теләмим дип, барысы каршында әйтәм!

Шушылай уемны-теләгемне Хәйдәргә белдергән идем, ул:

— Шул сәгатьтә-минутта ук сукыр бер тиенлеккә әвереләсең киләме әллә!— диде, усалланып ачуланып.— Андый кеше синнән башка да булыр. Күрербез!

Хәер, дөнья йөзендә һәр җан иясенең үз урыны бар, диләр бит, шулай булсын да, ди...

Хәйдәр миндә Язучылар берлеге рәисе булу теләген тудыру эшенә инде ныклап керeште. Әмма аңа фән белән шөгыльләнү уенда булуымны, институтка эшкә күчеп йөрүемне бөтенләй әйтмәдем. Аның — үз уе, минем — үземнеке, дидем, күңел төбемдә кояш нурларын уйнатып.

Ә «ширма» ролен башкарырга барыбер туры килде. Язучы кеше тормышны, халыкны аңларга, төшенергә теләсә, үзе белән уйнауларын күреп, шул уенның ахырына кадәр бара да белергә тиеш. Шулай уйладым, шулай эшләдем. Хәйдәр артында кемнәрдер тора һәм ул да аларның теләген үти иде, ахрысы. Югыйсә бу тормышның һәммә яклары да аны үз дулкыннарында йөртмәскә, ул үзе дә күп мәсьәләләрдән чикләнергә тиеш иде. Ә яшәеш Хәйдәрне һәммә эресе-вагы белән бергә үз куенына алды. Дөньяның гүяки төзүчесенә, төзәтүчесенә, иясенә әверелә барды. Ул әйткән сүзләрне бүген башкалардан ишетсәм дә сәерсенмим, аның һәр сүзе, фикере, теләге аларның да акылы-күңеле аша узган икәнлеге сизелеп тора.

## Х

Хәйдәр озын буйлы, күркәм кешеләрнең берсе булды. Сүзе — сүз иде, тавышы — моңлы, эше — гамәл!

Аның балта эшенә осталыгы күпләрне хәйран калдырды. Идел артындагы дачасына ул зур бураны бер үзе бурады, йорт итеп, камил итеп салып та куйды. Өендә дә тәртип, пөхтәлекне яратуы беренче урында тора, гаиләсен даими кайгыртып яши белде. Кул эшләрен камил рәвештә башкарулары барча кылган гамәлләреннән үк күренеп торды. Һаман да һәммә нәрсәне үзе башкарырга өйрәнгәнлеге сәбәпле, кешегә ялыну, башкаларга салыну кебек гамәлләр уена да кермәде Хәйдәрнең.

Олы бер Казан шәһәрендә генә дә аның танышлары, дуслары арасында балта осталары күп иде. Аларның хәлләрен белешеп тору, яннарына барып чыгып, тормыш, сәясәт, аң-мәгърифәт мәсьәләләренә кадәр җитеп фикер алышулары эчкерсезлеген күрсәтеп тора. Сөеп, үз итеп сөйләгән

кешеләренең берсе — Нургали абзый дигән, урман хуҗалыгы белән бәйле кешеләрдән берсе иде. Ул аның гадилегенә, хезмәттәшләренә карата гадел хөкемдә булуына исе китеп бәян иткәннәре хәтердә.

— Исерекләргә дә сүз әйттерми. Берәүләр кемнедер яманлап, гаеп итеп сүз катса, аны шунда ук туктата. Дөнья бу, тормыш бу, дия. Һәр кешенең үз урыны, Бүген болай булыр, ә иртәгә аннан да ышанычлы кешене табалмассыз, дия. Андый, Нургали абзый кебек изге җанлы адәмне сирәк очратабыз бу дөньяда!

Саба якларыннан булган ул урман хуҗалыгы хезмәткәре Нургали абзасына Хәйдәр баргалап йөрде. Аны идеал итеп күтәрүенә бераз аптырый да торган идем. Шул кеше белән таныштыруын үтенгәч:

— Ашыкма! «Кара урман» романымны язып бетерим, аннары...— ди торган иде.

Ул әсәренең язмышы миңа мәгълүм түгел. Әсәрләрен Хәйдәр хәтта басылып чыккач та күрсәтергә, фикеремне белергә атлыгып тормады. Үз иҗатына бәйле актан да, карадан да сүз әйтерәсе килми иде аның.

Дусларының берсе — зур талант иясе рәссам Фаил ага Зыязов иде. Аларны бергә еш очраттым. Югыйсә бездә танышсалар да, алга таба алар, Фаил агада очрашып, дөнья барышына бәйле әңгәмәләр корып, иҗат эше газапларын йөрәкләре аша уздырганнарында, күңел зарларына кушып, аптырашка да бирелми калмаганнар. Әдипләрдә һәм сәнгать кешеләрендә уртак уйлар белән яшәү тәртибе бар. Фаил ага Зыязовның Хәйдәр язган әсәрләр нигезендә берничә картина иҗат итүен сәнгатькәрләр генә түгел, музей-күргәзмә тамашачылары да яхшы белә. 1921 нче елгы ачлык турында Хәйдәр хикәя язгач, аның нигезендә ачлык темасына багышланган бүреләр турындагы Фаил ага Зыязовның картинасы күп кенә күргәзмәләрдә дә булды. Хәйдәр дә ул данлыклы рәссам турында телевизион фильм эшләде. Аны телевизордан кат-кат тапшырдылар. Ул шәхес аның зур ачышларыннан берсе иде.

Кешеләрнең дәрәҗәләрен белү һәм аларны ихласлык, хакыйкать, намус призмалары аша күреп бәяләү Хәйдәргә хас

сыйфатлардан берсе иде. Ул үзе өчен генә яшәгән, сүзендә берне сөйләп, гамәлендә икенче төрле булган, дан-дәрәҗәдән башканы сөймәгән, аңламаган әдипләргә карата каты бәгырьлелек күрсәтүне дөрес эшкә санады. Алар аны сөймәделәр. Җир шары ничек ике полюска бүленгән кебек тоелса, анда яшәүче кешеләр дә шундыйдыр инде, берләре — уңда, икенчеләре — сулда, дигәндәй.

## XI

<Журнализм.>

Бернинди әдип тә, бернинди әдәбият та бу «авырудан» азат түгел. Бигрәк тә татар әдәбиятына ул каты йокты. Хикмәте шунда — безнең татар әдипләре көн күрү, яшәү хакына газета-журналларда кәсеп итәргә мәҗбүрләр. Мәкаләләр язу, газета чыгару, теле-радио тапшырулар әзерләү әлбәттә журналистлар эше. Аларның үз хезмәт ритмы, үз яшәү тәртибе, язу, сөйләү, иҗат үзенчәлекләре дә бар. «Журнализм» гади сөйләм нормаларына нигезләнә, аңарда әдәби сөйләм принциплары юк дәрәҗәсендә. Ә безнең татар әдипләре, газета-журналларда хезмәт итеп, журналистлык кәсебендә шактый уңышларга ирешеп өлгерсәләр дә, әдәбияттан еракլаша баралар. Бу аларның язган әдәби әсәрләрендә ачык күренә башлый. Иң әүвәлдә әдәби стильне гадиләштерүгә омтылудан башлана, аннары әдәби формалардан публицистик калыплар өстен чыгарыла, инде образлы-сурәтле тасвирны фикер әйтү, хәбәр, вакыйга сөйләү алыштыра. Шушы өч адымнарыннан әдипләрнең әсәрләренә «журнализм» чире йокканлыгын күреп була. Кайсы гына, хәтта әдәби дип аталган журналны яки газетаны ачып укып карамыйк, шигырь булсын, прозамы, башкасымы — алар барысы да «журнализм» авыруы тәэсирендә «гарип» туган әсәрләрдән торалар диярлек. Бу авыруның диагнозы күптән билгеле. Матбугат органнары туугa ук, газета-журналларны «литературчина», ягъни «әдәбилектән» коткару өчен оештырылган зур кампанияләр чыннан да ахырда журналистиканы әдәбияттан «котылдырган». Бигрәк тә XIX йөз Европа, Америка, рус матбугатлары «әдәбилектән» савыккан һәм моның өчен әдип кулы, әдип күңеле, әдип акылы белән язылган чын

әдәби әсәрләргә (шигырь, хикәя, роман) газета-журналларда киң урын бирүдән дә оста файдаланганнар, югыйсә, һәм хәзер дә бу шулай булып кала бирә. Журналистик сәхифә белән әдәби полосалар бер-берсенә буталмыйча бирелү укучыда аларны дөрес аңларга ярдәм итә, үзләренчә яшәүләренә шартлар тудыра. Әмма татар матбугаты, бигрәк тә совет чорында, башкача эш итте. Әдәби әсәрләрне дә журналистик алымнарга буйсындыру редакторларның төп эшенә әверелде. Шул чорда әдәбиятка «журнализм» йокты, ә журналистикада «әдәбилек» авыруы бетә барды. Журналистиканың мәйданы шактый киң иде.

Хәйдәр, иң беренче чиратта, зур һәм бөек әдип булды. Әмма әдәби формаларда җиңел фикерли алудан шактый читләшергә өлгергәнлеге әдәби әсәрләрендә ачык күренә торды. Ул моны үзе дә сизә. Аларга «журнализм авыруы» дигән диагноз куймый мөмкин түгел иде. Шунда ук Хәйдәрне кисәтергә дә тиешмен дип таптым:

— Зинһар, «журнализм»ны рационализм һәм натурализм белән бутамагыз,— дидем.

Әлбәттә рационализм дигәндә — табигыйлек, натурализм дигәндә — тышкы, болай да күренеп, аңлашылып торган чынбарлыкны сурәтләү күздә тотылуын белдердем. Минем аңлатмаларны ул бәхәссез кабул итә иде. Сүз «журнализм» мәсьәләсенә күчте. Татар әдипләренең күпчелеге, шагыйрьләре, язучылары газета-журналлардан алып өлгергән бу авыруларыннан савыкмаслык хәлгә калганнарын аңлаган Хәйдәр үзе дә ул аймактан чыгар юлны озак эзләде. Сурәтле фикерләүгә кайтуны ул мифлардан өлге алудан, үзе тоткан юлда — вакыйгаларны мификлаштырып бәян итүдә — табар сыман иде. Авыр иҗат газапларына бирелү аны изә башлады. Холкына да тәэсир итми калмады. Билгеле, язучы халкында тормышка хыял күзлеге аша карау гадәте бар. Моңардан аларны бары тик фән генә саклый ала. Юккамы алдынгы карашлы Европа әдипләре үзләрен гыйлем өлкәсе белән тыгыз бәйлиләр. Кайсын алсагыз да — яки ул физик, математик, яисә тарихчы, филолог. Электән, Дантелар, Бокаччолар чорыннан ук шулай килә.

Боларны еш искә ала башлагач, Хәйдәр фән өлкәсе белән яхшылап кызыксынуга күчте. Галимнәр белән дуслыгын ныгытты.

Хыялдан азат булу дигәнне дә ул дөрес аңларга тиеш иде. Асылда әдипләр юкны бар итеп күрүгә һәм сафсата бәласенә төшәләр. Һәр вакыйганы адәм башына килә алмаслык, тормышта булырлык түгел дәрәҗәдә катлауландыралар. Яшәеш чишмәгән, чишәргә теләмәгән мәсьәләне кеше акылы гына хәл итә алмый. Җәмгыятьнең үсешеннән башка гына, нинди генә талантлы булма, күп нәрсәләрне аңлауга ирешеп тә булмый. Хәйдәр боларны акылы белән сизенә, күңеле белән тоя, әмма әдиплек максимализмы, «журнализм» коткысы аңардан күпне таләп итә иде. Андый хисләр белән шаяру мөмкин түгел. Хисләрнең алдау, саташтыру көче бар.

Бервакыт ул графоманлык мәсьәләсен бәхәс мәйданына чыгара башлады. Бу гыйбарә артында нәрсә торганлыгын сорадым. Хәйдәр ул сүзне язуда талымсызлык дип аңлый икән. Мин көлеп куйдым. Андый вакытта ул икеләнеп кала торган иде.

— Дустым,— дидем аңа,— читтән кергән-кертелгән сүзләрдә асылда берничә мәгънә булучан. «Графоман» кәлимәсенең дә сүзгә-сүз эчтәлеге бар, шулай ук фикер үсеше тарихында аркасына алган йөге, һәм, аннан килеп, телдә кулланылышы белән бергә безнең үзебезнең ул гыйбарәне аңлау дәрәҗәбез.

Ул сөйләшүебездә графоманлыкның мәгънәсе идеологик яктан тотнаксызлык икәнлеген ачыклап төшенүдә тукталып калдык. Кичә кызыл таҗ киеп тә, бүген яшел чапан бөркәнүчеләр иде алар — графоманнар.

Иҗат эше әлбәттә күңел хезмәте. Әмма акыл белән җан бергә береккәндә генә кешенең гамәлләре дөрес була башлый. Иҗатта күңелгә дә, акылга да бердәй таянырга кирәк. Иҗат ул, иң беренче чиратта, хакыйкатьне танып белүгә юнәлтелә. Хакыйкатьне төшенмичә, юкны бар итеп тасвирлау — иҗат түгел, саташу, графоманлык.

## XII

Элекке эшемдә чагында Хәйдәр миңа еш килә иде. Институтта укыту эшенә күчүемә, бөтенләй башка тормыш башланды. Минем әле лекцияләрем, әле утырышларым, җыелышларым. Әүвәле ул айга бер килеп китсә, хәзер ярты елга бер генә минем ишеккә юлын төби. Әмма яңа дуслар, яңа хезмәттәшләрем арасына Хәйдәр кереп китә алмады. Безнең дуслык та суынды. Ул язу, иҗат эшенең авырлаша баруыннан зарланып кайчакта шалтырата гына иде хәзер. Алар да бетте.

Теге вакытта, мәктәпләре юбилеена алып кайткач, аны туган авылына, Дүртмунчага, үзен генә алып барып килдем. Күпер асты ягында тыкрыклы урам булып, шундагы су буе юнәлешендә моңаеп торган үзенең туып үскән йортына алып керде мине. Яз вакыты, яңгырлы, юеш, пычрак чаклар иде. Ишек алларына кергәч тә сул якта — таштан сарай, түрдә — терлек абзарлары, уңда — матур гына йорт. Янәшәсендә агачлар үсә.

— Өй каршындагы юкә агачы ауды бит,— дип, түрбакча уңаена калып килеп күрсәтте безгә йортның ул вакыттагы хуҗабикәсе.

Ул чыннан да адәм биеклеге урыннан шартлап сынган да, шул килеш, киселмәгән хәлендә авып ята.

— Эче черек булган икән,— диде Хәйдәр.— Бала чагымда утырткан идем. Минем язмышка ишарә итә булыр!

Йөрәк жу итте.

— Агачтан да фал ачкач, нинди мөселман инде син!— дидем аңа, тәмам ачуланып.

Анысы дөрес инде, урман кисүдә күп иза чиккән кеше буларак беләм: агачны аударганда, бәласенең кайсы яктан сугарга мөмкинлеген даими аңлап, сизенеп эшләргә кирәк. Агач кисүнең җае бар. Мең исәптә бер ялгышу да харап итеп ташлый. Менә шуларны күздә тоткан акыллы кешеләр агач кисүдән сакланырга киңәш иткәннәр. Әмма аларның ул сүзләре өзек чыбыклар белән тапшырылган, халыкта агач ауны-аударуны бәла белән юраучга кайтарып калдырганнар. Замана кешесе боларны гына белергә тиеш иде.

## XIII

Дусларымны бик еш искә ала торган гадәтем бар. Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Наис Гамбәр, Фаил Зыязов, Гөлүс Хафизов... Саный китсәм — аз түгелләр. Хәер, артык күпкә дә җыелмыйлар. Барысын да атамадым. Догаларымда да «баргач кайтмый торган җиргә киткән» һәм монда калган дусларыма газап утларыннан саклавын һәм аларга яхшылыклар бирүен Аллаһы тәгаләдән түбәнлек белән сорыйм.

Хәйдәрнең үлем түшәгенә ауганлыгын, телефоннан шалтыратып, Мөдәррис Әгъләм хәбәр итте. Телевидениедән күрсәткәннәр. Кабатлаячаклар икән. Нәкъ шулай булды. Сюжетлары хәтергә уелып калды. Уйланылмаган хәл булган, хатыны пычак тотып эшләгән вакытта Хәйдәр ялгышлык белән аның кул астына килеп кергән. Искә алуы да авыр. Икесе дә калын пыялалы күзлекләр кия иделәр. Бәла аяк астында гына шул.

Бу вакыйга дөньяның котын алды. Язучы халкында бераздан имеш-мимеш куерды, төрле фаразлар белән урамнар тулды.

Хәйдәр белән хатыны үзара тату, берсен-берсе бик тә сөешеп, яратып, бәхетле яшәделәр. Ул аңа авыз күтәреп авыр сүз әйткәнен мин белмим. Хатыны да аның һәр адымын аңлап, һәр сүзен кабул итеп, алдында келәм, аркасында мамык япма булып, хезмәтендә камил зат иде.

Нигә, ни өчен, ничек шулай аралары бәла белән киселгәндер — аңлашылмады. Гомер буе матур яшә-яшә дә, әҗәл шуклыгыннан аякларың таеп китсен инде — алай бер дә дөрес түгел бит!

Көтелмәгән бәла аркасында Хәйдәрнең хатыны Наилә ханым берьюлы ничәмә ут эчендә калды. Ялгышлыгы аркасында ирен югалтуы аны акылыннан яздырыр хәлгә җиткерсә, кеше теле, кеше сүзе, имеш-мимеш уйдырмалар бәла чоңгылына җанын төртеп төшергәннәрдер? Мәхкәмә хөкеме бер хәл, ил хөкеме, халык хөкеме аңардан мең тапкырлар авыррак түгелме? Аллаһы тәгалә мондый чакта кем ягында була? Сөйгән хатынын ялгышлыгы өчен каһәрләүче Хәйдәрнең дус-

лары, танышлары, ялгышмыйбызмы? Имеш-мимешләрдән арынырга вакыт түгелме?

Бу уйлар ничә еллар күңелемне борчып, вакыт-вакыт изеп тордылар. Ул чишелмәс төенгә әверелде. Һәм көннәрнең берендә хәл ителде.

Эшемнән кайтып килә идем. Хәйдәрнең хатыны очрады. Гаилә хәлләрен белештем. Улы өйләнгән, Хәйдәрнең кабер туфрагына, Дүртмунчага, ел саен, барып, зыярәт кылалар икән. Сагыналар үзен.

Мин башка һич сүз сорашмадым. Авыр туфрагына җиңеллек үтенечендә ике якка, үз юлларыбыздан киттек. Шул минутларда Хәйдәргә җәннәт ишекләрен Аллаһы тәгалә ачканлыгын күңел тойгандай булды. Борчылулар тулы уйларымнан аерылдым. Инде Хәйдәр хакында сүз чыгып, танышларымнан берәрсе имеш-мимешләргә бирелсә, юкны сөйләмәскә киңәш итүне гадәтемә керттем. Юкка әйтелмәгән бит, бәла аяк астында, дип. Ул хәтта бөекләргә дә кагыла. Ә Хәйдәр узган заманабызның чыннан да бөек әдипләреннән берсе иде. Табигате белән шулай яратылган, талантлы, чиста, пөхтә, булдыклы, ярдәмчел кеше, чын шагыйрь, чын язучы иде! Каләмдәшләре арасында мәртәбәсе даими югары иде. Бервакытта да икетөрлелек, икейөзлелек күрсәтмәде. Шуңа да аны юксынабыз, искә алабыз, әсәрләренең кабат томнар булып халыкка чыгуын көтәбез.

*2012.*

## КҮҢЕЛЕНДӘ ХАЛЫК ДОГАСЫ

*(Композитор Котдус Хөснуллин иҗаты хакында)*

К.Хөснуллинның Казанда «Раннур» нәшриятында 2001 елда 724 сәхифәдән гыйбарәт «Мөнәҗәтләр һәм бәетләр» китабы дөнья күрде. Мондый зур хезмәтне бер кешенең генә башкарып чыга алуы гына да зур соклану тудыра. Билгеле булганча, халык иҗаты җәүһәрләрен барлау һәм җыйнау, көйләрне өйрә-

нү, аларны ноталарга салу, фәнни яктан төркемләү һәм тикшерену эше коллектив хезмәт җимеше генә була ала. К.Хөснуллин исә боларны бер үзе башкарып чыккан һәм гыйльми дәрәҗәдә югары итеп эшли алган.

Мөнәҗәтләрне тикшерү һәм өйрәнү эше соңгы вакытларда фәндә шактый активлашып китте. М.Нигъмәтҗанов, Р.Ягъфәров, А.Садыйкова, Р.Исхакова-Вамба, Ф.Урманчиев, М.Бакиров, Х.Миңнегулов, Г.Макаров һ.б. галимнәр бу юнәлештә күп эш башкардылар. Әмма К.Хөснуллин, башкалардан аермалы буларак, текстларны тулы һәм дөрес эшләү, көй сәнгате таләпләре югарылыгында тәртипкә салу белән шөгыльләнде.

Мөнәҗәт жанры борынгы заманнардан бирле әдәбиятта һәм халык иҗатында үстерелеп килүе белән озын үсеш һәм үзгәреш процессын кичергән, шунлыктан ул катлаулы сәнгать күренешt булып тора. Аны анализлау һәм бәяләү фәндә төрле каршылыклар китереп тудыра. Галимнәрнең хезмәтләрендә мөнәҗәткә төрлечә карашлар сакланып килә. Чынлыкта мөнәҗәт ул — шигъри дога. Андый әсәрләрнең мөнәҗәт булуы өчен өч композицион берәмлекнең булуы шарт: беренчесе — Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итү, Аны олылау, икенчесе — Аллаһыга үзеңнең шәхси теләк-үтенечеңне җиткерү, өченчесе — шул үтенечеңнең кабул ителүенә шарт буларак адарыну. Аларның һәркайсы мөһим. Әгәр дә бер генә элементы төшерелеп калдырылса да, әсәр мөнәҗәт булуыннан туктый. Адарынган вакытта һичшиксез Аллаһы тәгалә биргән тәкъдиргә буйсыну, күңелдә иманны ныклы саклау белән ант итү мәртәбәле санала. Бу Ислам дине йолаларында шулай кабул ителгән һәм Коръән аятьләре белән расланылган. Шулай итеп, мөнәҗәт — дини эчтәлектәге шигъри дога әсәре буларак аңлашыла.

Һәртөрле дини шигъри әсәрләр халык күңелендә мөнәҗәт буларак калганнар. Шуңа күрә дә дингә кагылышлы эчтәлектә икәннәр, ул иҗат җимешләрен халык «мөнәҗәт» дип атый барган һәм шулай дип хәзер дә күзаллый. Хәтта касыйдә, кыйсса, газәл буларак жанрлары төгәл билгеле әсәрләр дә халык телендә «мөнәҗәт» диелә, бу яктан халкыбыз бүтән төрки кавемнәрдән аерылып та торалар. Әгәр дә берәр төрек: «Әйдәгез, мәснәви әйтеп алабыз!»— дип көйләп җибәрсә, безнең татарга аны:

«Әйдәгез, мөнәҗәт әйтеп алабыз!»— дип аңларга кирәк була. Шулай итеп, мөнәҗәт төшенчәсенең дини эчтәлек белән бәйле, дога булып яңгыраучы һәртөрле шигъри әсәргә ярашып баруы белән килешергә кала. Бу исә галимнәргә мөнәҗәтне жанр буларак тикшерү һәм өйрәнү эшен шактый катлауландыра.

Ислам дине тарихы белән бәйле борынгы хезмәтләрдә мөнәҗәтне Адәм галәйһис-сәлам вакытыннан ук килгәнлеге күрсәтелә. Һәрхәлдә форма ягыннан, дога буларак, илаһи затка мөрәҗәгать итү мәдәният башлагычы баскычларыннан алып, кешелек тарафыннан кулланылышта булганлыгын инкарь итү мөмкин түгел. Укыла торган догаларның күпчелеге прозада. Әмма күңел кушканча башкарылуы шарт булганлыктан, ул догаларның шигырьгә күчеп китүе бер дә гайре табигый хәл кебек күз алдына килми. Пәйгамбәрләрдән бигрәк тә Давыт галәйһис-сәламнең мөнәҗәтләр чыгаруга маһир булганлыгы мәгълүм. Бүгенге көндә төрле диннәрдә һәм мәзһәбләрдә кулланыла торган, европалылар «псалма» дип әйткән «шигъри догалар» да урта гасырларның галимнәре тарафыннан мөнәҗәтләр буларак билгеләнгәннәр.

К.Хөснуллинның тезисларыннан берсе булган һәм мөнәҗәтләрне мәҗүси дәверләрдә үк киң таралыш алган жанр буларак карау мәсьәләсенә килгәндә, бу чыннан да шулай. Хәтта гарәпләрнең үзләрендә дә төрле потларга мөнәҗәтләр белән мөрәҗәгать итү йоласы сакланган. Алар соңыннан мөселман шагыйрьләре тарафыннан Аллаһыга мөрәҗәгатькә алыштырылганнар, Ислам дине кануннарына эчтәлектә һәм формада буйсындырылганнар.

Кешелек һичбер вакытта да илаһи дөньяга мөрәҗәгатьсез калмаган. К.Хөснуллин җыйнаган материаллардан күренгәнчә, хәтта коммунистлар хакимлеге заманнарында да алар туа торганнар һәм, яңа юнәлеш, драматик эчтәлек алып, катлаулы күренешкә әверелә барганнар. Композитор-галим аларын да табуы һәм төркемләве, өйрәнүе белән укучыларын сокландырмый калмый дип беләм.

Мәҗүси вакытларында халкыбызның борынгы бабалары тудырган дога шигырьләре, хәзерге кулланылышта йөргән термин белән әйтсәк — мөнәҗәтләре, бүгенге көнгәчә сакланып

калынмаган. Әмма аларның һичшиксез булганлыгын хәтта Орхун-Енисей кабер ташъязмаларыннан ук күрергә, үзмаксат куйганда, «реставрацияләп» тикшерергә дә мөмкин. Әгәр дә Әбул-Газыйның 1609 нчы елда тәмамлаган «Шәҗәрәи-төрек» хезмәтенә мөрәҗәгать итсәк, ул да бу мәсьәләгә ачыклык кертергә ярдәм итүче кайбер фактларны билгеләп үткәнен күрербез. Аның фикерләренчә, мәҗүси дәвердәге бабаларыбыз вакытсыз вафат булган иң якын кешеләренә сыннар һәм сурәтләр ясата торган булганнар. Шул потлары белән, тере кешегә ничек мөрәҗәгать итсәләр, шулай сөйләшкәннәр. Аларга сыгынып, көйле догалар, шигырьләр әйткәннәр. Һичшиксез үтенечләрен белдергәннәр һәм хәтта алардан ярдәм дә сораганнар. Бу йолаларын алар шигъри дога белән алып барганнар.

Тәңре дине мәсьәләсенә килгәндә, аны мәҗүсилек дип карарга кирәкме икән? Бу мәсьәлә фәндә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, булган кадәре фәнни хезмәтләр дә каршылыклар белән тулы. Галимнәр тәңречелекне дөрес аңлау һәм аңлатуны әлегә шактый катлаулы мәсьәләләрнең берсе булып кала килгәнлеген еш искәртәләр. Тәңречелек чорында, мәҗүсилектән, ягъни потларга табынучылыктан аермалы буларак, мөнәҗәтләр нинди эчтәлектә һәм формада булганнар дигән сорауга якынча җавап табарга мөмкинлегенә инде тукталган идек. Монда өстәп шуны гына әйтергә мөмкин, мәдәни үсештә эчтәлекнең алышынуы тиз арада яңа формаларның барлыкка китерелүе белән озатылып барылгандыр дип әйтеп булмый.

Урта гасырларга килгәндә, мөнәҗәт жанрының шактый үсеш алганлыгын К.Хөснуллин билгеләп үтә һәм моны суфичылык, диндарлык үсеше белән бәйли. Ул фикерне инкарь итеп булмый. Чыннан да урта гасырлар дәвере шагыйрьләре мөнәҗәт жанры үсешенә зур йогынты ясаганнар.

К.Хөснуллинның төрле, бер-берсеннән ерак, үзара бәйләнешләре күптән өзелгән төбәкләрдән җыеп алган мөнәҗәтләренең күбесе урта гасырлар төрки шагыйрьләрнең иҗат җимешләренә бәйле икәнлеген искәрсәк, әдәбият белән халык иҗатының шактый тыгыз бәйләнештә үсә барышын да ачык күз аллый алабыз. Хәтта Г.Тукай, С.Сүнчәләй һәм башка XX йөз башы татар шагыйрьләренең әсәрләре дә халык тарафын-

нан мөнәҗәт буларак файдаланыла башлаганнар. Бүгенге көндә бу процессны тукталып калгандыр дип әйтергә мөмкин түгел. Димәк, мөнәҗәтләрне өйрәнү халкыбызның рухи дөньясын ачык күзаллар өчен шактый киң юллар ача, аның мәдәни үсешен дә билгеләргә ярдәм итә. Бу факт исә К.Хөснуллин хезмәтенең әһәмиятен бермә-бер арттыра, аның киң җәмәгатьчелек өчен файдалы икәнлеге хакында сөйли.

К.Хөснуллин илебезнең һәр татарлар яши торган төбәкләрен җәяүләп йөреп, аның моңга-җырга бай күңелен өйрәнеп чыккан практик галим-композитор. Җырлар, шактый гына инструменталь-камера һәм симфоник әсәрләр иҗат иткән, романслар язган. Ул бүгенге көндә оратория һәм балет әсәрләре авторы да. Аның «Көмеш дага» балетын сәхнәләребездә күрәсе иде! Опера тудыру юнәлешендә дә шактый гына уңышлы эшләр башкаруы хакында җәмәгатьчелек арасында сүзләр күп йөрде. Ул халкыбызның бай фольклор мирасын туктаусыз өйрәнә, көйләрен барлый һәм, аларны халыкның үзенә кире кайтарып, киләчәк буыннар алдында ихластан бөек эшләрне башкарды. Ничәмә сәхнә әсәрләренә көйләр язды. Боларның барчасы да дәүләт тарафыннан да лаеклы бәяләнелергә тиеш иделәр, югыйсә.

*06.04.03.*

## ТАРИХЧЫ РӘССАМ

*(Канәфи Нафиков иҗаты хакында)*

Казанда Габдулла Тукайның әдәби музеенда Канәфи Нәфыйковның 1986 нчы елда ясалган, «Ландыш (С.Гыйззәтуллина-Волжская һәм Г.Тукай)» дип аталган рәсеме бар. Бу эш берничә тапкыр күргәзмәләрдә дә катнашты. Гаҗәеп кызыклы хезмәт. Чибәрлеге һәм артистлык осталыгы белән татар халкын үзенә гашыйк иттергән С.Гыйззәтуллина-Волжская бу рәсемдә ак калфактан, күркәм күлмәктән һәм бераз гына каушап калганрак сурәттә, оялчан карашын

яшеребрәк басып тора. Чөнки аның янына Г.Тукай килгән. Юк, ул гына түгел, XX йөз башының зыялы яшьләре Сәхибҗамал туташның туган көненә җыелганнар. Өстәл тулы гөлчәчәкләр. Һәркайсының күңелендә бәйрәм рухы. Нәкъ С.Гыйззәтуллина-Волжскаяның Г.Тукай турында язган истәлегендәге тарихи вакыйганың җанланышы бу. Тукай, сак кына үрелеп, үзе китергән ап-ак ландыш чәчәген бәйләм гөлләр арасына куя. Ул да бераз гына оялганрак сыман. Күңелендә — сер, дәртле сагыш сере, Сәхибҗамал туташка хөрмәте, соклануы һәм, һичшиксез, шагыйрь булгач — эчкерсез мәхәббәте. К.Нәфыйков боларның барысын да бик оста һәм үтемле итеп сурәтли алган. Зыялы, татлы һәм тәэсирле күренешне XX йөз башы татар яшьләренең үз-үзләрен тотышлары хакыйкый, вакыйгаларның шигърилеге белән бергә үреп ясаган.

Сокландыргыч рәсем. Әмма буяулары гына бераз авыррак, катлаулырак, беренче карашка хәтта романтик халәт белән каршылыкка да киләләр сыман. Хәер, рәсемнең серлелеге дә шушы төсләр ярдәмендә чагылыш тапкан шул. Тарихның ерагая баруы кисәтелә кебек.

Ә Канәфи Нафиков, академик Индус Таһировның әйтүенчә, үзе дә ерак тарихтан киләдер сыман. Үткәндә калган бабаларыбыз аны юри безнең чорга җибәрмәдеме дип уйларга гына кала. Дөрес, бу шаяртып әйтелгән сүздә, ничек кенә булмасын, хакыйкать тә бар. Чөнки рәссам, табигый талантына гына таянмыйча, фәнни хезмәтләрне туктаусыз һәм зур тырышлык белән өйрәнә, дус галимнәре белән киңәшә, фикерләшә, эзләнү-тикшеренүне төп эшләренең берсе дип саный. Әмма тарихи әсәр, әгәр дә фәнни нигездә төзелмәсә, экияткә әверелеп китәчәк.

Тарихи темаларга ясаучы рәссам Канәфи Әбҗәлетдин улы Нәфыйков, ни хикмәт, борынгы Болгар далаларының сулышын саклаучы Чирмешән ягы Иске Үтәмеш авылында туып үскән. Бала чагыннан шул туфрак һәм чишмәләр аны тәрбия иткәннәр. Татарның бөек рәссамы Бакый ага Урманче юкка гына К.Нәфыйковны тарихи темаларны яктыртучы рәссам буларак беренче урынга куймаган. Остазы Әнәс әфәнде Тумашев

исә К.Нәфыйковны бүгенге көндә дә иң тырыш һәм уңышлы эшләүче укучыларының берсеннән саный.

К.Нафиков, рәссам буларак, милли театрыбыз һәм гомумән сәхнә сәнгате өлкәсендә шактый күп хезмәт куйган, шушы юнәлештә Ташкент театр-рәсем институтында 1967-1973 елларда укыган. Ләкин, кызганыч, аның тарихи темаларга эшләнелгән күп кенә сәхнә проектлары тормышка ашмый калганнар. Татарга үз тарихын үз күзе белән күрергә ярамаган шул. Ә К.Нафиков чыннан да тарихны күзгә күрсәтеп бирә.

Кайсыбер вакытларда, ара-тирә татар телеканалыннан К.Нәфыйковның рәсемнәренә багышланган «Тарих башы ерак гасырларда» дигән документаль фильм күрсәтелгәли. Шушы фильм хакында дусларым сүз кузгаткач, бераз тәнкыйди юнәлештә фикер йөртергә үземне әзерләп тә куйган идем. Әмма уйларым телевизордагы беренче картиналардан ук үзгәреп китте. Дөрес, операторларның осталыгы җитенкерәмәгән, ни кызганыч, шушындый изге эшкә Мөнир Зәлүшев кебек оста кинооператорларны нигә тартмадылар икән дип уфтанырга туры килде. Рәсемнәрнең рам кысалары һәрдаим күрсәтелеп, телевизор экранын тарайтканын бик сиземләп бетермәгәннәр. Шулай да режиссеры Фәния ханым Хәертдинованың һәм сценарийлар язуда, тапшыруларны алып баруда шактый осталыкка ирешкән язучы-журналист Индус Сирматовның фильмны яхшы оештыруларын мактап үтәргә кирәк.

Рәсемне күргәзмә залларында карауның үз үзенчәлекләре һәм тәртибе бар. Кайвакытта рәссамның осталыгын бер үтә сиземле эшләнелгән сызык хәл итсә, икенче бер очракта сурәтләрдәге бирелгән характерларның тирәнлеген, яисә вакыйганың, эчтәлекнең тирәнлеген исәпкә алырга туры килә. Операторлар да боларны истә тотарга тиеш иделәр. Димәк, рәссамнарыбызның хезмәтләрен киң аудиториягә җиткерү юнәлешендә шактый кызыклы уңышларга да ирешергә мөмкин. Бу изге эш бер-ике фильм эшләү белән генә тукталып калмаска, алга таба да дәвам итәргә тиеш иде.

К.Нәфыйков рәсемнәренә багышланган бу документаль фильм бүгенге көндә татар мәктәп һәм уку йортларында дәрес

өчен кулланылырга тиешле әһәмиятле материал да әле. Аны укытучы-мөгаллимнәр тарих һәм әдәбият дәресләрендә күрсәтмә әсбап буларак файдалана алалар, чөнки фильмда татар халкының милли тарихы һәм рухи мирасы методологик нигездә төгәл һәм ышанычлы итеп К.Нәфыйковның рәсемнәре ярдәмендә чагылдырылган. Ул Болгар дәвере, Казан ханлыгы, аннан соңгы гасырлар, тарихи вакыйгалар һәм шәхесләр, ул халыкның милли йолаларының электәге күренешләре — боларның барсы да яшь буынның фикере һәм аңы формалашуда зур роль уйнаучы факторлар.

Кызыклы күргәзмәләр даими рәвештә оештырылып, ачылып киләләр. Шулай ук тарихи темаларга иҗат итүче Рушан Шәмсетдиновның шәхси күргәзмәләре дә вакыйга буларак зыялыларыбыз тарафыннан кабул ителде, югары бәя алды. Кызыклы һәм киң планлы эшләре белән башка рәссамнарыбыз да сөендереп торалар.

К.Нәфыйковның бер күргәзмәсендә мин рәссамның 1980 нчы елда ясалган «Археолог Әзһәр Мөхәммәдиев портреты»н күреп гаҗәпкә калган идем. Казан дәүләт университеты профессоры Әзһәр әфәнденең үзен яхшы белгәнлегемнән, бәяләмәләремне бергә туплап, рәссамның шушы график эшендә галимнең характерын һәм максатчанлыгын, тирән белемле шәхес булуын, шул ук вакытта балаларча беркатлылыгын төгәл сызыклар белән бирә алуына сокланып озак карап тордым. Соңыннан да болар хакында искә алып, хәтта үзләренә дә сөйләдем.

Ул чагында Канәфи әфәнде, ничәмә әһәмиятле һәм бәяләп бетергесез эшләре арасыннан берсен аерып мактаганым өчен бераз үпкә дә белдерде әле. Әйе, аны беренче чиратта тарихи темаларга ясалган эшләренә бәям кызыксындыра иде. Әмма мин алар хакында артык сүз куерта алмадым. Ул вакытта әйтергә теләгән фикеремне бәлки хәзер кабул итәр?

Канәфи Нәфыйков тарихи шәхесләрне һәм дәверләргә характерлы күренешләрне сурәтләгәндә дә нәкъ менә шушындый осталыгын эшкә җигә. Күңеленең тоемы, белеменең тирәнлеге, кулының сизгерлеге һәм композиция төзүдәге төгәллеге, эчтәлекне буяулар аша бирә белүе белән ирешә ул

шушы уңышларына, минемчә. Монда аның театр рәссамы буларак формалашуы да зур роль уйнаганлыгы сизелеп тора. Чыннан да аның эшләре тарих театры түгелмени?

## РИЗА ФӘХРЕТДИНОВНЫҢ ВАҺҺАБИЛАР ХАКЫНДА ТӘНКЫЙДИ ФИКЕРЛӘРЕ

Р.Фәхретдиновның Ваhhабилар хакындагы мәкаләсе 1906 нчы елда «Әлгасрел-җәдид» («Яңа гасыр») журналының 2 нче санында дөнья күрә. Ул аны «Ваhhабилар кемнәр?» башы астында урнаштырган. Авторы «Ризаэтдин бине Фәхретдин, Уфа» дип күрсәтелгән. Димәк, ул аны Уфа шәһәрендә яшәгән чагында ук язган, жанрына караганда, фәнни хезмәттән бигрәк, ул журналистик мәкалә стилендә эшләнелгән һәм анда фикерләр публицистик калыпта бәян итүгә корганнар. Шунлыктан бу мәкаләсен асылда сәяси юнәлештә иҗат ителгән публицистик әсәр дип билгели алабыз.

Мәгълүм булганча, XIX нчы йөзнең башлангыч чорында ук ваhhабичылык татар дөньясына үтеп керә. Шул ук йөзнең соңгы чирегендә иҗтимагый фикер үсешендә ныклап урнашкан алдынгы җәдитчелек идеяләре дә ваhhабичылык тээсирендә формалаша. Асылда Р.Фәхретдиновның үзен дә, аның дини карашларын һәм тәрбия-әхлак тематикасын күтәргәндә нинди мәсьәләләргә зур игътибар бирүләрен дә искә алсак, бу яктан ваhhабичы дип белдерә алабыз. Әмма бу карашларын татар әдәбияты һәм иҗтимагый фикере тарихында яктыртканда ваhhабичылык белән бәйләп карау әлегә актуаль булмады, шунлыктан ни сүзлекләрдә, ни фәнни мәкаләләрдә бу хакта ачык кына язылган һәм хәтта ваhhабичылыкның нәрсә икәнлеге аңлатылып бирелгән материалларны табуы һаман да кыен. Хәтта ваhhабичылыкка караган үзенчәлекләр татар җәдитчелек хәрәкәтенең генә түгел, хәтта татар кадимчеләренең дә асыл сыйфатлары итеп

аңлатыла һәм тасвир кылына киләләр. Мәсьәлә киң планда алынып, һәрьяклап тикшеренү-эзләнүләрне, бәяләр бирүне таләп итә.

Ваһһабичылыкны прогрессив хәрәкәт дип карамау хата булыр иде. Шунысын алдан ук белдерергә тиешбез, данлыклы сөгъдиләрнең сәяси омтылышларында төп идеологик коралга әверелдерелгән ваһһабичылык милли-азатлык көчләрен хәрәкәтләндерү өчен дә актив файдаланылган.

Р.Фәхретдинов журналдагы мәкаләсен «Бу сүз башыны күрән затлардан бер чугысы: «Ваһһабилары белмәк нәдән лазем улды, беленмәсе лазем улан башка шиләремез юкмы?»— дия бәхәс итәчәкләре күңелә кәлер» дип башлап китә һәм реаль училищеда укучы улының: «Әткәй? Ваһһабилар кемнәр?..»— дигән сорауны куюын, аңа җавап биргәнендә генә бу мәсьәләгә дикъкать итүен белдерә. Ул урыс мәктәпләрендә укучы татар балаларында ваһһабилар хакында хаталы фикерләр бар икәнлеген искәрә. Мисалга И.Янчинның «География» (Ч.П.— изд. 25-ое.— Москва, 1904.— С.48.) дәреслеге алына һәм аннан ваһһабилар —«секта, не признающая Магомета» дигән билгеләмәгә игътибар юнәлтә. Шуннан соң Р.Фәхретдинов бу фикернең хата булуын аңлату өчен «Ваһһаби җәмгыяте» тарихын сөйләүгә күчә.

Мөхәммәд бине Габделваһһап бине Сөләйман Ән-Нәҗәди Әт-Тәмйәми Әл-Ханбали (1703-1787), «Ваһһаби мәзһәбе»нә нигез салучы галим, үз чорының иң укымышлы затларыннан булган. Туган иле Йәмәндә белем алганнан соң, Басра, Хиҗаз һәм Шам вилаятьләрендә сәяхәтләр итеп, анда исемнәре мәшһүр галимнәр белән очрашкан, алар белән кайнар бәхәсләр оештырган. Ул таркаулыкка дучар ителгән Ислам дөньясын ныгыту өчен җан ата башлаган. Шунлыктан шыгый һәм сөнни мәзһәбләрдә урнашкан, бер-берсен инкарь итешүгә корылган каршылыкларны юкка чыгаруның, суфичылыктан һәм диндарлыктан, халык фикерен буып торганнарына күрә, котылырга кирәклеген яхшы аңлап эш итү юлын сайлаган. Аның бу омтылышлары шул заманның галимнәре тарафыннан тәнкыйтькә очраган. Әмма Мөхәммәд бине Габделваһһап динне сафландыру, тарихи үсеш тузаныннан арындыру

кирәклегән кайнар бәхәсләрдә дәлилләү юлын да тапкан һәм шул вакытларда ук аның теоретик карашлары да формалашып өлгергән. Аның «Китабы-тәүхид» хезмәтендә алар чагылыш тапканнар.

Мөхәммәд бине Габделваһһап ул фикерләрен хаҗилар алдында да, гарәпләр арасында да кайнарлык белән аңлата торган була. Ислам динен саф көенчә саклауны, Мөхәммәд пәйгамбәр заманындагы рәвешенә кайтаруны, бары тик Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәхси үзеннән теркәлеп алынган хәдисләр белән генә гамәл кылуны алга сөрә.

Р.Фәхретдинов шушы мәсьәләләргә тукталып, Мөхәммәд бине Габделваһһапның эшчәнлегенә уңай бәя бирә, аның үз артыннан күпләрне ияртә алуын да билгеләп уза һәм шул вакытларда Йәмәндә сәясәт белән шөгыльләнгән Габделгазиз бине Сөгудның шушы мәзһәпне үз максатларында файдалана башлавын да ачыклый.

Габделгазиз бине Сөгуд, ваһһабиларның җитәкчесе мәртәбәсенә күтәрелеп, бу мәзһәбкә сәяси төс кертә. Асылда диннең сафлыгы өчен көрәшкән ваһһабилар дин карендәшләре булган сөнни Төрек империясенә каршы азатлык хәрәкәте җәелдерәләр, Мәккәне үз кулларына төшерәләр, ваһабилар буларак бик күп җирләрне буйсындыралар, хәтта Мисыр һәм Төрек мәмләкәтләренең гаскәрләре белән аяусыз сугышлар алып баралар. Р.Фәхретдинов ваһһабилар мәзһәбенең тәэсире тиз арада барлык Ислам дөньясына таралуын билгеләп уза. Гарәбстанда гына түгел, хәтта Һиндстанда да галимнәр Мөхәммәд бине Габделваһһапның фикерләрен яклап чыгалар. Ваһһабилыкны Р.Фәхретдинов асылда яңа бер мәзһәб булмыйча, «бәлки Исламы җәнабе Рәсүлуллаһ вә әсхабе гасырында улан садәлегенә вә табигый хәленә куймактан гыйбарәттер» дип аңлата. Әмма алар хакында һаман «Ваһһаби мәзһәбе» исеме астында яза. Мөхәммәд пәйгамбәр мәзһәбе буларак аңлатылган сөнниләрне инкарь итүчеләр буларак ваһабиларны гаепләүнең зур хата икәнлегенә аерым тукталып уза.

Дөрес, ваһһабилар бу вакытларда мөселманнар арасында урнашып җиткән күп кенә йолаларны инкарь иткәннәр: «Буннара күрә, үлекләр хозурына варып Аллаһтан хаҗәт сорамак,

үлекләр исеме илә нәзерләр итмәк вә корбаннар чалмак, үлекләрдән ярдәм эстәмәк, каберләрә зиярат итәр өчен сәфәр әйләмәк, каберләр өстенә биналар салмак, мәсҗетләргә манаралар куймак — мөнһи эшләрдәндер».

Р.Фәхретдинов ваһһабиларның шушы фикерләре белән килешүен белдерә, бу гамәлләрнең чыннан да Аллаһыга мөшриклек икәнлеген таный. Дөрестән дә Ислам дине бәлаказалардан бары тик Аллаһыга гына сыенырга таләп итә, гыйбадәт Аллаһыдан гайрегә дөрес түгел, чөнки бөтен галәмнең хуҗасы бары тик ул гына дип өйрәтә. Бу — Мөхәммәд бине Габделваһһапның «Китабы-тәүхид»ендә генә түгел, бәлки мөселманлыкның нигезе булган иманның асыл эчтәлеген аңлатучы китапларда да тәфсилле язылган. Ә ваһһабилар һәммә йолаларны да тәүхид күзлегеннән уздыралар һәм тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән шәригатьтәге күп кенә карашларның хаталанудан гыйбарәт икәнлеген дәлилләп чыгалар.

Әгәр дә татар әдәбиятының Х1Х нчы йөз башыннан үсешен күзәтсәк, ваһһабиларның йогынтысыннан безнең җәмәгатьчелекнең дә читтә калмаганлыгын күрербез. Ваһһабилар дөньяви гыйлемнәрне дини схоластика белән сугаруга каршы килгәннәр, шуның белән фикер хөрлеген дә яклап чыкканнар. Шунлыктан аларны турыдан-туры фанатизмда гаепләүне хата дип бәяләр идек. Р.Фәхретдинов исә ваһһабиларны көферлектә гаепләргә омтылучыларның сүзләренә каты бәрелмичә генә, моны «гүзәл эш түгел» дип бәяли.

Ваһһабилар сугышка хәвеф намазы укып кергәннәр, тәкбир әйтеп көрәшкәннәр. Бу хәл Мисыр һәм Төрек гаскәрләрен куркуга салган.

Мәкаләсендә Р.Фәхретдинов, тарихи чыганакларга таянып, Мисыр һәм төрек гаскәрләре арасында үзләре белән сугышкан ваһһабиларга карата хөрмәтләренең шактый көчле булганлыгын да бәян итә. Ахырда: «Ваһһабилар — Рәсүл Әкрам өммәтеннән вә безем дин карендәшемез улан мөселманнардыр»,— дип белдерә. Әмма аңа карап кына бу юлдагыларга иярүне кирәк эш дип санамый. «Шуйлә исә дә,—

дип яза ул,— игътикад вә гамәл тугрысында мөтәббигать итәргә тиешле улан бер мәзһәб вар исә, ул да ялгыз Фәхрел-әнбия әфәндемез Мөхәммәд бине Габдулла Әл-Һашими Әл-Корәйши Әл-Мәкки Әл-Мәдинәи мәзһәбедер. Мөмкин кадәр бунының юлына иярмәк вә һич улмадыгында иярер өчен лазем улыр. Халыклар истәр ваһһаби улсыннар, истәр әшгари вә матуруди мәзһәбендә улмак ла ифтихар итсеннәр, хаклык исә Рәсүлуллаһ юлында улмактадыр».

Р.Фәхретдинов мәкаләсен шуның белән төгәлли һәм улына да бу рәвешле аңлатып биргәнлеген яза, урыс китапларындагы хаталы аңлау-аңлатуларга таянып эш итүнең буталуларга гына китерүен белдерә.

Ваһһабилар мәсьәләсенә әйләнеп кайтып, аларның карашлары, Ислам мәдәнияте үсешендә керткән өлешләре зур булганлыгын азсызыклап үтәргә кирәк. Әмма дин юлы, XVII нче йөз татар шагыйре С.Аллаһияр язганча, бик нәзек, анда бик тиз ялгыш эзгә басарга, читкә чыгып китәргә мөмкин. Ничек кенә булмасын, дин ул рухани өлкә генә түгел, ул мәдәни, фәнни берәмлекләрне генә дә түгел, хәтта гадәти күзаллауларны да үз эченә ала, әхлакый нормаларны төзи. Тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән йолалар да кагыйдә булып киткән икән, мәсәлән, Мәүлет бәйрәме һ.б., аларны фундаменталистик-ревизионистик карашлардан чыгып инкарь итү динне сафландыра дип фикер йөртергә нигез була алмый. Ваһһабиларның фикерләре белән артык мавыгып китмичә, әмма мәдәниятебезне үстерүдә аларның идеяләреннән файдаланып, шул ук вакытта тәнкыйтьләрен дә искә алып, Р.Фәхретдинов кебек галимнәребез халык күңелен ныклы итүдә зур эш башкарганнар.

*Октябрь, 1999.*

Э Ч Т Ә Л Е К


Татар теле — аристократлар теле ....................3
Китап тәрбиясе ....................10
Төшләр, фән, шигърият ....................17

***<u>Татар шигърияте сәхифәләреннән</u>***

Узган гасыр ахырында шигъриятебез ....................22
Татар шигърияте һәм анда К.Сибгатуллин һәм Н.Акмалов урыны *Аналитик мәкалә* ....................34
Ренат Харисның мәхәббәт шигъриятендә лирик герой *Аналитик мәкалә*....................51
Равил Фәйзуллин шигъриятендә күзәтү һәм шигъри бәян берәмлекләре....................65
Роберт Миңнуллинның лирикасы һәм аның «эстетик дөнья сурәте»....................77
Дәрья дәрте *(Р.Мингалим иҗаты хакында)*....................93
Зөлфәт шигъриятенең үзенчәлекләре *(әдәби-эстетик анализ тәҗрибәсеннән)*....................103
Урал тулпары *(шагыйрь Р.Ягъфәров иҗаты үзенчәлекләре)*....................113

***<u>Татар прозасы сәхифәләреннән</u>***

Ә.Еники иҗатында әдәби герой концепциясе: *төп элементлары*....................118
Татар әдәбиятында ироник реализм *(Камил Кәримовның «Ком сәгате» романы уңаеннан)* ....................131
Безнең Фәнзаман....................143
«Оча торган кешеләр» яки Ак төс тантанасы *(Г.Гыйльманов иҗатына бәйле)* ....................151

***<u>Бәяле бәяннар</u>***

Сарман Дамир ....................157
Хәмит Ярмине искә алганда....................166
Остаз *(Нил Юзиев хакында истәлек)*....................172
Хәйдәр *(Мин белгән язучы Гайнетдинов Хәйдәр)* ....................179
Күңелендә халык догасы *(Композитор Котдус Хөснуллин иҗаты хакында)* ....................202
Тарихчы рәссам *(Канәфи Нәфиков иҗаты хакында)*....................206
Риза Фәхретдиновның ваһһабилар хакында тәнкыйди фикерләре....................210

**Литературно-критическое научное издание**

***Яхин Фарит Закизянович***

**От века к веку: К литературе нового времени**

Казань: Издательство «СҮЗ» («Слово»), 2014

(На татарском языке)

*Редактор* Павличенкова З.Ф.
*Корректор* Мухамедьярова З.Т.
*Технический редактор и дизайнер* Салимуллин Т.Р.

*Подписана к печати* 21.02.2014.
*Объем* 10 авторских листов. 215 с.
*Тираж* 500 экз.

Типография “Джайб”, г.Казань.
Тел.:8 987 2963592